МИРАС
№4 / 2014

МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№4 / апрель 2014

КАЗАНЬ
КУЛЬТУРНАЯ СТОЛИЦА
ТЮРКСКОГО МИРА
ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ
МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ
2014

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ

КАЗАНЬ
КУЛЬТУРНАЯ СТОЛИЦА
ТЮРКСКОГО МИРА
ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ
МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ
2014

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

04(28)
апрель 2014

88

5 MINTIMIR ŞEYMIEV: «Biz Türk dünyası'nın bir parçasıyız»

17 Azerbaycan'ın efsane şairi Füzuli'nin doğmunun 520 yıl

ЭЧТӘЛЕК

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 **Кардәшлеккә чикләр юк.** *Ләбиб Лерон*

КАЗАН – ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛГЫ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

5 **Минтимер Шәймиев: «Без – төрки дөньяның бер өлеше»**
12 **Фөзули иҗаты һәм татар әдәбияты** (Фөзулинең тууына 520 ел). *Резеда Ганиева*
18 **Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр: Фөзули.** *Ризаэддин Фәхреддин*
22 **Фөзули шигырьләре**
24 **Татар-төрек әдәби бәйләнешләре яссылыгында Тукай иҗаты.** *Хатыйп Миңнегулов*
29 **Тукай әсәрләре кырым татар телендә.** *Илсөяр Рәмиева*
30 **Үзбәк әдәбиятына үз өлешен кертүчеләр.** *Лирон Хәмидуллин*
36 **Ат уйнаткан вакытлар...** *Нурулла Гаптуллин*
37 **Түркләр.** *Ркаил Зәйдулла*
38 **Тәңреләр һәм рухлар.** *Габделкадыйр Инан*
40 İstiklal Marşı
41 **Төркиянең Дәүләт гимны**
42 **ТӨРКИ ДӨНЬЯ ӘДИПЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН:** **Булмас.** *Мәхтүмколый;* **Кызыйлар.** *Токтогул;* **Шәрык нуры.** *Чулпан;* **Мәхәббәт әсире.** *Р.Н.Гүнтәкин;* **Өйләнү.** *М.Әүэзов*
52 **Безнең ничек көрәшкәнне тарих белеп тора...** *Алмаз Гафиятов*

ТАРИХИ МИРАС

54 **Яңа төрек дәүләте уңчылары.** *Йосыф Акчура*
57 **Алтын Урда чоры этник тарихына карата кайбер фикерләр.** *Марсель Әхмәтҗанов*
62 **Милләт язмышын кайгыртып...** (Гаяз Исхакый көндәлеге). *Фәния Фәйзуллина*
67 **Арыслан.** *Газинур Морат*
68 **Вахит Имамов: «Nein, nein, ich bin kein Russisch, ich Tatar!»** *Вахит Имамов белән Равил Сабыр әңгәмәсе*

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды. 2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Марат ЗАКИР
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр —
Данил САЛИХОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №А-871
Тираж — 3000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Басарга кул куелды: 4.04.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

72 **Төрки-татар тарихи терминнарының аңлатмалы сүзлеген төзүгә карата.** *Ильяс Мөстәкыймов*

ӘДӘБИ МИРАС

80 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
88 **Тукайча татар кодексы.** *Зиннур Мансуров*
103 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Мөхәммәтшин*
104 **Тукай дәреслеге** (Г.Тукай төзегән җыентыкларның милли әдәбият үсешендәге әһәмияте). *Эльмера Галимҗанова, Фәния Фәйзуллина.*
107 **«Әлифба» музее… Бердәнбер!**

СӘНГАТИ МИРАС

108 **Тукай образын иҗат иткәндә.** *Габдулла Шамуков*
11 **«Безнең мирас» елъязмасы / Апрель**

ФӘННИ МИРАС

112 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*
115 **Мирасворд**

МИЛЛИ МАТБУГАТ БИТЛӘРЕННӘН

116 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның апрель ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

120 **Яңа китап.** *Гөлчирә Ханнанова*

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән һәм авторларның архивыннан алынган фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә —
«Г.Тукай. Туган моңнар» (фрагмент). Картон, пастель. *Х.Латыйф эше.*

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

КАРДӘШЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК

Хөрмәтле кардәшләр!

Мәгълүм ки, 1993 елның июлендә төрки халыкларның мәдәни тормышында зур вакыйга булды: Азәрбайҗан, Казахстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан һәм Төркиянең мәдәният министрлары Алматы шәһәрендә ТӨРКСОЙ оешмасы төзү турындагы килешүгә кул куйды. Бераз соңрак бу оешмага Башкортстан, Татарстан, Хакас, Тыва, Алтай, Гагауз, Саха-Якутия һәм Төньяк Кипр Төрек Республикасы вәкилләре дә килеп кушылды (бүгенге көндә ТӨРКСОЙ ундүрт төрки халыкны берләштерә).

ТӨРКСОЙ төрки милләтләрнең мәдәни мирасын барлау, саклау, киләсе буыннарга тапшыру, башка халыкларга таныту һәм дә төрки кардәшләребез арасындагы дуслык-туганлык җепләрен ныгытуга биниһая зур өлеш кертә.

Быел Казан төрки халыкларның мәдәни башкаласы дип игълан ителгән иде. Бу уңайдан шәһәребездә бик күркәм чаралар үтәчәк. Шулардан берсе – «Мәшһүр мәгърифәтчеләр Мәһмәт Акиф Ирсой һәм Габдулла Тукай» Халыкара симпозиумы. Сүз уңаеннан, әлеге мәшһүрләребезгә, шулай ук төрки дөньяның башка асыл шәхесләренә, әйтик, бөек азәри шагыйре Фөзули (тууына 520 ел), күренекле төрекмән шагыйре Мәхтүмколый (тууына 290 ел), танылган кыргыз акыны Токтогул (тууына 150 ел), Йосыф Баласагунлы, Йосыф Акчура, Рәшат Нури Гүнтәкин, Гаяз Исхакый һәм Мохтар Әүэзов һәм башкаларга бәйле язмаларны, аларның иҗат үрнәкләрен журналыбыздан укый алачаксыз.

Аңлашылганча, бу санныбыз шушы зур чара уңаеннан махсус нәшер ителде.

Кардәшлеккә чикләр юк, диләр. Хак сүзләр. Киләчәктә дә шулай бергә-бергә, иңгә-иң торып, һәрчак дус булып яшәргә язсын!

СЛОВО ГЛАВНОГО РЕДАКТОРА

РОДСТВУ НЕТ ГРАНИЦ

Уважаемые собратья, друзья!

Как известно, в июле 1993 года произошло знаменательное событие, затронувшее культурную жизнь тюркских народов. В городе Алматы министры культур Азербайджана, Казахстана, Киргизстана, Туркменистана, Узбекистана и Турции подписали соглашение о создании организации ТЮРКСОЙ. Позже к ней присоединились представители Башкортстана, Татарстана, Хакасии, Тывы, Алтая, Гагаузии, Саха-Якутии и Турецкой Республики Северного Кипра (на сегодняшний день ТЮРКСОЙ объединяет 14 тюркских народов).

ТЮРКСОЙ вносит огромный вклад в возрождение, сохранение и популяризацию культурного наследия тюркских народов, передаёт традиции будущим поколениям, способствует укреплению родственных связей.

В 2014 году Казань была объявлена «Культурной столицей тюркского мира». В этой связи в городе планируется провести ряд важных мероприятий, одним из которых станет Международный симпозиум «Выдающиеся просветители Мехмет Акиф Эрсой и Габдулла Тукай». К слову, в журнале вы сможете найти статьи и образцы из творчества этих и других выдающихся личностей тюркского мира, как великий азербайджанский поэт Физули (520 лет со дня рождения), известный туркменский поэт Махтумкули (290 лет со дня рождения), знаменитый киргизский акын Токтогул (150 лет со дня рождения), Юсуф Баласагуни, Юсуф Акчура, Решат Нури Гюнтекин, Гаяз Исхаки, Мухтар Ауэзов и другие.

Этот номер журнала специально посвящён данному знаменательному событию.

Говорят, родству нет границ. Верные слова. Желаю, чтобы и в будущем мы были вместе, стояли плечом к плечу, всегда жили в мире и дружбе!

YAZI IŞLERI MÜDÜRÜNDEN

KARDEŞLIKTE SINIR YOKTUR

Çok Değerli Kardeşlerimiz!

Bildiğiniz gibi, 1993 yılının Temmuz ayında Türk topluluklarının kültür hayatında çok büyük bir olay yaşandı; Azerbaycan, Kazakistan, Kırgızistan, Türkmenistan, Özbekistan ve Türkiye'nin kültür bakanlarınca Kazakistan'ın Almatı kentinde, TÜRKSOY Teşkılatı'nın kurulması için sözleşme imzalandı. TÜRKSOY Teşkilatı'na daha sonra, Başkurdistan, Tataristan, Hakas, Tuva, Altay, Saha-Yakut, Gagavuz, KKTC (Kuzey Kıprıs Türk Cumhuriyeti) Cumhuriyetleri bu teşkilata katıldılar. Bugün ondört ülke TÜRKSOY'un üyesidir.

TÜRKSOY kurulduğu günden bu güne Türk topluluklarının kültür mirasına sahip çıkmayı, onu korumayı, gelecek nesillere aktarmayı, başka milletlere tanıtmayı, Türk kardeşliğini pekiştirmeyi şiar edinmiştir.

Bu yıl Kazan kenti, Türk topluluklarının kültür başkenti olarak ilan edilmiştır. Bu bağlamda şehrimizde çeşitli konularda toplantı ve konferanslar düzenlenecektir. Bunlardan biri «Ünlü aydınlar Mehmet Akif Ersoy ve Ğabdulla Tukay» adını taşımaktadır. Bunun yanısıra dergimizde Türk Dünyası'nın yetiştirdiği mümtaz şahsiyetlerden Azeri Şairi Fuzuli (Doğumunun 520. yılı münsabetiyle), Türkmen Şairi Mahtumkulu (Doğumunun 290. yılı münasebetiyle), Kırgız Ozanı Toktoğul (Doğumunun 150. yılı münasebetiyle), Yusuf Balasağuni, Yusuf Akçura, Reşat Nuri Güntekin, Ğayaz İshakıy, Muhtar Avezov'la ilgili yazılar ve daha başka edebi yapıtlar yer alacaktır.

Dergimiz, anlaşıldığı gibi Kazan 2014 Türk Dünyası Kültür Başkenti özel sayısı olarak yayımlanmış bulunmaktadır.

Kardeşlikte sınır yoktur demişler. Çok doğru bir söz. Bundan sonra da dostluk ve kardeşliğimizin el ele, omuz omuza daha bir canlanarak ilelebet devam etmesini diliyoruz!

INTRODUCTORY WORD FROM THE EDITOR-IN-CHIEF

NO BOUNDARIES TO THE BROTHERHOOD

Dear friends!

It is known in 1993 in the cultural life of Turkic peoples there was an outstanding event: in the city of Almaty the Ministries of Culture of Azerbaijan, Kazakhstan, Kyrgyzstan, Turkmenistan, Uzbekistan and Turkey concluded an agreement about the establishment of the World Assembly of Turkic Peoples TURKSOY. Later the representatives of Bashkortostan, Tatarstan, Khakassia, Tuva, Altay, Gagauzia, Yakutia and the Turkish Republic of Northern Cyprus joined this assembly (at present TURKSOY unites fourteen Turkic peoples).

The World Assembly of Turkic Peoples makes a valuable contribution to revival, preservation, popularization and transmission of the Turkic peoples' cultural heritage to the next generations. It favours the strengthening of relationships.

This year Kazan was proclaimed as the culture capital of the Turkic peoples. In this regard, in our city a lot of important events will be held. One of them is an international Symposium «Outstanding enlighteners of the Mehmet Akif Ersoy and Gabdulla Tukay». By the way, in the magazine you can find the articles and extracts from the works of these and other prominent people of the Turkic World, as great Azerbaijani poet Fizuli (520 years old since birth), famous Turkmen poet Mahmutkoly (290 years old since birth), outstanding Kirgiz akyn Toktogul (150 years old since birth), Yusuf Balasagun, Yusuf Akchura, Reshat Nuri Guntekin, Gajaz Ishaki, Muhtar Auezov and others.

Now it is understandable, the issue is dedicated to this momentous event.

They say there are no boundaries to the brotherhood. It is true. Wish us were together standing shoulder to shoulder and living in peace and happiness.

КАЗАН – ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛГЫ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ



МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ: «БЕЗ ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕ»

Лев Овруцкий. «Беседы с Минтимером Шаймиевым» китабыннан

MINTIMER SHAIMIEV: «WE ARE THE PART OF THE TURKIC WORLD»
From the work of «Talks with Mintimer Shaimiev» by Lev Ovrutskiy

– Минем бүген Татарстанның чит илләр белән, атап әйткәндә, Якын Көнчыгыш юнәлешендәге элемтәләре хакында сөйләшәсем килә иде. Халыкара багланышлар, нигездә, шулардан башланды. Бу юнәлешне сайлавыгыз очраклы хәл, әлеге эшләр буенча киңәшчегез Акуловның гарәп илләре буенча белгеч булуыннан килә, дигәннәр иде миңа.

— Бу дөрес түгел. Акулов, чыннан да, гарәп илләре белгече булса да, без Төркиядән башладык. Һәм бу табигый иде, чөнки милли яңарыш башлангач, үзебезнең иң беренче чиратта төрки дөньяның бер өлеше булуыбыздан чыгып эш йөрттек.

– Һәм мөселман дөньясының да.

— Әлбәттә.

– Төркиядән соң сез күп кенә гарәп илләренә – Әмирлекләргә, Кувәйткә, һәм иң мөһиме, Согыд Гарәбстанына бардыгыз. Ә Израильдә булдыгызмы?

— Булдым.

– Бу хакта газетага язганнарын нигәдер хәтерләмим.

— Анысы шәхси сәфәр иде, мөгаен, шуңа күрә язмаганнардыр. Бераз ачыклап китим. Икътисади мөнәсәбәтләрне үстерүне без иң элек Европадан башладык, чөнки анда җайга салынган эшләребез бар иде инде. Шуннан соң — Төркия. Америкада да булдым, гәрчә әле бу көннәрдә генә кайдадыр күземә чалынды: имеш, мин анда ике сенатор белән очрашканмын да, шуның белән эш беткән. Монысын инде кем язган, шуның намусында калсын. Ул чорда Татарстан белән кызыксыну көчле иде. Мин элеккеге Дәүләт секретаре, бөтен дөньяга мәгълүм сәясәтче Киссинджер, дүрт министр белән очраштым. Иң мөһиме, АКШның Эксимбанк рәисе белән нефтехимия өчен кредитларга бәйле хәлиткеч килешүләргә ирешелде. АКШның сенатында исә танылган сенаторлар һәм берничә комитетның әгъзалары катнашлыгында ике якны да кызыксындырган очрашулар булды.

– Беләм, анда очрашулар күп булды, иң мөһиме сезнең Гарвардтагы нотыгыгыз. Зур тәэсир калдырган иде ул. Ләкин сүзне Төркиядән башлаган идек. Бу ил белән мөнәсәбәтләр ничек урнашты?

— Алдыбызда дөнья ачылгач, табигый ки, беренче мәдәни багланышлар

Төркиядә илнең президенты Тургут Озал белән. 2002 елның 17 декабре

төрекләр белән булды. Тел, мәдәният, дини традицияләр ягыннан уртаклык уңай йогынты ясады. Төрки дөнья безгә бик якын, без — аның бер өлеше.

– Тел җәһәтеннән авырлыклар юкмы? Тылмач кирәкме? Сез төрекләрне аңлыйсызмы?

— Әгәр алар иске төрекчә сөйләшсә, ә син татар телен яхшы белсәң — бер кыенлыгы да юк, барысы да аңлашыла диярлек. Бик тиз сөйләшмәсәләр, мин әйбәт кенә аралашам. Кайбер татарлар төрек телен начар аңлый, бу аларның татарчаны юньләп белмәвеннән килә. Ататөрек реформасыннан соң төрек теле шактый яңарган, ә менә иске төрек теле исә татар теленә якын калган.

– Төрек ягыннан беренче «карлыгачлар», мөгаен, эшмәкәрләр булгандыр.

— Әйе, төрек эшмәкәрләре. Алар, безгә килеп, контрактлар алырга омтылдылар.

Кайбер татарлар төрек телен начар аңлый, бу аларның татарчаны юньләп белмәвеннән килә.

– Алдылармы соң?

— Әйе, әле без аларга үзебезнең нефтьне дә саттык. Сабиров премьер-министр чагында, без федераль үзәк белән нефтьнең бер өлешен үзебезнең карамакта калдырып, республика ихтыяҗларына тоту турында килештек. Билгеле бер күләмдә квота алуга ирештек, бу җиңел булмады. «Татнефть» үзе чыгара торган нефтьнең бер өлешен республикага калдыра башлады.

– Өчтән бер өлешен, минемчә.

— Бераз кимрәк. Әмма шуны әйтер идем: квота алу — бер хәл, ә менә экспортны җайлап җибәрү — бөтенләй башка нәрсә. Әлбәттә, башлап Төркия үзе кызыксынды, алар, башка бик күпләр шикелле, нефтькә мохтаҗлык кичерә. Андагы компанияләр безгә мөрәҗәгать итте. Шул рәвешле сәүдә, бигрәк тә вак күмәртәле сәүдә һәм бүтән тармакларда да хезмәттәшлек башланды. Ул заманда бер без генә түгел — бөтен Россия Төркия белән сәүдә итте.

– «Капчыклы» сәүдәгәрләрме?

— Әйе, ирекле сәүдә алардан башланды. Кешеләр Төркиягә барып капчыклап товар ала да, монда алып кайтып сата. Павильоннар, вак кибетләр ачыла башлады... Барысын да үз җикәләрендә күтәреп ташыдылар, капчыклар астында үзләре күренмиде дә — кырмыскалар кебек.

– Хәтеремдә, Казанда төрек төзүчеләре бик күп иде.

— Алар хәзер дә бар, дөрес, алай ук күп түгел. Төрекләрдә төзелеш технологияләре яхшы, ә без аларча эшли белми идек. Бигрәк тә бетон, монолит конструкцияләр буенча.

– Шуучы «опалубкалар»мы?

— Күрәм, сез яхшы беләсез икән. Без ул чакта бу технологияне үзләштерергә тырышып карадык, тик әллә ни барып чыкмады, ә төзергә кирәк иде. Соңыннан, әлбәттә, өйрәндек. Дөресен генә әйткәндә, үзләренә ихтыяҗның кимүен, аларны сирәгрәк чакыра башлавыбызны төрекләр авыр кичер-

Төркия президенты Сөләйман Дәмирәл белән. Төркия, 2004 елның 15 сентябре

де. Ләкин бу бернинди дә сәясәткә бәйләнмәгән табигый процесс иде.

– Шулай да төрекләр Казанда күп төзеделәр. Хәтта Кремльне төзекләндерүдә дә катнаштылар.

— Әйе, Кол Шәрифтә дә, Кремль сараенда да алар эшләде. Президент Абдуллаһ Гүл белән премьер Эрдоган безгә килгәч, бу биналарны аларга да күрсәттек һәм алар үзләренең канәгатьлек, әйтер идем, хәтта горурлык хисен яшермәделәр.

– Көзен, сентябрь аенда, һәрвакыт Төркиядә ял итү гадәтегезне бөтенесе дә белә. Бу инде традициягә әверелде. Һәм һәрчак сез анда Төркиянең югары җитәкчелеге белән очрашасыз.

— Беренче тапкыр мин анда ял итәргә 90 нчы еллар башында бардым, ул чакта Төркия президенты Тургут Озал иде. Һәм аннан соң да, мөгаен, егерме еллап, мин гел бер кунакханәдә ял иттем.

– Инде аңладым, сез – консерватив кеше. Әгәр дә ошый икән, шул җитә, кем әйтмешли, яхшылыктан яхшылык эзләмисез.

— Әйе, анысы шулай. Проблемалар юк икән, нигә тагын нидер эзләргә? Анда миңа бик уңайлы. Хезмәт күрсәтү, аңлаешлы тел, игътибар, сакчылар һәм башкалар — барысы да югары дәрәҗәдә.

– Бу – Кемердамы инде?

— Анталиядә бу, «Киришфорд» кунакханәсендә.

– Сез президентлыктан киткәч, нидер үзгәрдеме?

— Юк. Дөрес, соңгы ике елда Бодрумда ял итәм. Бодрумга барырга миңа президент Гүл киңәш итте, анда һава бик әйбәт, корырак та, диде. Чыннан да, Бодрум миңа ныграк ошады. Әмма шуны әйтер идем, игътибар һич үзгәрмәде. Бик ихтирамлы мөнәсәбәт.

– Сезгә һәрвакыт югары дәрәҗәдәге кунакка караган кебек карадылармы?

— Һичшиксез шулай. Иң беренче килүемнән үк. Ул чакта әле аларның Казанда консуллыгы булмаса да, миңа Тургут Озал белән очрашу оештырдылар. Ул бу очрашуга карата нәзакәтлек күрсәтте — без бит Россиянең бер өлеше, шуңа күрә, дипломатия ягыннан аңлашылмаучылыклар килеп чыкмасын өчен, алар мине Россия вәкиле буларак кабул иттеләр. Асылда исә — тиешенчә кадер-хөрмәт күрсәтелде. Ул безне хәләл җефете белән үз

резиденциясендә — Истанбулда, Босфор ярындагы сараенда кабул итте.

– Сез дә хатыныгыз белән идегезме?

— Әйе, әлбәттә, протокол буенча шулай тиеш. Минем хатыным — аның хатыны белән, ә мин — Озал белән таныштым. Ул мине үзенең улы белән дә таныштырды. Шуннан соң без, бергә-бер калып, озак кына әңгәмә кордык.

– Сүз ни турында барды?

— Ул мөселман дөньясы, төрки дөнья турында сөйләде. СССР таркалганнан соң барлыкка килгән илләр буенча йөргән икән.

– Алар барысы да мөселман республикаларымы?

— Әйе. Мин аларның үз йогынтыларын бөтен төрки дөньяга тарату теләген тойдым һәм аңладым. Һәм, әйтер идем, бу һич кенә дә буш ният түгел. Мин күрдем: төрле елларда Төркиягә килеп урнашып, иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләрен шунда дәвам иткән татар һәм башкорт зыялыларының каберләре бүгенгәчә карап-кадерләп тотыла.

– Аларның күбесе – Атарөрекнең көрәштәшләре... Менә бит ул нинди хикмәт: алар Россиядән, Лениннан качып киткәннәр, ә Ленин Ататөрек белән дуслашкан.

— Мондый каршылыклар тарихта аз түгел. Төркиядә Исхакый, Вәлиди, Максуди җирләнгән... Бу ил аларның барысын да сыендырган, без моны истә тотарга тиеш.

– Озал мөселманнарны берләштерүгә өндәдеме?

— Мөселманнарны да, төркиләрне дә. Ул болай диде: «Безгә бер-беребез белән үзара аңлашуга ирешергә кирәк, бергә булырга кирәк, чөнки ислам дөньясына басым ясау бара. Киләчәктә бу басым көчәячәк. Чөнки без хәзер нығыйбыз, мөселманнар арта бара, без билгеле бер байлыкка ия». Моннан тыш, Төркиянең геосәяси урыны нинди шәп: Босфор бугазы, илнең ярларын ничәмә диңгез юа.

– Мәгълүм ки, Россиядә пантюркизмга бик сагаеп карыйлар.

— Алай ук күпертмәскә иде. Нинди пантюркизм? Бу темага бер Жириновский гына сөйләнә, ә аны рус милләтчеләреннән гайре кем генә тыңлый соң?

– Озал белән әңгәмәгезнең хасиятен аныклыйсым килә. Сез – яшь сәясәтче, халыкара дәрәҗәгә беренче мәртәбә чыгуыгыз, ә ул инде мондый эшләрдә, кем әйтмешли, азау теше ярган. Сезнең үзара мөнәсәбәтләрдә «остаз-укучы» халәте булмадымы?

— Юк, бөтенләй булмады. Ул зирәк кеше. Үзен гади тотты: без аның белән бик җылы, ирекле, тигез дәрәҗәдә әңгәмә кордык. Ул да мине аңлагандыр, дип уйлыйм.

– Ягъни ул өстен булырга тырышмады?

— Юк, миңа ул аерым бер хөрмәт белән карады кебек.

– Бу бердәнбер очрашуыгыз булдымы?

— Юк. Хәтеремдә, бер тапкыр ул — инде башка резиденциясендә — зур кабул итү мәҗлесе оештырды. Утырабыз, гаҗәеп матур табын, әңгәмәбезне дәвам итәбез. Ул үзе җитәкчелеккә керешкән заманда аларда маргаринны талонга гына бирүләре, азык-төлек җитмәве турында сөйли. Үз чиратымда мин дә, СССРда гомумән бөтен нәрсәнең талонга гына бирелгәнлеген сөйлим. Моңа кадәр Истанбулдагы бер-ике супермаркетта булган идем. Анда — муллык, хәзерге көндә бездәге кебек. Һәм мин моңа сокланып әйттем: сездә товар шундый күп! Ул чакта бездә андый хәл юк әле, бу хыял гына иде. Гел гаҗәпләнә идем: шулкадәр азык-төлекнең булуы мөмкинмени? Алар ничек бозылмый саклана соң?

– Мин моңа хәзергә кадәр гаҗәпләнәм.

— Шулай озак кына сөйләшеп утырдык, ләкин аңа — өйләдән соң Әнкарага очарга, ә безгә исә ялны дәвам итәргә кирәк иде. Һәм ул, һич көтмәгәндә, болай дип куйды: «Әйе, президент әфәнде, кибетләрдә товарлар бар, әле күбрәк тә булачак, әмма безгә шунысы

Казан Кремлендә Төркиянең премьер-министры Рәҗәп Тайип Эрдоган белән очрашу вакыты. 2011 ел

мөһим: анда үзебез җитештергән товарлар күбрәк булырга тиеш».

– Ул сезгә «президент әфәнде» – дип мөрәҗәгать иттеме?

— Әйе, әлбәттә.

– Инде шулай якынаеп киткәч, «галстуксыз» форматка, бер-берегезгә исем белән эндәшүгә күчкәнсездер, дип уйлаган идем.

— Юк, аларда андый гадәт юк. Һәрвакыт «президент әфәнде» яисә «хөрмәтле президент» (төрекчә «саин җөмһүрбашкан» дип әйтелә). Һәм ул кинәт кенә әйтә: «Президент әфәнде, Сезгә Истанбулны күрсәтәсем килә». Ә анда ил көрдләр вә башка сәбәпләргә бәйле рәвештә тыныч түгел, сак һәм протокол хезмәтенә тиз арада безгә җайлашырга туры килде. Шәһәр буйлап машинада йөрдек, супермаркетка кердек. Ул һәр бүлектә төрекләр җитештергән товар белән кызыксына һәм аларны горурланып миңа күрсәтә. Үз товарларыбызның күбрәк булуын телим, ди. Мин күрдем: аны кешеләр ярата, кулларын үбәләр, анда шулай кабул ителгән. Озалга карата хөрмәтнең

Төркиядә Исхакый, Вәлиди, Максуди җирләнгән... Бу ил аларның барысын да сыендырган, без моны истә тотарга тиеш.

гаять зур икәнлеге күзгә ташланып тора иде. Чөнки ул җитәкчелек иткән чорда төрекләр, ниһаять, туйганчы ашый башлаганнар! Мин халыкның мондый мөнәсәбәтенә таң калдым. Моның кадерен белмәү мөмкин түгел.

– Ул бит Европага таба да борылды, Европа Берлегенә керү мәсьәләсен күтәрде.

— Әйе, ул киң колачлы кеше иде. Ул Ислам факторы хакында әйтте, һәм мин моның хәзер нигездә гамәлгә ашуын күрәм. Тугандаш халыкларның үзара аңлашуын ныгыту турында борчылуын, аның фикерләрен бик еш искә алам.

– Аның Сезгә йогынтысы булган, бу сизелеп тора.

— Ә мин моны яшермим дә. Ләкин, шул ук вакытта, безнең, Россиянең дөньяда үз геосәяси мәнфәгатьләре барлыгын да аңлыйм. Төркия белән сөйләшүләр алып барырга, яхшы мөнәсәбәтләр урнаштырырга кирәк. Озал үзе дә яңа Россия һәм яңа Татарстан белән элемтәләрне җайга салу кирәклеге турында сөйли иде. Без Казанда Төркия консуллыгын ачу мәгъкульлеге, Россия белән үзара мөнәсәбәтләрдә Татарстан факторы да исәпкә алынырга тиешлеге турында сөйләштек.

– Сез аның белән бүтән очрашмадыгызмы? Озакламый вафат булды бугай ул.

— Әйе, ул юан кеше иде, йөрәге авырткан, күрәсең, эшлекле сәфәрләренең берсендә инфаркттан үлеп китте.

– Аннан соң Дәмирәл булды.

— Әйе, Сөләйман Дәмирәл. Ул хакимияткә берничә мәртәбә килде, мәшһүр сәясәтче һәм атаклы дипломат. Аның белән мөгамәләбез гаиләләр дуслыгы дәрәҗәсендә диярлек иде.

– Җылы мөнәсәбәтләр?

— Бик җылы. Мин аның белән берничә тапкыр очраштым һәм хатыннарыбыз катнашында мәҗлесләр гадәти хәлгә әйләнде. Озалдан башлап, шулай килә — безнең ял вакытында һәр президент шәхси самолётын җибәрә, безне почётлы каравыл белән каршы ала. Төшке аш гадәттә Президентның Әнкарадагы резиденциясендә уза.

– Тик Сез бит дәүләт башлыгы да түгел, рәсми визит белән дә килмәгәнсез.

— Юк, әлбәттә. Бу — дуслык чагылышы. Анталиягә туристлар очып килә торган халыкара аэропорт янәшәсендә хәрби аэродром бар. Менә шунда алар мине югары дәрҗәле кунак сыйфатында каршы алалар иде.

– Сезне таң калдырмакчы булдылармы? Бу протокол гамәлләре, нигездә, бик кыйммәткә төшми, әмма бик югары бәһаләнә.

— Моны протокол гамәлләре генә, дип уйламыйм, гәрчә дустанә карашка гына кайтып калмаса да. Ихтимал, Татарстанның Россиядәге абруе да, безнең Ельцин, Путин белән мөнәсәбәтләр дә, партия төзелешендәге ролебез дә бәяләнгәндер.

– Дәмирәл белән арагыз бик җылы, дип әйткән идегез.

— Әйе, без әле хәзер дә берберебезне бәйрәмнәр һәм туган көннәр белән котлыйбыз.

– Ягъни элемтәләр өзелми.

— Әйе, кешеләрчә, дусларча элемтәләр. Бер тапкыр шулай Дәмирәл мин ял итеп яткан Анталиягә очып килде дә үзенең кунакханәсенә чакырды. Без төшке ашны бергә ашадык, ә кичен кинофестивальгә киттек. Йомгаклау кичәсе, җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы бара иде. Һәм кинәт ул мине сәхнәгә чакырды да, үзе белән бергә бүләкләрне Шәймиев тә тапшырачагын белдерде. Ул мине: «Татарстан Президенты — Шәймиев, минем туганым» — дип игълан итте.

– Сез республика президенты булып эшләгән дәвердә Төркия белән бернинди дә кытыршылыклар булмадымы?

— Мөнәсәбәтләр ансыз гына булмый. Бер вакыйга истә калган. Ул чакта президент Сезер иде. Без, ягъни «Татнефть», зур бер төрек компаниясен сатып алырга килештек. «Тупраш» иде бугай. Төркиядәге ягулык салу станцияләренең 70 проценты аның кулында иде.

– Җитди хәл – 70 процент!

— Без бит уйламыйча юк-бар сөйләп йөрүчеләр түгел. Дәүләт эшләрендә андый экспромтлар гомумән булырга тиеш түгел. Мизгел эчендә йөзеңне югалтуың ихтимал. Мәсьәлә бик җентекләп өйрәнелде, әзерләнде.

– Өстәвенә барысын да Мәскәү белән дә килештерергә кирәк бит әле.

— Әлбәттә. Бер йөкне бергәләп тартабыз лабаса.

– Килешү өзелдеме?

— Кызганыч ки, өзелде. Без инде килешендек, хәтта расладык та, ләкин профсоюзлар каршы чыкты: янәсе, ил бәйлелеккә төшә, эшчеләрнең эш урын-

Төркиядә илнең президенты Абдуллаһ Гүл белән. 2009 елның 26 сентябре

нарын югалтуы мөмкин һәм башкалар.

– Төрек хөкүмәте үзенең профсоюзларына тәэсир итә алмадымы? Моңа хәтта ышануы да кыен.

— Ышанырга да, ышанмаска да була, әмма килешү өзелде. Шунысын әйтим, төрек бизнесы үтә агрессив. Төрекләрнең тәҗрибәсе көчле, алар сәүдә итә дә, сатулаша да беләләр.

– Сәүдәчел милләт.

— Әйе, бик сәүдәчел. Аларның эшмәкәрләре белән эш итү җиңел түгел. Ә безнең кешеләр социализмнан чыккан, кайчак үтә беркатлы эш итәләр, менә хәзер утырабыз да, бөтен мәсьәләләрне хәл итеп ташлыйбыз, дип уйлыйлар.

– Бу килешүнең өзелүе алга таба мөнәсәбәтләргә комачау итмәдеме соң?

— Юк. Әлбәттә, кәеф кырылды. Ләкин без алга таба бергә эшли ала торган башка өлкәләр, мәсәлән, гуманитар өлкә барлыгын аңладык. Үзегез

Ул мине: «Татарстан Президенты – Шәймиев, минем туганым» – дип игълан итте.

дә күреп торасыз, без Төркиядә Сабан туйлары, Тукай көннәре оештырабыз, күпсанлы һәм төрле фестивальләр, очрашулар, конференцияләр уздырабыз.

– Ягъни татар йогынтысы ныгый бара?

— Үзара йогынты бу. Без — аларга, алар безгә йогынты ясый. Әгәр дә алар безгә ачык йөз күрсәтмәсәләр, бу мөмкин булмас та иде.

Русчадан ***Марат Закир*** *тәрҗемәсе*

Translation of ***Marat Zakir*** *from Russian* ■

Азәрбайҗанның даһи шагыйре Фөзулинең тууына – 520 ел

520 years since the birth of Fizuli, the genius poet of Azerbaijan

ФӨЗУЛИ ИҖАТЫ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

(ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР ЯССЫЛЫГЫНДА)

Резеда Ганиева

THE CREATIVE ACTIVITY OF FIZULI AND TATAR LITERATURE
(studying work of Fizuli in the sphere of literary interrelations).

Prof. Rezeda Ganieva

Фөзули (Мөхәммәд Сөләйман улы, 1494-1556) – Яңарыш дәвере кичергән урта гасыр азәрбайҗан әдәбиятының даһи шагыйре, акыл иясе.

Фөзули – аның тәхәллүсе, «кыю», «куркусыз» дигән мәгънәне аңлата. Шагыйрьнең ата-бабалары Азәрбайҗанда яшәгән. Әмма бу ил-дәүләт өчен бертуктамый барган сугыш-тартышлар, аеруча Тимур яулары аркасында, Фөзулинең ата-анасы Госманлы солтаннары идарә иткән Гыйракка күченеп китәргә мәҗбүр була. Булачак шагыйрь шигый мөселманнары өчен бик тә изге, хаҗ кылу урыны булып саналган дүртенче хәлифә Галинең улы Хөсәен (Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы) җирләнгән Кәрбәла шәһәрендә дин әһеле (мөфти) гаиләсендә туа. Дөньякүләм мәдәнифәнни үзәк булып танылган Багдад шәһәрендә Коръән тәгълиматы, фикъһе гыйлеме, математика, логика, медицина, астрономия буенча тирән белем ала; грекларның Пифагор, Гераклит, Эмпедокл, Сократ, Әфләтүн (Платон), Арасту (Аристотель) кебек акыл ияләренең, әл-Кинди, Фараби, Бируни, Ибн Сина, Ибн Рөшд кебек Шәрык философларының хезмәтләрен зур тырышлык куеп өйрәнә, Көнчыгыш Ренессанс әдәбиятының атаклы вәкилләре

Рудаки, Фирдәүси, Хакани, Ж.Руми, Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Нәсими, Нәвои иҗатлары белән яхшы таныш була. Фөзулинең замандашлары һәм иҗатын өйрәнүчеләр аның тырышлыгына, армый-талмый гыйлем туплавына, барлык фәннәрдән дә хәбәрдар булуына игътибар итә. Фөзули тәхет ияләреннән,


دیباچهٔ دیوان فضولی
علیه الرحمه

حمد بی حد اول متکلم نطق آفرینه که سفینهٔ امید سکان بحار بحور نظمی تموج استغراق
مستغرق گرداب حرمان اتمش ایکن سلسلهٔ استبشار
براوب شعراء اسلام صحیح و سالم ساحل نجاته چکمش و سپاس بیقیاس
اول ناظم آسمان و زمینه که بسملهٔ بر نظمین افسر فرق فرقان ایدوب مزرعهٔ
قلوب اهل عرفان نهال مودت کلام موزونه چکمش زهی صانع که لوح
خامهٔ کلک حسن موسیقی ازلدن اقتضای نظم جان پرور رقم قلمش کمال
شعرکیبی محکم اولماز اولدین ایدین آنکا منت که طبع نظم لطف اتمش رقم قیلمش

Физули диваныннан бер бит

хакимнәрдән ераграк булырга тырыша, мәдрәсәдә мөгаллим, мөдәррис, мулла, изгеләр төрбәсен саклаучы мөҗәвир вазифасын башкара. Шагыйрь 1556 елда чума эпидемиясе вакытында Кәрбәладә вафат була.

Шигърият белән Фөзули бик иртә кызыксына башлый. Сәнгати осталык һәм камиллек үрнәге дип кабул ителгән әсәрләрен өч телдә — гарәп, фарсы, төрки телләрдә иҗат итә һәм «Багдад Фөзулисе» дигән шөһрәтле исемгә лаек була. Әдәби-фәнни чыганакларда шагыйрьнең тышкы кыяфәте түбәндәгечә тасвирлана: «олуг башлы, зур вә үткен күзле, озынча битле, куе сакаллы, кыска чәчле, озын мыеклы бер адәмдер» (Р.Фәхреддин).

Шәрык һәм Гареб әдәбият белемендә Фөзули мирасы шактый төпле өйрәнелгән. Европалылар аның оригиналлыгын, фәннилеген, фәлсәфилеген хөрмәт итәләр. Россия, Төркия, Азәрбайҗан галимнәре шагыйрь әсәрләрен барлау, текстологик яктан эшкәртү, шәрех-комментарийлар язу, дөньяви һәм фәнни карашларын яктырту, сәнгати фикерләү һәм жанр үзенчәлекләрен тикшерүгә зур игътибар бирәләр. Азәрбайҗан белән тугандаш угыз телле төрекләр дә Гыйракта яшәгән Фөзулине үз шагыйрьләре дип таныйлар. Ул төрекләрнең Урта гасырлардагы һәм Яңа замандагы «Танзимат» («Реформа») һәм «Сәрвәте фөнүн» («Белемнәр хәзинәсе») дип аталган әдәби хәрәкәтләренә дә көчле йогынты ясаган.

Фөзули бөтендөнья әдәбияты тарихында даһи лирик, газәл жанры остасы булып санала. Ул иҗат иткән газәлләр — гашыйк җаннарның йөрәк дулкыннарын үтә дә хисси сурәтләр ярдәмендә гәүдәләндергән шигъри җәүһәрләр.

Татар кешесенә Тукай шигърияте, аның «Туган тел»е ни дәрәҗәдә якын булса, азәрбайҗанлылар өчен Фөзули газәлләре шул дәрәҗәдә кадерле. Моның шулай икәнлегенә мәкалә авторы да шаһит. Узган гасырның 70 нче еллар башында Бакуга әдәби бәйләнышларга багышланган конференциягә баргач та, урамдагы репродукторлардан Фөзулинең гыйшык җырлары даими яңгырап торуы гаҗәпкә калдырды. Анда — Мәскәүдә минем белән бергә аспирантурада укыган Явер Эйвазов гаиләсендә — Йолдыз Нигъмәтуллина белән бергә кунакта да булырга туры килде. Аларның шулвакытта капка төбендә радиокомитеттан килгән төркемнең безне — Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романыннан музыканың шәригать тарафыннан хупланмаган сәнгать икәнен укып белгән галимәләрне — изге Рамазан аенда көпә-көндез кәмәнчәдә уйнап, Фөзули газәлләрен җырлап каршы алулары — гайре табигый хәл иде. Соңлап кына аңладык: сөнниләрдән аермалы буларак, шигыйларда музыканы ислам диненә каршы юнәлтелгән сәнгать дип кабул итү юк икән. Югыйсә, Фөзули үзе дә музыканы кешеләрнең рухын сафландыра, акылларын кайгы-хәсрәтләрдән арындыра торган сәнгать дип раслап, тирән лиризм белән сугарылган, музыка коралларының бәхәсенә корылган «Сәгыйнамә» поэмасын иҗат итмәс иде. Аның фикеренчә, музыка — җир кешеләренә илаһият тарафыннан күкләрдән иңдерелгән Галәм Җаны.

Фөзулинең гыйшык җырларын бары тик Шәрык Ренессансының бөекләре — Сәгъди, Хафиз, Нәвои, Җами газәлләре белән генә янәшә куеп булыр иде. Фөзули фикеренчә, мәхәббәт хисләрен белдерүдә һәр кеше — үз-үзенә падишаһ, солтан, шаһ. Аның лирик герое сөйгән ярын гашыйклыктан акылдан язган Кайс-Мәҗнүнгә караганда да йөз мәртәбә артык ярата, Нәвоинең Ләйлә һәм Ширин өчен үзләрен фида кылган Мәҗнүн һәм Фәрһадтән дә күп дәрәҗәдә өстен куя. Ничәмә-ничә гасырлар үткәч тә, шушы ук мотив Габдулла Тукайның «Мәхәббәт» (1908) шигырендә калкып чыга: *«Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! — мин аларның таңчысы!»*.

Фөзули газәлләренең үзәген матурлык эстетикасы тәшкил итә, ул сурәтләгән җир кызлары — матурлык алиһәләре, шагыйрьне илһамга рухландыручылар. Тукай әйтмешли: *«Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы»*.

Фөзули иҗатында сагышлы мәхәббәт темасы өстенлек итә. Риваятьләр, истәлекләр, элгәреге һәм бүгенге әдәбият белгечләре моның сәбәбен аның гарәп теле укытучысы Хуҗа Рәхмәтулла, йә булмаса, азәрбайҗан шагыйре Хәбиби кызына гашыйк булуда, сөю-сөелү турындагы якты хыялларның тормышка ашмый калуында күрде. Совет чоры галимнәре исә шагыйрь газәлләрендәге кайгы-хәсрәт мотивын урта гасырлардагы социаль шартларның авыр булуы белән бәйләп аңлатты. Чынбарлыкта, Фөзулинең «сагышлы мәхәббәт шаһы» булуының тамырлары бик еракка — гарәпләрнең исламга кадәрге җаһилият дәвере дип аталган поэзиясенә, гозрә кабиләсе шагыйрьләренең әдәби традициясенә барып тоташа иде. Гашыйклык ул — олы кайгы-хәсрәт дигән мотив — Фөзулинең «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасында (1536) пантеистик эчтәлектә һәм әфләтүн мәхәббәте рәвешендә тулы бер концептуаль яңгыраш алды. Азәрбайҗан шагыйренә кадәр бу фаҗигале мәхәббәт темасына Шәрык Ренессанс әдәбиятының даһилары Низами (1188), Нәвои белән Җами (икесе дә 1484 елда дустанә ярыша-ярыша) мөрәҗәгать иткәннәр иде. Галимҗан Ибраһимов фикеренчә, Фөзули Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтен сәнгатьчә сурәтләүдә Шәрыкнең барлык шагыйрьләрен дә узып киткән.

Каһарманнарның үлеме белән тәмамланган бу мәхәббәт тарихы сәнгатьнең барлык төрләрендә чагылыш тапты: Хөсәен Хаҗибәковның «Ләйлә вә Мәҗнүн» операсы язылды, XX гасыр башында ул Истанбул, Баку сәхнәләрендә куелды; мәкалә авторы аны 60-70 елларда Баку һәм Мәскәүдә

«Хадикатес-сөгадаи» («Бәхетлеләр бакчасы») поэмасының кулъязмасы

карау бәхетенә иреште. Мөселман халыклары шигърияте дә бу әсәрнең йогынтысы зур булды. Моның шулай икәнлеген күренекле романтиклар азәрбайҗанлы Вагиф (1717-1797) һәм үзебезнең Дәрдмәнд (1859-1921) шигырьләрендәге мәхәббәт утында янып, күкләргә ашкан Мәҗнүннең Ләйлә үлеме турындагы хәбәрне ишеткәч тә, чүлләрдәге каберлекләрдә елап-сыктап, хәлдән таеп, туфракны иснәп, сөйгәненең каберен эзләп йөрү күренешен хәтерләткән «Хикәяи гыйшык» шигырьләрен искә төшерү дә җитә:

Ни җирдә гыйшык вә сәүдаәләр
*(акылдан язу — **Р.К.**) исе бар,*
Аның шул җирдә кабре…
Шунда ул яр!..

Фөзули — мәрсия һәм касыйдәләр авторы да. Аның иң мәгълүм касыйдәсе «Әнисел-кальб» («Йөрәк дусты») атаклы азәрбайҗан панегиригы Хакани

Ширванины (1120-1199) шул исемдәге касыйдәсенә 45 нче нәзыйрә булып тора. Аның үз заманында дөньяны тетрәткән, бик күп илләр, җир-суларны яулап алган, Госманлы империясенең шанын күтәргән солтан Сөләйманга багышланган касыйдәләре дә бар. Шагыйрьнең касыйдәләре мактау-мәдехтән генә тормый, аларда иҗтимагый-тәнкыйди мотивларга да шактый урын бирелә: тиран падишаһлар фаш ителә, игенчеләрнең тыныч хезмәте яклана. Түбән һәм өстен катламнарга бүленгән җәмгыятьне шагыйрь кабул итми. Аныңча, хәлифәлекләр, патшалар, дәүләт хакимияте тарафыннан югарыда торучыларны түбәннәрдән саклау өчен уйлап чыгарылган. Дәүләт белән диннең төп бурычы — җәмгыятьнең түбән баскычында торучыларны, кыерсытылганнарны өстен катламның рәнҗетүеннән, кысрыклавыннан яклау.

Фөзули — суфи шагыйрь дә. Аның тәсаувыф тәгълиматына багышланган «Сәгыйнамә», «Рәнд вә Заһид» («Кәеф-сафа кылучы һәм дәрвиш»), «Сыйххәт вә мәраз» («Сәламәтлек һәм авыру») кебек пантеистик эчтәлекле әсәрләре фәннилек, фәлсәфилек, сәнгатилек, хиссилек күзлегеннән әдәбиятчылар һәм фәлсәфәчеләр тарафыннан бик югары бәяләнә. Салкын акыл, тән белән яратуны өнәмәгән, әфләтүнчә җан мәхәббәтен генә алга сөргән «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасында да суфичылык мотивлары мул бирелгән.

Фөзули — прозаик та. Гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлар тарихында ул зарлар жанрына нигез салучы буларак та мәгълүм. Аларда ул гомумкешелек кыйммәтләрен яклый, үз заманы өчен хас әхлакый кимчелекләрне, иҗтимагый гаделсезлекләрне, хәтта мохтаҗларга ярдәм итү урыны дип исәпләнгән вакыф җәмгыятьләрендә тамыр җәйгән ришвәтчелек күренешләрен үткен саркастик ирония белән фаш итә. Автобиографик эчтәлекле бу шикаятьләр безнең көннәрдә дә актуальлеген югалтмаган.

Фөзули иҗат иткән зар-шикаятьләр язу традициясе, гасырлар аша үтеп, әдәби жанр буларак яңартылып, Яңа замандагы бик күп төрки әдәбиятларга килеп керә. XIX гасыр — XX йөз башы казах, үзбәк, төрекмән әдәбиятларында зарлар жанры аеруча җанланып китә. Азәрбайҗан шагыйрьләре арадашчылыгында сатирик максатларда зар-шикаятьләр язу Габдулла Тукайга кадәр килеп җитә. Ул да Галиәкбәр Сабир белән Мөхәммәд Һади шигырьләренә «Мулланың зары», «Безне урынсыз яманлыйлар» дигән һөҗүви эчтәлекле нәзыйрәләрен иҗат итә.

Галимҗан Ибраһимовның искәртүенчә, Тукай иҗатындагы дини-фәлсәфи лириканың иң югары ноктасы дип саналган «Мигъраҗ» шигыре дә — Мөхәммәд Фөзулинең шул исемдәге шигыренә тиңдәшсез осталык белән язылган нәзыйрә. Дөрестән дә, шигырьнең тирән дини-мистик эчтәлеге, кайнап торган Берлек — «вәхдәт диңгезе» һәм юкка чыккан җир, вакыт-замана образларының зур шартлау теориясе белән үрелеп бирелүе, өстәвенә, ислам теологиясе, эстетикасы, этикасы өчен хас символларның нур, яктылык сурәтләре ярдәмендә гәүдәләнеше Фөзули белән Тукай арасындагы фәнни, фәлсәфи-дини карашларның бик тә охшаш булуы турында сөйли. Г.Ибраһимов Фөзули иҗаты белән Шәехзадә Бабич шигърияте арасында типологик охшашлыклар булуга да игътибар итте. Аларның һәр икесендә дә акыл белән хиснең тыгыз үрелүенә, ягъни неоплатонизм фәлсәфәсе рухында гәүдәләнүенә басым ясады.

XX гасыр башы — татар әдәбиятының зур сыйфат үзгәрешләре кичергән, Шәрык һәм Гареб мәдәни казанышларын иҗади үзләштергән, Ренессанс-алгарыш дәверенә аяк баскан чор. Бу — әдәби барышның һәр өлкәсендә, шул исәптән әдәбият белемендә дә, аның тарихын, теориясен өйрәнүдә дә, әдәби тәнкыйтьтә дә чагылыш тапты. Татар вакытлы матбугатында, төрле җыентыкларда Фөзули кебек Шәрык даһилары иҗатын өйрәнергә чакырган байтак язмалар дөнья

күрде, тәрҗемәләр күбәйде. Шундый мәкаләләрнең берсе 1912 елда «Шура» журналының 7 нче санында нәшер ителде. Аның авторы — күренекле мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин. Мәкаләсендә ул, тәфсилле итеп, Фөзулинең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыра, шигырьләреннән өзекләр китерә, төркичә шигырь язуда азәрбайҗан даһиының үзбәк шагыйре Нәвоига тиң булуы турында әйтә, аның татар шагыйрьләре Габдерахман Туймөхәммәдкә, Гыясетдин Хәбибуллага, Әбелмәних Хаҗига зур йогынты ясавы турында сөйли, ә Шәмсетдин Зәкине «Идел буеның Фөзулие» дип атый.

XX гасыр башында һәм совет чорында, әдәби-теоретик, тәнкыйди чыгышлары белән Фөзули иҗатына иң еш мөрәҗәгать итүче Галимҗан Ибраһимов булгандыр, мөгаен. Беренчеләрдән булып ул, милли үзлегебезне, Шәрык балалары икәнлегебезне онытмыйча, Гареб һәм Шәрык даһилары иҗатына тигез караш булдырырга өндәде, аурупачыл үзәк (евроцентристик) карашлардан азат булып, «Гомер, Данте, Шекспир кебек Гареб классикасы янәшәсенә утыртып, алларына бердәй тезләнеп», Фөзули шикелле «Шәрык даһиларын искә алырга», аның «Ләйлә вә Мәҗнүн»ен «мәдрәсә көрсиләренә, аннан бөтен татар йөрәгенә» кертеп утыртырга чакырды (Г.Ибраһимов. Әсәрләр. 9 томда. — Т.V. — Б.224).

***

Фөзули кебек бөек шагыйрьләрнең иҗат мирасын татар укучысына җиткерүдә Г.Ибраһимов «мәдрәсәләрдәге әдәбият галимнәренә», «гомумән, әдәбият кешеләренә» зур өметләр баглаган иде. Әмма аның бу изге уйфикерләрен тормышка ашыру тоталитар дәвернең фаҗигаләре аша үткәч кенә мөмкин булды. Алтмышынчы еллар башыннан Казан университетының рус һәм татар филологиясе бүлекләрендә шәрык әдәбиятлары укытыла, гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларның даһилары иҗаты да өйрәнелә башлады. Алар арасында азәрбайҗан әдәбиятының мәшһүр шагыйре Фөзули дә бар иде. Онытасым юк, ярты гасыр диярлек университетта укыту дәверендә имтиханда Фөзулинең фәлсәфи-эстетик карашлары турында иң акыллы, иң тирән җавап бирүче Григорий Родионов булды. Еш кына бу хакта студентларга да горурланып сөйли идем. Еллар үтеп, талантлы шагыйрь Гәрәй Рәхим булып җитешкәч тә, ул кабат азәрбайҗан шагыйрьләрен искә төшерде, алардан шигъри тәлгәшләрен — уңышлы тәрҗемәләрен бирде. «Мәхәббәт мәҗнүне» тәхәллүсе белән танылган Рәдиф Гаташның да сәнгатьчә фикерләү кыйбласын Гаребтән Шәрыкка таба юнәлтүдә азмы-күпме безләрнең дә өлеше бардыр, диюгә җөрьәт итәм.

Хезмәт юлымның байтак сәхифәләре азәрбайҗан әдәбиятын укытуга, студентлар белән бергәләп татар-азәрбайҗан әдәби бәйләнешләрен өйрәнүгә багышланды. Фәнни-педагогик эшнең авыр сукмагына аяк басуда Мәскәү университеты профессоры Азиз Али улы Шәриф тә зур роль уйнады. Фәнни җитәкчем М.И.Богданова кинәт вафат булгач, диссертациямне яклау вакытында күзколак булыр өчен ул Мәскәүдән Казанга да килде. Фөзули иҗаты буенча зур белгеч — монографияләр авторы, шагыйрьнең дүрт томлы әсәрләрен дөньяга чыгаручы академик Хәмид Араслы белән аралашу вә әңгәмә корулар, китаплар бүләк итү, минем Бакуда кунак булуым, алар гаиләсен Казанда кунак итү дә азәрбайҗан әдәбияты турындагы мәгълуматларымны киңәйтте. Болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанын Шәрык Ренессансының титаннары Низами, Фөзулиләр белән янәшә куеп тикшергән докторлык диссертациямә югары бәя бирүче дә азәрбайҗан галиме Ариф Аллаһиар улы Гаджиев булды. Бөек Кодрәт Иясенең миңа шундый фәнни язмыш юллаганына бик тә рәхмәтлемен.

МӘШҺҮР АДӘМНӘР ВӘ ОЛУГ ХАДИСӘЛӘР[1]: ФӨЗУЛИ

Ризаэддин Фәхреддин

FAMOUS PEOPLE AND GREAT EVENTS: FIZULI

Rizaeddin Fahreddin

Төрек кавеме[2] шагыйрьләренең бөекләреннән булган Фөзулинең иseme Мөхәммәд бине Сөләйман[3] булып, атасы Хиллә шәһәренең мөфтисе Сөләйман әфәнде иде. 910/1504тә[4] Кәрбәла шәһәрендә дөньяга килеп, Багдадта шөһрәт тапты вә шул сәбәптән «Фөзули әл-Багдади» дип мәгъруф булмыштыр [танылган].

Солтан Сөләйман Кануни[5] Гыйрак вилаятен фәтех итәр [яулар] өчен сәфәр иттегендә, садыре әгъзам [баш вәзир] Ибраһим паша[6] васитасы [арадашлыгы] илә бәгъзе бер шигырьләрен тәкъдим итеп, мәкъбүлиять кәсеп итте [хуш күрелде].

Бер вакыфтан килмәктә булган хиссасын [өлешен] мәңгы иттеге [туктатуы] сәбәбеннән, вакыф назыйреннән шикаять кылып язмыш бер мәкаләсе бардыр[7]. Фөзули тәхсил [уку] илә мәшгуль булдыгы вакытында Рәхмәтулла исемендә булган остазының кызына мәхәббәте төшеп, шуның фикере илә мәшгуль булмыш вә гарзы мәхәббәт касды [нияте] илә шигырь сөйләргә башламыштыр.

Фөзулинең бөтен хәяте вә гомере хәсрәт вә газап эчендә үтте. Ошбу зар вә моңнарын шигырьләре илә халыкларга хикәят вә тәфһим итәр [белдерер] иде. Мәшәкать вә зәхмәт эчендә яшәдегеннән, фәүкылгадә [гадәттән тыш] хәссәс [сизгер] булды вә бу хәссәслыгы да үзен беренче шагыйрьләр дәрәҗәсенә күтәрде. Моның соңында килмеш төрки шагыйрьләр моңа тәкълид илә [ияреп] шигырь сөйләмешләр исә дә, Фөзули һәрберенең өстендә калмыштыр.

Фөзули, үзенең ана теле булган төркичәдә[8] шигырь сөйләргә моктәдир [сәләтле] булдыгы кеби, фарсыча да сөйләр иде. Төркичә шигырьләрендә икенче Галишер Нәвои[9] саналыр. Нәсерләре дә шигырьләре мәртәбәсендә гүзәл булдыгыннан, мөгаллим Наҗи моның хакында: «Фөзули, кәнди мәсләк мәхсусында нәзыйрсез [тиңдәшсез] булып, һәнүз [һаман да] моның мисле [кебек] килмәмештер», — дияр.

Фөзулинең фикере ачык, сөйләме гүзәл, тәэсирле вә моңлы булмак илә шөһрәт тапмыштыр. Фәкать шигырьләрендә хикмәттән вә суфилык фикерләреннән күбрәк гыйшык, тәсаувыр[10] вә хыял галиб [өстен] идеге дәгъва кылыныр. Моның илә бәрабәр шигый булдыгыннан, фикер җәһәтенчә иранлыларга тәкълид итеп [ияреп], арттыру вә ифратлар илә мавыкты диярләр вә шигырьләрен гаҗәм [фарсы] модасында киенмеш бер төрек кызына тәшбиһ кылырлар [охшатырлар].

Габбасыйлар[11] инкыйразыннан соң, исламнар[12] бөек таг [тау] башыннан иң тирән чокырга тәгәрәп төшмәктә булган олуг таш кебек түбән киттекләре хәлдә, шигырь сөйләмәк тугрысында да артта калмышлар. Хосусан, Гыйракта шигырь тәмамән рәваҗеттән төшмәмештер [юкка чыга]. Хәзрәти Хөсәен маҗараларын вә Кәрбәла вакыйгаларын[13] шигырь илә хикәят итеп мәшгуль булдыкларыннан, гомумән сөнниләргә күрә шигыйларның, бу тугрыда күп алда тордыклары дәгъва кылыныр. Фөзули,

бердән Гыйракта вә, икенчедән, шигый булдыгыннан[14], шигырь сөйләмәк тугрысында олуг мәртәбәләргә ирешмеш булса кирәк. Мәга ма фиһ [шуның белән бергә] ошбу бөек шагыйрьнең кыйммәте үзенең чордашлары тарафыннан тәкъдир ителмәдеге, заманында язылмыш бер «Тәзкирәтеш-шогарә»дә шул вакытның шагыйрьләреннән вә шигырьләреннән озын бәхәсләр ителдеге хәлдә, Фөзули хакында ике-өч юл гына язылып эш тәмам ителендегеннән истидлял [дәлил] кылыныр[15].

Русия исламнарына[16] Фөзули ни вакыт мәгълүм булды вә шигырьләре ни вакыт истигъмаль ителенергә [файдаланыла] башланды? Бабаларыбызның башка хәлләреннән хәбәребез булмадыгы кеби, моннан да мәгълүматыбыз юктыр. Шулай булса да, Русия исламнары арасында аерым затлардан бер чукларының шигырьләре Фөзули өслүбендә булдыгыннан дәлил итеп, боларның Фөзули шигырьләре илә таныш булдыклары вә шул шигырьләрнең өслүбләрен үзләренә үрнәк тоттыклары турында уйларга юл бар. Бу җөмләдән Габдрахман бине Туймөхәммәд, Шәмсетдин Суфи[17], Гыясетдин бине Хәбибулла вә гайреләр. Әбелмәних хаҗи[18], Сәгыйд кыйсбәсендә[19] булган шагыйрьләр (Хаҗи Багдади кеби шагыйрьлектән мәхрүм назыймнар [шагыйрьләр] моннан мөстәсна[20]) Языйчы угылының[21] «Мөхәммәдия»сенә, Лямигыйнең «Гыйбрәтнамә»сенә тәкълид итмеш булсалар кирәк[22].

Рәсеменнән аңлашылдыгына күрә, Фөзули олуг башлы, зур вә үткен күзле, озынча битле, куе сакаллы, кыска сачле, озын мыеклы бер адәмдер.

Әсәрләре: «Хадикатес-сөгадаи», «Сыйххәт вә мәраз», «Диван»[23], «Ләйлә вә Мәҗнүн»[24] вә гайреләр. Һәммә әсәре дә табгы булып нәшер ителмештер.

Фөзули 65 ел гомер сөреп, 975/1567 тарихында вафат булды. Кабере Багдадта[25].

Шура. — 1912. — №7. — Б. 194—195.

***

«— Фөзули диваны бармы?

— Сатылып бетте. Хәзер яңадан бастырабыз, берәр һәфтә [атна] соңында килсәгез, хәзер булыр».

Китапчыдан ошбу сүзне ишетүем илә күңелем шатлык берлә тулды. Фөзули диваны кабат басылачак, имеш! Шигырь гашыйкларын мәмнүн кылачак бу хәбәрдән мин дә шәһәр фәтех иткән [яулаган] гаскәр дәрәҗәсендә сөендем. Ләкин бу сөенеч озак дәвам итмәде, күңелемә килгән ошбу фикер йөрәгемне яндыра башлады: Фөзули диваны яңадан басылачак, ләкин моны кемнәр басачак вә бу әсәр нинди җирләрдә эшләнеп чыгачак? Бу сөальгә биреләчәк җавапны уйлап, газап эчендә калдым.

Борын заманнардан калган иске бер өйнең караңгы бер почмагында тоташтан ютәлләп торучы бер карт мисалында эшләүче иске бер машина, судан яңа гына чыгарылган юеш кәгазьдә, ибтидаи [башлангыч] мәктәптә дәрес алырга мохтаҗ булган бер мосаххих [корректор]… Безнең Фөзулиебезнең диваны, икенче мәртәбә буларак, ошбу рәвеш вә ошбу хәлдә басылып чыгачак.

Инде Фөзулинең гасырдашы булган француз Рабле[26] әсәрләренә дә бер дәфга [мәртәбә] күз салып карагыз! Рабленең бөтен тиражы йөз генә түгел, бәлки берничә йөзләр илә басылып таралып бетте. Һәрбере нәфис сурәттә басылды. Француз байларыннан бере Рабле әсәрләрен тикшерү өчен хисапсыз акча сарыф итте. Иң могтәбәр галимнәрдән гыйбарәт бер мәҗлес, еллар буенча гомер сарыф кылып, моның әсәрләрен тикшерделәр дә, иң соң ысулда ясалмыш машиналар вә маһир эшчеләр тарафыннан эшләнеп, матбугат дөньясына чыкты. Париж халкы бу вакыйганы олуг хадисәләр [вакыйгалар] хөкемендә кылып каршылап алды. Әмма безнең Фөзулиебез диваны, югарыда сөйләдегебез рәвештә, язуны да яхшылап танымый торган мөрәттибләр [хәреф җыючылар] тарафыннан эшләнәчәге мәгълүм. Бичара Фөзули, бәхетсез!.. Фөзули — бәхетсез төрек милләтенең бәхетсез баласыдыр!..

Фөзулинең шигырьләрен укыдыкларында әдипләр хәйран калырлар, моңа сокланырлар. Әгәр дә җир йөзеннән тереклек югалса иде, Фөзули әсәрләре тереклекне яңадан тергезергә куәтлеләрдер.

Фөзули бу көнгә кадәр тиешле дәрәҗәдә җентекләп тикшерелмәде, әсәрләре дә өйрәнелмәде. Бу гүзәллек дөньясы бездән күз күреме кадәр ерак тормактадыр.

Фөзули, тел ясаучы адәм булдыгы өстенә, бик олуг бер шагыйрь, шәйда [акылын җуйган] бер гашыйк, икътидарлы [сәләтле] бер назыймдыр [шагыйрьдер]. Шушы сыйфатларның берәмберәме генә дә Фөзули исемен дөньяда калдырырга җитәрлек булырга тиешле, ләкин бу адәмдә монда зикер ителмәгән бер камиллек бар иде ки, бу башка камиллекләрнең берәм-берәменнән түгел, бәлки бөтенесеннән дә югары дәрәҗәдәдер. Ул исә милләтпәрвәр вә төреклеккә мәфтүн[27] булмакы иде. Хәкыйкать хәлдә [чынлыкта], Фөзули ифрат дәрәҗәдә милләтче иде, төрек телендә[28] әсәрләр язып таратмак тугрысында да яңа бер ишек ачты вә башкаларга үрнәк булды, бик күп төрек галимнәре вә төрек әдипләре төшкән хатага Фөзули төшмәде, бәлки үз телендә көйләде вә үз шивәсе илә җырлады.

Фөзулинең төрекчә сөйләгән[29] әсәрләренең ләззәтлелеген белүчеләр, аның төрекчә сөйләү тугрысында да муаффәкъ [булдыклы] бер адәм идегендә шөбһә итмәсләр.

Фөзули үзенең милләтенә вә теленә гашыйк адәм иде. Төрек милләтенең яшьләре бу адәмне үзләренә остаз итсәләр, ялгышкан булмаслар.

Фөзули хакында булган бу мәкаләне Мөхәммәдгали әфәнде Тәүфикъ тарафыннан «Танин» газетасына язылмыш озын бер мәкаләдән чүпләп алып яздык.

Фөзули, ихтимал ки, күбрәк руханиларны һөҗү кылып [сатирик көлеп] язудан гыйбарәт булган Раблегә караганда бәхетсездер, үзе вә әсәрләре лязим дәрәҗәдә тикшерелмәмеш вә дәрәҗәсе дә тәкъдир кылынмамыштыр. Моның өчен без кайгырабыз, тәәссеф итәбез [үкенәбез] вә кимсенәбез. Шулай булса да, безнең Шәмсетдин Суфига күрә Фөзули, хәтта Рабле дәрәҗәсендә бәхтиярдыр. Һәр никадәр бозык урыннарда, иске машиналар илә өмми [язу белмәүче] хәреф җыючылар эшләсәләр дә, Фөзулинең әсәрләре бу көндә матбуг булып[30] таралды, диваны хәтта икенче мәртәбә табгы ителер, имеш. Инде Фөзули исеме онытылудан, хәтерләрдән чыгудан тәэмин кылынды, Төркиядә никадәр хамидлар [мактаучылар] вә никадәр хәмидләр [мактарга яраклылар] килсә дә, Фөзули һәмишә [һаман] үз урынында торыр, игътибардан төшмәс. Безнең Шәмсетдинебез өчен мондый хәлне хыялга китереп тә булмый. Әгәр дә Мәрҗани хәзрәтләре[31] язып калдырмаган булса иде, бу адәмнең урыны түгел, хәтта исеме дә калмаячак иде.

Тәрҗемәи хәлен «Асар»да[32] язар өчен никадәр вакытлар сарыф итеп вә никадәр мәктүбләр [хатлар] язып, эзләнүебезнең нәтиҗәсе буларак, бәгъзе бер урыннардан берникадәр әсәрләре, касыйдә вә газәлләре, кыйтга вә мөнәҗәтләре җыелган иде. Гаунә [ярдәм] булырлык дәрәҗәдә бәгъзе шәйләрне күчереп, китапның озын булуыннан курыктыгыбыздан, башкаларын ияләренә кайтарып җибәрергә мәҗбүр булдык. Оренбург имамнарыннан Габдрахман исемле бер адәм, бервакыт килеп: «Шәмсетдин Суфи безнең хөрмәтле адәмебез иде (остазыбыз иде дигән шикелле, ләкин хәзер ачык белмим, оныттым), бездә аның байтак әсәрләре бар, сез китаплар бастырасыз, шуның әсәрләрен дә бастырсагыз яхшы булыр иде», — диде. Бастыручы табылмаганлыктан, мәҗбүр булып үз китапларыбызны бастыргаладыгыбызны, башкаларның әсәрләрен нәшер кылырга икътидарыбыз [көчебез] җитмәдеген сөйләп, игътизар кылдык [гафу үтендек]. Хәзер инде бу хәзрәт вафаттыр. Мәзкүр әсәрләр кемнәр кулларында калдыгыннан мәгълүматыбыз юк. Әгәр дә бер һиммәт сахибе[33] чыгып, шушы суфиның барлык әсәрен җыеп бастырса, тәкъдир кылынырлык хезмәт иткән булыр, матди файда күрмәсә дә, мәгънәви файда күрер иде.

Шәмсетдин Суфи, Багдад Фөзулисе булмаса да, Урал-Волга буйларының Фөзулисе идекендә шөбһә юк. Мөгаллимнәребездән Габдрахман Сәгъди[34] бәгъзе шигырьләре илә истишһад кылуында[35] вә Җамалетдин Вәлиди[36] дә Мәрҗаниләрне сөйләгән җирдә моннан һәм беркадәр бәхәс кылуында исабәт итмешләр[37] вә кадерданлык кылмышлардыр.

Инсаннарның дәрәҗәләрен үлчи белмәк — банкротлык күрми торган байлыктыр.

Шура. — 1913. — №11. — Б.350—352.

Искәрмәләр

[1] «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр [вакыйгалар]» — «Шура» журналында сан саен диярлек чыккан рубрика исеме.
[2] Төрек кавеме — төрки халыклар күз алдында тотыла.
[3] Кайбер чыганакларда Мәхмәд бине Сөләйман, русча әдәбиятта Магомед Сулейман оглы Физули.
[4] Фәнни җәмәгатьчелектә кабул ителгән фикер буенча, Фөзули 1494 елда дөньяга килә.
[5] Солтан Сөләйман Кануни (1494-1566) — Госманлы империясенең 1520-1538 еллардагы солтаны, 1538-1566 елларда хәлиф.
[6] Ибраһим паша (1493/1494-1536) — Госманлы империясендә бөек вәзир.
[7] *Сами бәк җәнаплары, ошбу шикаять маддәсеннән дәлил итеп булса кирәк, Фөзулинең Истанбул шәһәренә килдеген хикәят итмеш. Фәкать бу бер зөһулдән [онытылудан] гыйбарәт. Фөзули үз гомерендә Истанбулга килмәмеш вә мәзкүр шикаятен дә Багдадта булдыгы хәлдә язмыштыр. — Р.Ф.*
[8] Шагыйрьнең туган теле — азербайҗан теле.
[9] Алишер Нәвои (1441-1501) — шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе.
[10] Тәсаувыр — сурәтләп күз алдына китерү.
[11] Габбасыйлар — гарәп хәлифәләренең икенче династиясе (750-1258).
[12] Мөселманнар дип укырга.
[13] *Хәзрәти Хөсәен маҗараларын вә Кәрбәла вакыйгалары —* Мөхәммәд с.г.в.нең оныгы Хөсәен бине Гали (626-680) һәм хәлифә Язид отрядлары арасындагы сугыш. Сугышта Хөсәен вафат була.
[14] *Моның шигыйлеге хакында ачык хәбәр юк исә дә, диванында вә башка әсәрендә хәзрәти Гомәрнең исемен зикер итмәдеге ошбу «имеш» хәбәрне бераз тәкъвия кылыр [куәтләндерә]. — Р.Ф.*
[15] *«Тәзкирәтеш-шогарә»нең бәхәс итмеш затлары милләт күңеленнән чыгып, онытылып беттекләре хәлдә, хакында ун сәтыр [юл] кадәр булсын язу кызганылмыш Фөзули исеме җир асларындагы караңгы өйләргә кадәр таралды, тәрҗемәи хәле аталардан балаларга, нәселләрдән нәселләргә күчерелеп торылыр. — Р.Ф.*
[16] Русия исламнарына — Россия мөселманнарына дип укырга.
[17] Шәмсетдин Зәки (Гобәйдуллин Шәмсетдин Ярмөхәммәд улы, 1822—1856) — суфи шагыйрь. Каргалы мәдрәсәсендә укыта. Тумыштан сукыр.
[18] Әбелмәних Каргалый (Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов, 1782-1833) — суфи шагыйрь, Оренбург губернасы Каргалы авылында туа.
[19] Сәгыйд кыйсбәсе — XVIII гасыр урталарында Оренбургтан ерак түгел төзелгән Сәгыйть бистәсе, соңрак Каргалы дип атала башлый.
[20] моннан мөстәсна — монда кермиләр.
[21] Языйчы угылы — Мөхәммәд Чәләби.
[22] *Хаҗи Багдади илә аннан алда искә алынган адәмнәрнең тәрҗемәи хәлләре «Асар»да зикер ителмештер. «Гыйбрәтнамә» исемле әсәрнең бик иске язма нөсхәләре мәмләкәтебездә күрелер. Әбелмәних Хаҗинең «Җиһанның җаһ-малы нәфсә гаять тә хәсәндер бу, / Вәли мәгънан җәһәннәм суигә каид рәсәндер бу» («Дөньяның мал-дәрәҗәсе нәфсегә күркәмдер ул, / Әмма безне җәһәннәмгә сөйри дә кертәдер ул»), — дип башлап сөйләмеш булган шигырьләре тулысынча әлегә «Гыйбрәтнамә» башында булган касыйдәдән алынмыштыр. — Р.Ф.*
[23] Диван — шигырьләр җыентыгы.
[24] *Истанбул шәһәрендә беренче мәртәбә уйналмыш театрода Фөзулинең ошбу «Ләйлә вә Мәҗнүн»е уйналмыштыр. — Р.Ф.*
[25] Фөзули 1556 елда чума авыруыннан вафат була һәм Багдад вилаятендәге Кәрбәла шәһәрендә җирләнә.
[26] Франсуа Рабле (1494-1553) — Ренессанс дәверендәге француз язучысы.
[27] Төреклеккә мәфтүн — төркилекне сөюче.
[28] Төрек телендә — төрки телендә.
[29] Төрекчә сөйләгән — төркичә сөйләгән.
[30] матбуг булып — басылып чыгып.
[31] Мәрҗани хәзрәтләре — тарихчы һәм имам Шиһабетдин Мәрҗани.
[32] «Асар» — Ризаэддин Фәхреддиннең шул исемдә берничә томлык биобиблиографик әсәре.
[33] һиммәт сахибе — эшләргә теләүче кеше.
[34] Габдрахман Гайнан улы Сәгъди (1889-1956) — әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор.
[35] истишһад кылу — цитаталар китерү.
[36] Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов (1887-1932) — тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.
[37] Исабәт итмешләр — дөреслеккә ирештеләр.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин****и әзерләде*

The text was prepared to publish ***Lenar Gubaydullin***

ФӨЗУЛИ

FIZULI

***

Алтын патша — кешеләрен сатып ала көмеш белән,
Никадәрле гаскәр туплый, алырга бер мәмләкәтне!
Йөз мең хәйлә, мәкер белән аны яулап алса да ул,
Урнаштыра алмый тынлык, тырышса да тик нихәтле.

Язмыш беркөн әйләнә дә, һәлакәтле шул сәгатьтә
Һәлак була патша үзе, мәмләкәт һәм күпме кеше.
Карагыз: мин дәрвиш-патша, гаскәрләрем — сүзләр минем.
Җиңү өчен шул күкрәүле сүзләрдән мин алам көчне.

Һәрбер сүзем — алып батыр, көч ала ул хакыйкатьтән,
Теләсә, ул буйсындыра диңгезне һәм коры җирне.
Кая гына җибәрсәң дә, кызыкмый дан һәм байлыкка,
Беркемне дә ябып куймый, алгач та ул яулап илне.

Дөньядагы бернинди көч чыгаралмый аны юкка
Һәм язмышның тәгәрмәче калдыралмый аны аста.
Бирмәсен бер дәрәҗә дә миңа дөнья патшалары,
Тыйнак кына итеп үргән үз таҗым бар минем башта.

Бар нәрсәдә ирекле мин! Син тыңлаучым, кем булсаң да,
Фанилыкка хезмәт итмә икмәк өчен беркайчан да!

***

Серен халык йөрәгенең, ачып, безгә аңлата сүз.
Тик туктаусыз такылдаудан дәрәҗәсен югалта сүз.

Гакыллы һәм бөек сүзләр күтәрәләр безне күккә,
Нинди түбән кешедә дә бөек хисләр кузгата сүз.

Канат куй син сүзләреңә, йоклатканчы сине үлем,
Бу дөньяның йокысыннан кешеләрне уята сүз.

Көчле сүз — ул гүзәл ярның карашыдай якты була,
Йөзендәге пәрдә аша, балкып, күзен уйната сүз.

Бу дөньяның барлык яшерен хәзинәсен саклаучы ул.
Серле мең-мең хәзинәне кем дөньяга чыгарта? Сүз!

Йөзсәң гыйлем дәрьясында, аңларсың: тән — бер сәдәф ул,
Балкып шул тән уртасында энҗе кебек, ни ята? Сүз.

Тик, Фөзули, исеңдә тот: көч түгел күп сүзлелектә, —
Бик акыллы сөйләүдә дә артык була кайчакта сүз.

***
Язмыш — усал, дуслар — көчсез, алдавыч — заман.
Юк ярдәмче, тирә-якны дошманнар сарган.

Тик дәрт яна кояш төсле, ул да өметсез,
Намуссызлар — югарыда, намуслы — ауган.

Җуя бара көчен акыл, ә вөҗдан — куркак,
Сөю артса, кайгы арта, калышмый аннан.

Юк хакыйкать, үз ватаным читсетә мине,
Урап алган бу дөньяны мәкер һәм ялган.

Күңел өчен җәберләрнең чишмәсе һәр кыз,
Һәр каш — гүя үткен урак: аера җаннан.

Безнең белем — җил селкеткән зәгыйфь мәк кебек,
Чәчәк күк ул, суда чагылып, төсен югалткан.

Теләк — чикле, ирешкәнче ләкин аңар да,
Үтәсең син күпме газап, күпме сынаудан!..

...Дусларым юк, мәҗлесләрдән качам еракка,
Кем күрсәтер миңа юлны? Ялгыз мин һаман.

Җыерчыгын Фөзулиның арттыра кайгы,
Йөзе аның шуңа сулган, шуңа саргайган.

***
Ник кушасың, мәрхәмәтсез,
Баш тартырга яшәвемнән?
Яндырдым мин, аһлап, күкне, —
Кабыздыңмы миңа бер шәм?

Бүтәннәргә дус карыйсың,
Һәрбер чирне дәвалыйсың.
Мине нигә аямыйсың?
Сорашмыйсың ник хәл миннән?

Җаным һәр төн елап чыга,
Аһлап, шашып, җырлап чыга,
Тынгы бирми йоклаучыга, —
Күңлең кайчан ишетер икән?

Юар идем синең йөзең
Саф күз яшем белән үзем.
Чәчәк басты дөнья йөзен, —
Сизмисеңме шуны, иркәм?

Фаш итмәдем кайгымны мин,
Синнән ләкин сер яшермим.
Тыңлыйсыңмы җырым, — белмим, —
Борыламсың, көлеп миннән?

Мин түгел, син гашыйк иттең,
Сине күрми яшәү читен.
Күргәндә бу нурлы битең,
Мин гайбәттән куркыйм нидән?

Фөзулига шунсы хурлык:
Калды илгә көлке булып.
Карап баксаң, читтән торып,
Гыйшык инде үтми микән?

Әхмәт Исхак *тәрҗемәләре*
Translator ***Ahmet Ishak*** ■

ТАТАР-ТӨРЕК ӘДӘБИ БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ ЯССЫЛЫГЫНДА ТУКАЙ ИҖАТЫ*

Хатыйп Миңнегулов

TATAR TÜRK EDEBİ İLİŞKİLERİ BAĞLAMINDA ĞABDULLA TUKAY'IN ESERLERİ

Prof. Hatip Minnigulov

Дөнья сүз сәнгатендә 30 яшькә дә җитмичә бай иҗат мирасы калдырган, тарихка кереп калган талантлы затлар күп түгел: Марк Анней Лукан (б.э. 39-65), Шелли (1792-1822), Михаил Лермонтов (1814-1841), Николай Добролюбов (1836-1865), Шәехзадә Бабич (1895-1919) ... Тукай да – әнә шулар рәтендәге бөек шагыйрь.

*«Төрки дөньяны таныткан шәхесләр: Меһмәт Акиф Ирсой һәм Габдулла Тукай» темасына багышланган халыкара симпозиумда укыласы доклад (Казан федераль университеты, 15-17. 05. 2014)

...Миңа 1962-1963 нче уку елында Пенза өлкәсенең Качкару (Кутеевка) авылында укытучы булып эшләргә туры килде. Шул вакытта мин укучыларны Качкарудан ерак булмаган Олы Тарханга берничә мәртәбә экскурсиягә алып бардым. Андагы Лермонтов музеен күреп исем-акылым киткән иде. Шунысы хәтердә калган: бай тормышлы әбисе үзенең оныгы өчен бөтен шартларны тудырган икән. Тәрбиячеләрдән тыш, булачак шагыйрьгә чит телләрне 5-6 укытучы өйрәткән. Ә бит Тукайның матди тормышын болар белән чагыштырырлык та түгел: ятимлек-үксезлек, фәкыйрьлек, кулдан-кулга йөрү, сырхаулык, милли хокуксызлык...

Җиһанның әссесен, салкын,
бозын күрдем, карын күрдем;
Ниләр күрсә бөтен үксез — барын
күрдем, барын күрдем [1, Т.2, 247].

Бу юллар иҗади хыял җимеше генә түгел, ә ачы хакыйкатьнең, кырыс чынбарлыкның объектив гәүдәләнеше дә.

Әмма татарның бу бөек баласы, үз элгәрләре Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834), Акмулла (1831-1895) кебек, сынмаган да, бөгелмәгән дә. Күренекле әдип һәм мәгърифәтче Таҗеддин Ялчыгол (1763/1768-1838) «Рисаләи Газизә» (1806) исемле китабында, үз укучысына дәшеп, болай ди: «... сән хурлыкда калдым диб, «вай» димәгел, нитәк ки чынаякны күп тибкән вә баскан балчыкдан ясыйлар» [2, 339]. Тукайны тормышта очраган сынаулары рухи яктан ныгыта гына барган. Гадәттән тыш кыен шартларда әдипнең 5-6 томлык әсәр язуы, мәгърифәт, мәдәният өлкәсендә дөнья кадәр эшгамәлләр кылуы үзе зур батырлык вә фидакярлек. Инде шагыйрьнең вакытлы йорттан мәңгелеккә күчеп китүенә дә 100 елдан артык вакыт үтте. Шушы чор эчендә аның иҗаты онытыла бару түгел, киресенчә, яңгырашын, тәэсир көчен арттыра гына барды. Күп

TATAR TÜRK EDEBİ İLİŞKİLERİ BAĞLAMINDA ĞABDULLA TUKAY'IN ESERLERİ

Ğabdulla Tukay(1886-1913) yüzlerce yıllık Tatar söz sanatının büyük şairidir. Onun eserleri milli ve insancıl bir ruhla yoğrulmuştur. Ğ.Tukay'ın zirveyi tutmasında başta Allah vergisi kabiliyeti, sosyal ve tarihsel şartlar, yaşadığı devir, kültürel ilişkiler ve yüzyıllara uzanan Türk Tatar ilişkileri de önemli rol oynamıştır. Ğabdulla Tukay Türkiye Türkçesi'ne Osmanlı Edebiyatı'na ileri derecede vakıftır. İstanbul'daki siyasi, içtimai, kültürel ve tarihsel hadiselerden haberdardır. Bunlar eserlerine açık bir şekilde yansımıştır. Şair onlarca şiirini Türk söz sanatındaki eserlere dayanarak yazmıştır. Ğ.Tukay'ın adı, eserleri Türk Milleti tarafından uzun zamandır bilinmektedir. Meşhur Türk Edebiyatçısı Fuat Köprülü Ğabdulla Tukayev adlı mersiyevi makalesinde (1913) Tatar Şairini «Yüce ve fedakâr zatlar» listesine dahil etmiştir. Son yüz yılda Ğabdulla Tukay'la ilgili Türkçe pek çok makale yayımlanmış, eserleri Türkçe'ye çevrilmiştir. Örneğin 1994 yılında Fatma Özkan'ın imzasıyla Ankara'da yayımlanan Ğabdulla Tukay'ın şiirleri adlı bin sayfalık kitapta, şairle ilgili ilmî monografi ve şiirleri Türkçe çevirisiyle birlikte yer almıştır.

мәртәбәләр нәшер ителү, төрле телләргә тәрҗемәләре, йөзәрләгән фәнни хезмәтләр язылу, уку йортларында өйрәнелүе — шуның ачык мисалы.

Тукай өчен шигърият, әдәби иҗат — бөтен яшәешенең асыл максаты, мәгънәсе. 1911 елның 15 ноябрендә Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында ул болай ди: «Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора. Миңа хәзерге вакыт кадерле» [1, IV т., 320]. Шагыйрь, ничектер, үзенең гомере кыска буласын тоя. Шуңа күрәдер ул күңелендәге уй-хисләрне, илһам җимешләрен кәгазьгә төшерергә омтыла, еллык эшне айда, атналыкны бер көндә эшли. Чорыбызның бөек язучысы Чыңгыз Айтматов фикеренчә, Тукай, әйтерсең, «27

ел түгел, ә 270 ел яшәгән кебек күзаллана» [3, 32].

Тукай иҗаты гаять киң һәм күпкырлы. Ул шагыйрь һәм прозаик та, публицист һәм тәрҗемәче дә. Аларның һәммәсен миллилек һәм инсанилык, әдипнең көчле таланты, шәхси фикерләү үзенчәлеге берләштерә. Шагыйрь дөньяга, һәр нәрсәгә татар күзе белән карый, бәя-фикерләве дә аның шул ноктадан. «Чорт белә, — ди ул бер язмасында, — мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче… Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам!» [1, IV т., 314]. Гомумән, милләткә хезмәт итү, татар тәрәккыяте өчен көрәш — Тукай иҗатының асылы, җаны.

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид (бәйле. — Х. М.)*, милләтем;*
Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер (авыруың. — Х. М.) *гыйлләтем.*
Сән мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә (каршымда. — Х.М.) *варлык нәрсәдән;*
Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем
(Милләтне һәм миллиятемне дөнья бәрабәренә дә сатмам).
[1, I т., 316—317]

Татарлар һәм төрекләр — кардәш халык. Аларның этник (төрки) чыгышында, яшәеш тарихында, телендә, сүз сәнгатендә күп кенә уртаклыклар, охшашлыклар бар. Борынгы төрки әдәбият, тел, фольклор һәр ике кавемнең милли сүз сәнгатендә нигез, башлангыч булып тора. Озын-озак вакыт агышында алар теге яки бу дәрәҗәдә үзара аралашып, керешеп, рухи байлыкларны уртаклашып торган, бер-берсенә йогынты ясаган. Болгар һәм Алтын Урда сүз сәнгатенең сәлҗүк-госманлыларга тәэсир итүе билгеле. Уртак әдипләребез дә бар [Өммикәмал (XIV йөз ахыры — 1475), Гашыйк Гомәр (1621-1707) һ.б.]. Төркиянең соңгы дәвер иҗтимагый, гыйльми, мәдәни тормышында татарларның да зур роль уйнавы мәгълүм. Аларның исемнәрен генә атау да күп нәрсә хакында сөйли (Исмәгыйль Гаспралы (1851-1914), Муса Акъегетзадә (1864-1923), Йосыф Акчура (1876-1935), Садрый Максуди (Арсал) (1878-1957), Гаяз Исхакый (1878-1954), Габделбарый Баттал (1883-1969), Рәшит Рәхмәти (Арат) (1900-1964), Әкдәс Нигмәт (Курат) (1903-1971), Әхмәд Вәли Мәңгәр (1881-1978), Хәмит Зөбәер Кошай (1897-1984), Әхмәд Тимер (1912-2004) һ.б.).

Алты гасырдан артык (ягъни XIV йөз башларыннан) яшәгән Госманлы империясе дөньядагы иң зур, кодрәтле мөселман дәүләтләренең берсе була. Анда фән, сәнгать, әдәбият зур үсеш ала, борынгы төрки традицияләр уңышлы дәвам итә, Шәрык, Гареб рухи казанышлары иҗади үзләштерелә. Татарларга һәм кайбер башка төрки халыкларга гарәп-фарсыларның һәм аурупалыларның (аеруча Танзимат чорыннан) язма истәлекләре, әдәби-эстетик хәзинәләре төрекләр аркылы керә. Болар арасында, мәсәлән, «1001 кичә», «1001 көн», «Тутыйнамә», «Кабуснамә», «Әбугалисина» кебек китаплар, Даниэль Дефо, Жюль Верн һ.б. мәгълүм әсәрләре бар. Госманлы әдәбиятының Гашыйк Паша (1271-1332), Әхмәди (1329-1413), Мөхәммәд Чәләби (Язычыуглы) (?-1451), Әхмәд Мидхәд (1844-1913) һ.б. авторлары татар дөньясында аеруча билгеле булалар. Күп кенә татар зыялылары Истанбулда белем ала. Төркиядә нәшер ителгән газета-журналлар да Идел-йортка барып ирешә. Татар язма теленә күпләгән госманлы сүзләре һәм формалары килеп керә. Татарның тәүге драма әсәрләре, реалистик проза үрнәкләре тууда һәм үсүдә дә төрек сүз сәнгатенең роле зур [4; 5].

Тукай нәкъ менә шундый иҗтимагый, мәдәни шартларда әдәбиятка килеп керә һәм шагыйрь буларак формалаша. Аның төрек телен, әдәбиятын

яхшы белүе мәгълүм. Җаекта яшәү елларында Тукайның Истанбул университетында белем алган төрек студенты Габделвәли белән шәхси дуслыгы да госманлы сүз сәнгате белән кызыксынуын арттыра.

Тукай эшләгән «Ялт-йолт» журналының 1911 ел 21 апрель санында Истанбулда 1862 елдан бирле чыгып килгән «Тасвири әфкяр» газетасыннан алынган бер төрек рәсеме урнаштырылган. Аның астында шагыйрьнең «И төрек...» дип башланган фәрде дә бар [1, II т., 173]. Соңгы дәвер төрек тарихында Мөлхимә исемле пашаның, дипломатның эшчәнлеге тискәре бәяләнә. «Авыл җырлары» бәйләмендәге бер бәеттә шагыйрь бу затны менә ничек тасвирлый:

Мөлхимәләр балдагы төрек
халкын алдады:
Алдаласа алдаласын,
үкенечкә калмады [1, II т., 182].

XX йөз башы Төркия тормышына иҗтимагый-сәяси тотрыксызлык хас. Бу уңай белән Тукай 1911 елда болай яза: «Төркия янгын эчендә: монда ут һәм анда ут» [1, II т., 165]. «Тегеннәншуннан» исемле публицистик язмасында (1912) автор бу илнең хәлен «хәстә», «авыру» кеше халәте белән тиңли [1, IV т., 223].

Тукайның дистәләгән әсәре госманлы шигъриятеннән файдаланып иҗат ителгән. Шагыйрь үзе дә аларның «төрекчәдән» булуын искәртә: «Урланган мәгънә» (1908), «...Тән үстерсәң — җиһанда...» (1910), «Сөйгәнемне мин кочам дип...» (1909) һ. б.

Мәгълүм ки, М.Чәләбинең «Мөхәммәдия» исемле зур күләмле шигъри китабы (1449) татар дөньясында бик яратып укыла, көйләнә. Казанда ул күп мәртәбәләр нәшер ителә, уку йортларында өйрәнелә, татар сүз сәнгатенә зур йогынты ясый. Тукай да бу әсәрдәге аерым сурәтләрне, шигъри детальләрне файдалана, еш кына аның аерым өлешләренә нәзыйрә яза, җитди эчтәлекле юлларны сатира объектына әйләндерә («Мөхәммәдия»дән», «Диде Камил ки...», «Мөхәммәдия» көе», «Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш...»). Тукайның «Ысулы кадимче» поэмасы (1908) — стильләштерү, нәзыйрә алымын кулланган пародия язуның күркәм бер үрнәге. Чәләби дастанының «Сәбәбе тәэлифе китаб...» өлеше болай башлана:

Мәгәр көнләрдә бер көн әмр-е тәкъдир
Утырмышдым Кәлибуллида сирра (яшеренеп. — Х. М.).
Әлеме чикмеш идем җөмлә халкдан,
Дилемдә зикер иде, кальбемдә зикра [5, 121].

Тукай да үз поэмасын нәкъ «Мөхәммәдия»дәге текстка охшаш вәзен, кафия, сүзләр белән башлый, әмма шигъри юлларга сатирик эчтәлек сала:

Мәгәр көннәрдә бер көн,
әмре трахтир,
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.
Кулымны селтәдем фани җиһаннан,
Агызда папирус, алдымда сырра (сыра. — Х. М.).

Тукайның башлангыч чор иҗатында язылган шактый гына шигырьләре ярым госманлы, ярым татар телендә. Аларда төрек сүз сәнгатеннән алынган образ-детальләр дә еш очрый. Бу уңай белән Г.Ибраһимов үзенең «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә (1913) менә нәрсәләр яза: «Тукайның беренче адымнары, гомумән, беренче дәвере, нинди агым тәэсирендә булганын белү өчен һичбер мәшәкать сарыф итәргә мәҗбүр булынмый. Ул дәвердә язганнарында госманлы әдәбияты да күренә, ләкин иң көчлесе «Мөхәммәдия»дер... Шуның өчен Тукайның бу язуларын тудырган заманны «Мөхәммәдия» дәвере дип атау бер дә хаксыз булмас иде» [6, 117].

Тукай исеме, аның шигырьләре үзе исән вакытта ук Төркиядә билгеле бер дәрәҗәдә мәгълүм була. Күренекле төрек әдәбиятчысы Фуад Көпрелезаденең (1890-1966), шагыйрь үлеме уңае белән, «Төрек йорды» журналының 1913 елда басылган мәрсияви эчтәлекле «Габдулла Тукаев мәкаләсе (13. 05. 1913) — шуның ачык бер билгесе. Язма авторы шагыйрьне «олуг һәм фидакяр шәхесләр» исемлегенә кертә [7, 124].

Тукай вафатыннан соңгы йөз ел вакыт эчендә төрек дөньясында шагыйрьгә мөнәсәбәтле шактый гына язмалар дөнья күрде, аерым әсәрләре оригиналда яисә тәрҗемәләрдә басылып чыкты. Бу эштә аеруча Төркиядәге милләттәшләребезнең гамәлләре игътибарга лаек. Узган гасырның урталарыннан алып, Кече Азиядә «Тукай гәнечлек (яшьләр. — Х.М.) клубы» эшли. Анкарада «Тукай бәйрәме» исемле брошюра да дөнья күрә (төзүчеләре — Гали Акыш, Сәйдә Арсланбәк). Анда Наилә Бинаркның «Тукайның вафаты» исемле драма әсәре дә бар. 1965-1968 елларда «Тукай бюллетене» исемле кечкенә мәҗмуга чыгып килә [8, 213-215]. Төркиядә 1970-1980 елларда нәшер ителгән «Kazan» журналында Тукайның «Шүрәле», «Таз», «Теләнче», «Нәсихәт», «Су анасы» һәм кайбер башка шигырьләре төрек һәм татар телләрендә дөнья күрә [8, 210-233]. Шушы ук мәҗмугада Тукай турында да дистәләгән язмалар бар (Әхмәд Тимер, Надир Дәүләт, Наилә Бинарк һ.б.).

Төрек галимәсе Фатма Өзкан 1992 елда «Габдулла Тукай шигырьләре» темасына докторлык диссертациясе яклый. 1994 елда ул шушы хезмәтне Анкарада аерым китап итеп бастырып чыгара (958 битлек). Анда, фәнни монографиядән тыш, Тукайның барлык шигырьләре диярлек оригиналда һәм төрекчәгә тәрҗемәдә бирелгән (113-951 б.). Ахырда Тукайга мөнәсәбәтле бай библиография дә бар [9, 28-37].

Соңгы елларда Төркиядә нәшер ителгән антология-хрестоматияләрдә, Ататөрек Культур Мәркәзе чыгарган 33 томлык төрки әдәбиятлары турындагы китапларда, шулай ук көндәлек матбугат битләрендә Тукайга мөнәсәбәтле шактый гына язмалар, әсәрләренең аерым тәрҗемәләре бар. Бүген бөек шагыйребезне төрек дөньясына җиткерүдә үзебезнең татар кызына өйләнгән Фатих Кутлу аеруча нәтиҗәле эшли. Тукайның һәм дистәләгән башка татар әдипләренең әсәрләре, аның тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә бер-бер артлы басылып тора.

Татарның җаны, рухи яшәеше белән тыгыз бәйләнешле Тукай халкыбызның символына, даими юлдашына әверелде. Аның шундый дәрәҗәгә ирешүендә күпгасырлык төрек-татар бәйләнешлары, Кече Азиянең, Истанбулның озынозак тарихлы бай мәдәнияте мөһим роль уйный.

Әдәбият

1. Габдулла Тукай әсәрләре: Дүрт томда. — К.: Татар.кит.нәшр., I т., 1975. — 432 б.; II т., 1976. — 400 б.; III т., 1976. — 417 б; IV т. — 1977. — 431 б.
2. Китабе «Рисаләи Газизә». — СПб., 1847.
3. Слово о Тукае. Писатели и учёные о татарском народном поэте / Сост. Ф.Зулькарнаев. — Казань: Таткнигоиздат, 1986. — 431 с.
4. Бу хакта тулырак мәгълүматлар: Хатип Миннегулов. Записи разных лет. — Казань: Идел-Пресс, 2010. — 407 с. («О татарско-турецких взаимосвязях», «Об Ахмеде Мидхаде» мәкаләләре. — С.174-187, 191, 278-279); Х.Й.Миңнегулов. Гасырлар өнен тыңлап… — Казан: Мәгариф, 2003. — 335 б., («Тукай һәм Шәрык әдәбияты» 152-162 б.) һ. б.
5. Мөхәммәтов И.Р. Татар-төрек әдәби бәйләнешлары яссылыгында «Мөхәммәдия» китабы / Фәнни редакторы: Х.Й.Миңнегулов. — Казан, 2007. — 136 б.
6. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда: T.V. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. — 615 б.
7. Күпрүлезадә. Габдулла Тукаев // Казан утлары. — 2009. — № 4. — 115-124 б.
8. Миңнегулов Х. Дөньяда сүземез бар… — Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. — 336 б. [«Казан» һәм «татар» — аерылмас төшенчәләр» (210-233 б.); «Исламбул»ны мин дә күрдем» (233—257 б.) һ.б. язмалар].
9. Миңнегулов Х. Татарга теләктәш төрек галимәсе (Фатма Өзкан турында) // Мирас. — 1997. — №8. — 28-37 б. ■

ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ КЫРЫМ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

Илсөяр Рәмиева

TUKAY'S WORKS IN CRIMEAN TATAR LANGUAGE

Ilsiyar Ramieva, associate professor of Okan University

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң социалистик режимга күчкән Румыния республикасының Төркия белән булган мөнәсәбәтләре шактый катлаулана. Бу сәбәпле Румыниянең көньяк-көнчыгышында — Добруҗада яшәгән, чыгышлары белән Кырымнан булган татарларның урта мәктәпләрендә укыту өчен кулланылган төрекчә китап-дәреслекләр китертүгә чик куела. Кырым татар мәктәпләрен дәреслекләр белән Казаннан тәэмин итә башлыйлар. Ләкин Казан дәреслекләре буенча да укыту шактый зур кыенлыклар тудыра. Шул ук вакытта, киләчәкне күздә тотып, Татарстанга югары белем алу өчен берничә кеше дә җибәрелә. Ләкин бу чара тиешле нәтиҗә бирми. Шунлыктан Добруҗада 1837 елдан бирле эшләп килгән, элекке Бабадаг мәдрәсәсенең дәвамы булып торган Мәҗидия мәдрәсәсе укытучылары һәм Румыния университетларында белем алган белгечләр бергәләп кырым татар телендә дәреслекләр язу эшенә керешә.

Шундый китапларның берсен укытучы Таһсин Ибраһим (1903-1972) әзерли. Кырым татар телендә әзерләнгән «Уку китабы»нда Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Афзал Шамов, Кави Нәҗми, Муса Җәлил кебек татар шагыйрьләренең һәм язучыларының әсәрләре урын алган. «Уку китабы»на Таһсин Ибраһимның үзе язган «Кабак» исемле шигыре дә кертелгән.

«Уку китабы»нда Габдулла Тукайның әсәрләренә шактый зур урын бирелә. Монда Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәренең беренче бүлеге, «Сабыйга», «Эшкә өндәү», «Баскыч», «Кәҗә белән сарык» шигырьләре, атаклы «Шүрәле»се кырым татар теленә тәрҗемәдә урнаштырылган. Әсәрләр Габдулла Тукайның 1955-1956 елларда Казанда дүрт томлы итеп чыгарылган «Әсәрләр»еннән алынган.

«Уку китабы»на кертелгән тәрҗемәләр Таһсин Ибраһим тарафыннан әзерләнгән. Тәрҗемә вакытында әсәр билгеле бер үзгәрешләр кичерә, тәрҗемәче үзеннән өстәмәләр дә кертеп җибәрә. Мәсәлән, Таһсин Ибраһим, «Кәҗә белән сарык» әсәрен берникадәр әдәби эшкәртеп, үзеннән бер кушымта да тәкъдим итә. Бу кушымтада әсәргә һәм тасвирланган вакыйгаларга мөнәсәбәт белдерелә. Автор Шүрәлене, кырым татар укучысы күзаллавына якынайтып, «Урман җене» дип тәрҗемә кыла. «Исемдә калганнар» документаль әсәрен исә, ирекле тәрҗемә итеп, балалар өчен аңлаешлы хәлгә китереп, иҗади эшкәрткән. Кыскасы, «Уку китабы»ндагы кырым татар теленә ирекле тәрҗемәләр Габдулла Тукай әсәрләренең аһәңен, гомуми эчтәлеген, шигъри яңгырашын бозмый.

Тукай иҗаты бөтен төрки халыклар өчен аңлаешлы һәм якын, уртак әдәби-мәдәни мирас ул! XX гасырның социаль-сәяси шаукымнары, үзгәрешләре төрки халыкларны бер-берсеннән шактый ераклаштырса да, уртак әдәби-мәдәни мирас аларның якынлашуына хезмәт итә. И.Таһсиннең бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатыннан тәрҗемәләре дә шушы изге вазифаны үти.

Әдәбият

İbrahim Tahsin. Türkin öz qardaşı. – İstanbul, 2008. — 150 б. (кырым татар телендә). ■

ҮЗБӘК ӘДӘБИЯТЫНА ҮЗ ӨЛЕШЕН КЕРТҮЧЕЛӘР

Лирон Хәмидуллин

THE ONES WHO DOES ITS BIT TO UZBEK LITERATURE

Liron Khamidullin

Сулдан уңга: Абдулла Уразаев, Әсгать Мәҗит, Галия Нигъмәтуллина, Галия Булатова һәм Һади Такташ. Казан. 1927 ел

Безгә кардәш үзбәк халкы хәзер билгән җирләр иң борынгы дәверләрдән бирле төрки кабиләләр биләмәсе булган. 1940-1950 елларда шул төбәкләрдә археологик эзләнүләр эшен башкарган күренекле тарихчы, академик Сергей Толстов Бохара белән Сәмәрканд шәһәрләрен төркиләр нигезләвен дәлилләп язган иде. X гасырга караган кульъязмаларга һәм археологик табышларга таянып дәлилли ул аны.

Менә шушы бик борынгы чордан бирле төрки кавемнәр гомер кичергән төбәк белән безнең бабаларыбыз элек-электән аралашып яшәгән. Мәсәлән, IX-XII гасырларда ук, әле Европаның күпчелек илләре наданлыкта яшәгән дәвердә, Урта (Үзәк) Азия төбәкләрендә фән, гыйлем үсеше, әдәбият, мәдәният үсеше алга киткән була. Әбугалисина, Әл-Бируни, Әл-Хәрәзмиләр фәннең төрле өлкәләрендә ачышлар ясыйлар. Җирнең кояш тирәли әйләнү күренешен дә иң әүвәл шәрык астрономнары ачканлыгын раслаганлыгы турында фикерләр дә бар. Аксак Тимер әмир оныгы Олугбәк Сәмәрканд янәшәсендә ачкан зур обсерватория дә Урта Азиядәге беренче генә обсерватория булмаган. Бируни, Хәрәзмиләр — күктәге

йолдызларның торышын һәм хәрәкәтен билгеләүне исәпләүче формулаларны нигезләүчеләр. Космоска очу дәверендә шул формулаларны куллану турында академик П.Н.Федосеев та язган иде. Менә шундый төбәк ул Урта (Үзәк) Азия. Академик С.П.Толстов борынгы Хәрәзем мәмләкәтен бөек Шумер дәүләтенең дәвамчысы булган, дип тә фараз итә…

АКШның Индиана университеты галиме Аллен Франк Урта Идел буендагы болгар-татарлары Хәрәзем һәм Урта Азиянең башка төбәкләре белән мәдәни һәм сәүдә мөнәсәбәтләрен X йөзләрдә үк башлап җибәргәннәр, дип белдерә. Әйе, шул төбәктәге ил һәм ханлыклар белән бабаларыбызның аралашып яшәвен дәлилле торган мисаллар байтак. «Кыйссаи Йосыф» дастанын иҗат иткән Кол Галинең XII йөз ахырларында шул җирләрдә укып йөргәнлеге мәгълүм. Әбүгалисина, Хәрәзми, Фәраби кебек белем ияләренең кулъязма китаплары Идел-Урал төбәкләрендә археографлар тарафыннан табылуы шул ук фикерне раслый.

Соңрак дәверләрдә, әле ул яклар Россия империясенә буйсынмаган заманда, XVIII-XIX гасырның беренче яртысында, Бохара, Сәмәрканд, Ташкент мәдрәсәләрендә укып кайткан шәхесләребез дә ишле генә булган. Аларны бер утыруда санап та бетерерлек түгел. Ул исемлектә Оренбург төбәгеннән чыккан шагыйрь Әбелмәних Каргалый да, патша Россиясендәге иң тәүге рәсми мөфтиебез Мөхәммәтҗан Хөсәенев тә бар. Үзе дә Бохара белән Сәмәркандта белем эстәгән Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани, беренче мөфтинең бабасы Мансур бине Габдеррәхим бине Әнәс әл-Җәбәли әл-Борындыкыйны да Бохарада укыган һәм шунда укыганда «Тәракыйбе Мансурия» китабын язган, дип белдерә. Әйе, Бохара, Сәмәркандларда укыган шәхесләребез байтак. Шундагы мәдрәсәләрдә укыган кайбер шәкертләрнең мирасын беләбез дә шикелле. Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави, Әбелмәних Каргалый, Габдерәхим Утыз Имәни шундыйлардан.

Алда исемнәре аталган шәхесләрнең беришe, шул исәптән беренче мөфтинең бабасы да, ерак төбәктәге мәдрәсәләргә кача-поса гына барып укый алганнар. Казах, Хива ханлыклары аша Россиядән Ташкент тарафына беренче рәсми кәрван 1739 елда юлга чыккан, дип хәбәр итә Аллен Франк. Беренче кәрваннар казах ханлыклары чиге буенда, Җаек елгасының урта бер өлешендә урнашкан Орск каласыннан озатылганнар. Соңрак андый кәрваннар ике-өч елга бер йөри башлаган. Булачак шәкертләргә шул кәрваннарга эшкә ялланасы гына калган…

Хәзерге Үзбәкстан биләмәсенең төньяк өлеше — Ташкент төбәге 1865 елдан Россиягә буйсындырыла. XIX йөз ахырында ашыгыч рәвештә тимер юл төзелешенә керешәләр. Оренбург-Ташкент тимер юлы 1905 елның декабреннән эшли башлый…

***

Яңа оешкан Төркестан вилаяте идарәсенә беренче көннәрдән үк безнең милләт вәкилләре дә хезмәт куя. Шулардан иң күренеклесе Шаһимәрдән Ибраһимов. Оренбург губернасында туган бу морза 1867 елдан Төркестан вилаяте хәрби губернаторының ярдәмчесе һәм тылмачы вазифаларын башкара. Бер үк вакытта, ул 1870 елның апреленнән Ташкентта үзбәкчә һәм казахча чыга торган атналык «Төркестан вилаяте гәҗите»нең редакторы була. 1881 елда, чит илгә илчелек вазифасын үтәргә җибәрелгәнче, газетада аның күпсанлы мәкаләләре, язмалары дөнья күрә. Шул исәптән ул анда фарсы теленнән тәрҗемә итеп «Мең дә бер кичә» кыйссасын да бастырып чыгара. Үзбәк телендә еллык календарьлар да төзеп бастыра. Дипломатик эшкә күчкәндә, әлеге газетаның мөхәррире итеп милләттәше Хөсәен Чанышевны калдыра.

Шушы заманнардан башлап, үзбәк әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә милләттәшләребезнең өлеш кертүен исәпкә алырга хаклыбыз. 1893 елда Сәмәркандта Оренбург сәүдәгәре Габделгани бай Хөсәенев тырышлыгы белән беренче, җәдиди ысул белән укыта торган мәктәп ачыла. Укырга бик тиз өйрәтүе сәбәпле, җирле халык аны «машиналы мәктәп» дип атый. XIX гасыр ахырында Әтнә ягыннан Сыр-Дәрья төбәгенә барып чыккан Сәйфелгабид Мәҗитовның да яңа ысул белән укытуга йөз тоткан мәктәпләр ачканлыгы мәгълүм.

Әлбәттә, 1917 ел вакыйгаларыннан соң уртак хезмәттәшлек аеруча зур үсеш ала. 1918 елда Төркестан милли мохтарияте оештырыла. Бер елдан соң аның мәгариф комиссариаты җитәкчесе итеп язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Шәһит Әхмәдиев билгеләнә. Шул ук елда ул Ташкентта Халык мәгариф институтын ачуны хәл итә. Институтта үзбәк, казах бүлекләре, соңрак, 1921 елгы ачлык вакытында, күпсанлы татар зыялылары һәм яшьләре дә бу якларга килеп туплангач, татар бүлеге дә ачыла. Үзбәкстанның халык шагыйре Гафур Голәм үз истәлекләрендә Һади Такташ һ.б. татар зыялылары белән нәкъ шул елларда якыннан аралашканлыгын, бер-берсенең иҗат үрнәкләре белән танышканлыгын бәян итә. Бу вакытта әлеге институтның студентлары һәм укытучылары арасында Латыйф Хәмиди, Габдрахман Сәгъди, Гыйбад Алпаров, Габдулла Мостакаев һ.б. була. Шунысын да искәртеп үтик, 1927 елда ачылган Сәмәрканд университетында укыта башлаган Г.Сәгъди, үзбәк халкының классик шагыйре Галишер Нәвои иҗатын тирәнтен өйрәнеп, шул хакта беренче күләмле гыйльми хезмәт язган шәхес.

Совет хакимияте елларында үзбәк әдәбиятын баетуга үз өлешләрен керткән дистәләгән милләттәшебезнең исемен атарга була. Хәмзә исемендәге дәүләт бүләге иясе, әдәби һәм мәдәни «Шәрекъ йолдызы» һәм «Огонёк» мәҗмугасы рәвешендәге «Гөлстан» журналларының күп еллар дәвамында баш мөхәррире булган прозаик Әсгать Мохтар (аның «Чинар» романын мин татарчага тәрҗемә иттем), Урта Азиядә булган тарихи вакыйгаларны чагылдырган романнары белән танылган Рәүф Галимов, шулай ук тарихи темаларга повесть һәм романнар язучы һәм шулар нигезендә эшләнгән киносценарийлар авторы Җәүдәт Ильясов (ул да «Ташкентская правда» газетасында, «Звезда востока» журналында бүлек мөдире булган), танылган прозаик һәм драматург, киносценарийлар авторы Зиннәт Фәтхуллин — үзбәк әдәбиятын баетуга зур өлеш керткән шәхесләр. Мин бу исемлекне ике дистәдән артык язучыны берләштергән кырым татарлары, Шөгер төбәге кызы Мәрвә Җәлалетдинова, Рауза Якубова-Бородина һ.б. белән дәвам итә алам.

Иҗади чыныгуын Казанда башлаган, 1927 елда, рабфак тәмамлаганнан соң, гомерен Үзбәкстан ССРда уздырган якташым Габдулла абый Уразаев эшчәнлегенә аерым тукталу кирәктер дип уйлыйм.

***

Габдулла Гыйматдин улы Уразаев 1930 еллар урталарында СССР Язучылар берлеге әгъзасы була. Кайбер хезмәтләрен ул Вил Уразаев яисә Вил Вилдан тәхәллүсләре белән дә бастыра. Мәсәлән, Казанда укыганда язылган өч пьесасын ул сәхнәгә шул исемнәр белән чыгара. Мәскәүдәге «Центриздат» тарафыннан 1927 елда нәшер ителгән «Серле шалаш» пьесасы да Вил исеме белән нәшер ителгән. Гомумән, 1920 нче еллар татар театрына багышланган хезмәтләрдә ул Вил Уразай буларак теркәлгән. Риза ага Ишморат та «Дусларым, остазларым» исеме белән чыккан истәлек китабында аны шул рәвешлерәк искә ала.

Язучы, мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Гыйматдин улы Уразаевның

гомере туган-үскән җиреннән читтә — Үзбәкстан илендә уза. Тумышы белән ул элекке Самара губернасы Мәләкәс өязе Урта Кандалый авылыннан. Ягъни хәзерге Ульянов өлкәсе Иске Майна районы Абдул авылы кешесе. Рәсми туган елы — 1904 ел. Туган авылы хәзерге Татарстан чигеннән утыз-кырык чакрымга көньяктарак урнашкан. Ләкин Габдулла ул авылда озак яшәми — гаиләсе тиздән Мәләкәс шәһәренә күчеп китә. «Атам анда извозчик хезмәтен үтәгән», — дип сөйләгәне хәтеремдә. Мәләкәстә ул Гатаулла ахун хәзрәтләре тоткан «Исламия» мәдрәсәсендә җиде ел белем ала. «Исламия»дә булачак күренекле артист Әсгать Мәҗит белән бергә укыйлар. Соңрак та язмыш аларны бер тирәдәрәк йөртә. Дөрес, буй җиткәч, чит-ят җирләрдә йөргәндә рәсмиләштергән таныклыгына караганда, Габдулла Әсгатьтән дүрт яшькә кечерәк. Дөреслектә, яшь аралары алай ук зур булмагандыр, мөгаен.

Язучы Тәүфыйк Әйдигә сөйләгән бер хатирәсендә Габдулла ага атасының өйгә «Вакыт» газетасын, «Шура» журналын алдыруын, аның шуларны һәм башка татар вакытлы матбугатын укып үскәнлеген әйтә. «Исламия»нең өлкән сыйныфларында укыганда шәһәрдә чыга башлаган «Мәләкәс тавышы» белән элемтәгә керә, беркадәр вакыт ул газета типографиясендә хәреф җыю эшендә дә катнаша. «Ундүрт яшемнән хәреф җыю һөнәрен үзләштердем», — дип искә алган иде. Бу һөнәр аның киләчәк көннәрендә дә кирәк булачак әле.

1917 елгы вакыйгалардан соң Совет хакимияте Сембер шәһәрендә укытучылар хәзерли торган курслар ача. Әсгать Мәҗит белән шунда барып керәләр. Анда алар Кави Нәҗми, булачак артист Сәет Булатов белән бергә укыйлар. Барый Тарханов оештырган «Кызыл йолдыз» драма түгәрәгенә бик теләп йөриләр. Драматург, «Көн» исемле газета мөхәррире Фәтхи Бурнаш, яшь татар комиссары Бәкер Белоусов белән якыннан аралашалар. 1919 елда Габдулланы кызылларның Бишенче армиясе нәшер иткән «Кызыл яу» газетасына хәреф җыючы итеп алалар. «Сугышып йөрергә буең кечкенә», — дип, комиссар Гыйлемдар Бәембәтев мине ул эшкә үзе билгеләде. Берүк вакытта армия карамагындагы татар театр труппасында суфлёр булдым. Бөгелмә, Бәләбәй, Чишмә, Уфа шәһәрләре безнең тарафтан яулап алынды. Яулап алынган һәр авыл, һәр шәһәрдә спектакльләр куя идек. Ул труппада Камал I, Шакир Шамильский, Гыйлаҗ Казанский, җырчы артистлар Фәттах Латыйф, Әмин Зөбәеревләр уйнады», — дип сөйләгән иде Габдулла абый бер очрашу вакытында. Шул елларда Габдулланың беренче каләм хезмәте — «Мәхәббәт чәчәкләре» пьесасы күңелендә бөреләнә.

Күңеле белән ул туган якларына тартыла. Сәмәркандтагы партия мәктәбенең укыту бүлеге мөдире, шагыйрә Заһидә Бурнашева да аңа Казанга кайтырга киңәш иткән була. 1925 елның җәй ахырларында ул Казанга килеп төшә. Яшь комиссарларга хас булганча, күн киемнәр киенеп. Университет карамагындагы рабфакка укырга керә. Элекке танышларыннан Кави Нәҗми, Әсгать Мәҗитне эзләп таба, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, «Самаралы» Гадел Кутуй һ.б. белән аралаша башлый. Үзе дә кабат кулына каләм ала. Нәсер, шигырь, мәкаләләрен мондагы матбугат бик теләп бастыра. Әсгать Мәҗит, Риза Ишморат һ.б. белән театр уеннары уйнауда катнаша. Өч пьесага «җан өрә». «Ике көрәш» белән «Еллар каршында» пьесалары укучы яшьләр кичәләрендә сәхнәләштерелә.

Габдулла аганың узган гасырның егерменче еллары ахырында татар матбугатында дөнья күргән каләм хезмәтләрен барларга теләүче булса, аларны «Вил Уразай» яки «Абдулла Вилдан» тәхәллүсе белән дә

эзләсен. Казанда яшәү дәверендә ул Г.Кутуйның «Сулф» әдәби төркеменә якынрак тора. «Губернадашлар» — якташлар бит.

***

Үзбәкстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, шундагы иҗтимагый-әдәби эшчәнлек өлкәсендә танылган хезмәт ветераны Габдулла ага Уразаев белән мин 1976 елның октябрендә Ташкент шәһәрендә танышкан идем. Аның белән мине Ташкенттагы хезмәттәшем, СССР Әдәби фондының Үзбәкстан бүлеге директоры Шамил ага Аләдин таныштырды. Элегрәк елларда бу кырым татары белән инде без Мәскәүдә күрешкәләгән идек. Ул миңа Үзбәкстанда яшәүче язучы милләттәшләребездән Әсгать Мохтар, Габдулла Уразаев, Зиннәт Фәтхуллин, Җәүдәт Ильясовлар турында бераз мәгълүмат биргән иде. «Казан татарлары үзбәк әдәбиятының да алгы сафында атлый, бил бирмиләр», — дип, аларның һәрберсенең иҗатын да беркадәр барлап чыкты. Шуннан соң мин Әсгать Мохтарның ул чорда бик макталган романын — «Чинар»ны тәрҗемә иттем. (Ә.Мохтарның ата-анасы Башкортстанның хәзерге Благовар районыннан чыккан кешеләр. Әмирхан Еники белән алар күрше авылдашлар иде). Соңрак, Габдулла ага белән очрашканнан соң, мин анда тагын берничә якташны «таптым»: Рауль Мир-Хәйдәров Актүбә каласыннан, Рәүф Галимов Чиләбе өлкәсеннән, Мәрвә Җәләлетдинова үзебезнең Шөгер төбәгендәге Куакбаш авылыннан. Рус фамилиясе йөртеп тә, татарча иркен сөйләшүче язучылардан Чирмешән егете Сергей Волгинның, Иске Майна районының Кече Кандалый авылыннан чыккан Константин Волковның Ташкент каласында яшәгәнлеге дә мәгълүм.

...Институтка кереп уку теләгеn дә бөтенләй үк онытмый Габдулла. Рабфак биргән таныклыктан файдалану чиге якынлашкан бер дәвердә ул Ташкент педагогия институтына укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый. Төп эшеннән, партия кушкан вазифаларны башкарудан аерылмаган рәвештә. Бу вакытта аны Ташкентка, партия Үзәк комитетында эшләргә дип чакырып алалар. Аңа В.И.Ленин хезмәтләрен үзбәк теленә тәрҗемә итүне оештыру бурычы йөкләнә. Шул эшләрне башкару өчен Үзәк комитетта партия тарихын барлаучы махсус бүлекчә оештырыла. Ул бүлекчә җитәкчеләренең берсе Г.Уразаев була. Бу эшне уңышлы башкарып чыккач, утызынчы еллар ахырында, Г.Уразаевны «Кызыл Үзбәкстан» газетасының баш мөхәррире итеп билгелиләр.

1945 елда аны Үзбәкстан ССР Министрлар Советы карамагындагы Радиокомитетка рәис итеп куялар. Габдулла Уразаев бу вазифаны үтәргә керешкәндә радиодан үзбәк телендә көнгә фәкать дүрт сәгатьлек тапшыру оештырылган була. Бинасы иске, кысан, җиһазлар таушалган. Габдуллага берничә студия эшли алырлык иркен бина булдыру, яңа җиһаз-аппаратуралар кайтарып урнаштыру эшләрен сугыштан соңгы авыр шартларда үтәргә туры килә. Илленче еллар башына ул эшләрне мишәрчә үҗәтлек белән җиренә җиткереп төгәлли Г.Уразаев. Дүрт студия берьюлы эшли алырлык зур бина булдыра, яңа аппаратуралар кайтарта. Үзбәк телендәге тапшырулар сәгатен уналтыга җиткерә. Республикада яшәүче уйгыр, таҗиклар өчен үз телләрендәге тапшыруларга да юл ачыла. Радиокомитет карамагында милли оркестр оештырыла. Әйтергә кирәк, нәкъ шул елларда Үзбәкстан радиосында татар телендәге тапшыруларга да бер сәгать вакыт бирелә һәм ул тәртип туксанынчы еллар башына кадәр сакланды. Хәзер андый тапшыру бармы икән — әйтә алмыйм.

Алга куелган бурычларны башкарганнан соң, ул биләгән кәнәфигә төп милләт вәкилен утырталар да, Ураза-

евны яңа башлангычны үтәргә дип, яңа урынга күчерәләр. Берничә ел гомерен ул дәреслекләр чыгаручы «Укытучы» нәшрияты эшчәнлеген җайга салуга багышлый. Анда баш редактор һәм директор була. Шуннан соң аны әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен нәшер итүче зуррак нәшриятның директоры итеп куялар. Шул вазифаны башкарганда ул Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсенең секретаре итеп тә сайлана.

Якташымның соңгы эш урыны — Язучылар берлеге карамагындагы Әдәбиятны пропагандалау бюросы директоры кәнәфие. Ләкин ул анда озак эшләми. Алтмышынчы еллар уртасында пенсиягә чыгып, фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Г.Уразаевның Үзбәкстанда яшәгәндәге төп иҗат юнәлеше — үзбәк телендә татар әдәбиятын тарату, пропагандалау була. Ташкент шәһәрендә яши башлаган беренче көннәреннән үк ул Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Шамил Усманов һ.б. иҗатына багышланган күпсанлы очерк, мәкаләләр язып бастыра. Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» романнарын (икешәр басма), Ш.Усмановның «Памирдан радио» дип аталган фантастик әсәрен үзбәкчәгә утызынчы елларда ук тәрҗемә итә. Соңрак дәвердә аның каләме аша үзбәк укучысы кулына Әхмәт Фәйзинең «Тукай», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы», Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» повестьлары һ.б. әсәрләр барып ирешә. Габдулла Тукайның 1976 елга кадәр үзбәк телендә дөнья күргән барлык «Сайланма әсәрләр»ен туплашуда Г.Уразаев катнаша, күпчелек очракта кереш сүз авторы да ул була.

1979 елда үзбәк телендә хәзерге заман татар хикәяләрен туплап бастыру карарына киленде. Ташкентта булганда мин шул хакта Габдулла агага хәбәр иттем. «Ул китапны эшләп чыгарырга алынмыйсызмы?» — дип сорадым. «Кулымда эшем бар әле, Әмирхан Еники әсәрләрен тәрҗемә итәргә ниятләдем», — дип җавап бирде ул. Җитмеш биш яше тулган кеше бит, аны кабат аптыратып тормадык. «Дуслык китапханәсе» сериясендә 1981 елда басылган «Еллар вә юллар» хикәяләр җыентыгы тәрҗемәсен үзбәк язучысы Хәйрулла Эргашев башкарып чыкты.

Кадерле якташым Габдулла ага белән без соңгы тапкыр 1981 елның июнь ае ахырларында Кырымда очраштык. Язучыларның Кара диңгез буендагы «Күктүбә» иҗат йортында. Аның үзе кебек кечерәк буйлы, бик ачык йөзле, мөлаем кыяфәтле карчыгы белән икәү ял иткәннәр, инде китәрләренә ике көн генә калган иде.

— Ял гына иттегезме, әллә бераз эшләдегез дәме? —дидем.

Иң әүвәл бу соравыма җәмәгате — Зәйнәп апа җавап бирде:

— Тик утырырга бер дә күнекмәгән инде ул. Эшсез бер дә тора алмый, —диде. Сөйләмендә үзбәк аһәңе белән янәшә мишәр чалымнары да сиземләнгән кебек иде.

Шул очрашудан соң миңа Ташкентка барырга туры килмәде. Берникадәр вакыт үткәч, сиксәненче еллар урталарында Мәскәүдә очрашканда, шагыйрь, Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсе секретаре Нармурад Нарзуллаев күңелсез хәбәр җиткерде: «Обдулло әкә койтыш булды», — диде. Соңгы күрешкән вакытта Габдулла әкә безгә: «Туган якта күптән була алганым юк. Авылымны, Мәләкәсемне бик сагындым», —дип әйткән иде. Гомере читтә узган кешенең кабере дә читтә калучан шул. Туган төбәген ул кайтып күрә алмады шикелле. Кайткан булса — якташлары хәтерләр иде. Ульяновскида уңышлы гына нәшер ителә торган «Өмет» газетасы мөхәррире, якташы Исхак Хәлимов андый очракны хәтерләми. ■

АТ УЙНАТКАН ВАКЫТЛАР...

WHEN WE RODE A WHITE HORSE...

Усеин Болатуков (Хөсәен бәй Балатуков) – кырым татар драматургы, шагыйрь һәм режиссёр. Иң атаклы кырым морзалары ыруыннан булган аксөяк Болатуковлар нәселеннән. Парижда укып, югары белем алган. Рус императоры армиясендә офицер булып хезмәт иткән, үләр алдыннан гына отставкага чыккан була.

1918 елның февралендә «Варфоломей төнендә» кызыл террорчылар тарафыннан үтерелә. Усеин Болатуковның «Айшә ханым» пьесасына килгәндә, ул 1917 елда «Кырым учагы» («Къырым Оджагы») газетасында (Симферополь (Акъмәчет)) басылып чыга. С.Кәримов бәяләмәсе буенча, «Кырым татар әдәбиятында кырым морзаларының тормыш-көнкүрешен, дөньяга карашларын тулысынча яктырткан беренче әсәр». Аның эчтәлеге авторның югары һөнәри осталыгын күрсәтә. Пьесадагы унбер персонажның һәрберсе нечкә зәвык белән төгәл эшләнгән. Аларның сөйләменнән, шул чордагы морзаларның (бигрәк тә, Карт морза, Хәсән морза) яшәү рәвешен һәм милләт язмышына карашын ачык күрәбез. Пьесаның сюжет линиясе-канвасы артык катлаулы булмаса да, үзенең эчке үсешендә төп конфликтның катлаулана, арта баруы җәлеп итә.

Пьесаның чишелешен автор белә торып язмаган — укучыга, тыңлаучыга уйларга урын калдырган. Төп вакыйга 1910 елда җәй аенда Симферополь (Акъмәчет) шәһәреннән ерак булмаган бер авылда бара. Төп геройлар — морза нәселенә караган бер гаилә вәкилләре. Морза, аның хатыны — бик дини кешеләр, бөтен гомерләрен шәригать кануннарына багышлап яшиләр. Балаларын да шулай тәрбияләргә тырышалар. Әмма рус гимназиясендә укучы олы уллары Мөхәммәт морза аурупа манерында киенә, сөйләшә, яңача яшәргә тели, һәм, үзенең сеңлесе Айшәне дә шул юлдан барырга өнди. Милләтне саклап калу, аның өчен көрәшергә, берләшергә чакыру пьесадагы персонажлар сөйләмендә ачык чагыла.

Мәсәлән, Мөхәммәт морза: «Әти, башта син шунысын әйт, ни өчен син мине түбәнсетәсең?.. Ни өчен фанатизм кысасыннан чыга алмыйсың? Ни өчен татарларны пычракка салып таптыйсың, ә морзаларны күккә чөясең? Кеше булу өчен башта акыл кирәк. Әгәр башы булмаса, ни файда морзадан?»

Яисә, «Беләсеңме, Айшә, мин динебезне, татарлыгымны, горефгадәтләрне бик ихтирам итә идем. Ләкин моның кебек дикий гадәтләрнехакимлекне, татарларны мәсхәрә итүне бөтенләй сөймим... Кайчан татарлык кешелек рәтенә менәр, күрерменме шул көннәрне? Кайчан татар уяныр, йокылык царствосыннан чыгар? Айшә, бу безнең морза халкында бер начар гадәт бар, татарларны — кендек кардәшләрне кеше урынына куймау, минемчә, акылсызлык, не правда ли?»

Мөхәммәт морзаның дусты Ашыров шигырендә болай әйтелә:

«Йөрәккәем чыр-чыр яна
Әгәр төшсә исемә.
Туфраклар чәчелә кулдан
Кем адашкан Кырымда?!

Кая китте бабайларым
Ат уйнаткан вакыт?
Кая китте, бабайларым,
Сез утырган тәхет?»

18 яшьлек Айшә ханым энесенә: «Мин сине чын күңелдән яратам, энекәем! Тыңла, исеңдә калдыр, бер васыять әйтәм. Һичбер вакыт әйтмә син «Бу морза, ул татар, бу ногай», — дип. Һәммәсенә ихтирамлы бул».

Әлеге әсәр милли драматургиянең үсешендә зур роль уйнаган һәм ул кырым татар әдәбияты һәм сәнгатендә бик кыйммәтле нәфис сәнгать өлгесе булып тора. Бу — безнең дә мирасыбыз!

XX гасыр башы — кырым татар әдәбияты, мәдәнияте, сәнгате өчен дә чәчәк ату, үсеш чоры. Язучылар, сәнгать әһелләре берсеннән-берсе матур әсәрләр язалар, пьесалар иҗат итәләр, тугандаш халыкларның иҗат җимешләрен үрнәк итеп алып, үзләренең культурасын югарырак, өскәрәк күтәрергә тырышалар. Шуңа бер мисал: 1917 елда драматург Гомәр Инчи шигъри формада «Бәхетсез сугышчы» драмасын яза. Шул ук елда «Сихерчеләр корбаны» пьесасын татар теленнән кырым татар теленә тәрҗемә итә.

Ләкин, 1944 елда Ватаннан куылгач, бу тугандаш халыкның милли тормышы, әдәбияты һәм сәнгате әйтеп бетергесез зур югалтуларга дучар була.

Нурулла Гаптуллин, *тәрҗемәче*
Translator ***Nurulla Garif***

Редакциядән:
Мөхтәрәм укучыларыбыз! Усеин Болатуковның «Айшә ханым» исемле пьесасын алдагы саннарыбызның берсендә укый аласыз. ■

ТҮРКЛӘР

Ркаил Зәйдулла

THE TURKISH PEOPLE
Rkail Zaidulla

Да, скифы мы...
А.Блок

Түркләр без! —
Кысан бу дөньяга
Тудырган да безне Ашина,
Җилдергәнбез җитез тулпарларда
Җилләр, зилзиләләр каршына.

Түркләр без! —
Күзебез дә хәтта
Ук төзәргә диеп уелган.
Офыкларда югалабыз, чыгып
Тормыш дигән затсыз уеннан.

Түркләр без! —
Дөм караңгы төндә
Дала бүресенең юлдашы.
Таш диварлар кыса хәзер җанны,
Ерагая Күлтәгин ташы.

Түркләр без! —
Хәтер корбаннары.
Күзне йомып тып-тын тор гына,
Йөз меңнәрчә кылыч күтәрелә,
Һәм төмәннәр яуга ыргыла.

Түркләр без! —
Аларның да әле
Иң чыдамы икән ләбаса! —
Татар атын авыр аркан белән
Өстерибез гасырлар аша.

Түркләр без! —
Кеше арбасында...
Кулдан төште күптән дилбегә.
Сиздермичә әрнеп күз ташлыйбыз
Дөнья дигән атның биленә.

Түркләр без! —
Урман җәяүлесе
Адымнарын тыеп атласын! —
Арган җайдак камчы сабы белән
Кага яңа гасыр капкасын. ■

ТӘҢРЕЛӘР ҺӘМ РУХЛАР

Габделкадыйр Инан
(1889-1976)

GODS AND SPIRITS
Gabdelkadir Inan

Борынгы төрекчәдә «күк» һәм «иң бөек рух» төшенчәләре бер генә сүз («тәңре») белән атап йөртелә, «күк» (синий) сүзе исә сыйфат рәвешендә кулланыла. Ислам динен кабул иткән төркиләр «күк» сүзен һава, «тәңре» сүзен Аллаһ өчен яраклаштырганнар. Борынгы төрекчәдә «һава» мәгънәсендә кулланылган «калык»ны, ислам кабул ителгәннән соң, «күк» мәгънәсендә куллануга кертергә теләсәләр дә, бу тормышка ашмаган һәм ул сүз бөтенләй онытылып калган.

Борынгы төркиләрдә бөек уртак Тәңре хакында ачык инану барлыгын әлегә белмибез. Һәрхәлдә, бөек төрки империяләр оешкан дәверләрдә аларга кергән барлык халыклар өчен уртак культ булып, Күк-Тәңре саналган. Урта Азиядә дәүләт корган нәселләрнең барысында да Күк-Тәңре культы булганлыгын Кытай чыганаклары да раслый.

VI-VIII гасыр язмалары һәм риваятьләреннән Бөек Күк-төрек империясенең башында торган төрек нәселендә Күк-Тәңрегә инану системасы яшәве һәм бу системаның шактый ук үсешкә ирешкән булуы аңлашыла. Әлеге язмалардан күренгәнчә, хакан (дәүләт башлыгы) һәм бәйләр, төрек милләтенә кылган изгелеге һәм ярдәме өчен, Тәңрегә рәхмәт тойгылары белдерәләр, шөкер итәләр. Хаканнарны тәхеткә утырткан, төрекләргә җиңү китергән, һәлакәтләрдән саклаган Тәңрене алар Күк-Тәңре дип йөрткәннәр.

Үзләренең уңышлары һәм җиңүләре турында сөйләгәндә, хаканнар һәм бәйләр бервакытта да: «Тәңре ярдәме белән», — дияргә онытмыйлар.

Шунысы игътибарга лаек: бу язмаларда «Тәңре» сүзе нининдидер аерым тәңреләр (Җир-су, Күк) сыйфатында кулланылмый. Сирәк очракларда гына тәңре исеме «Җир», «Күк» яки «Җирсу» сүзләре белән бергә искә алына.

Күк-төрек һәм борынгы уйгыр язмаларында төньякның караңгы урманнарында барлыкка килгән гади шаманлык элементларының бик аз булуы күзгә ташлана. Шаманлыкны хәтерләткән сүзләр фикерне шигъри юл белән ачып бирү өчен генә кулланыла. Мәсәлән, Билге Каһан анасының балаларына күрсәткән шәфкате һәм сөюе хакында сүз алып барганда, аны шаманлыктагы мәрхәмәтле Тәңре-анага охшатып, «Умай кебек анам» дип телгә ала. Шаманлыкта «җибәрелгән» (ягъни, Тәңрегә, рухларга бүләк яки корбан итеп җибәрелгән) дигән мәгънәгә ия булган «ыдук» сүзенең Күк-төрек язмаларында «изге, мөкатдәс, мөбарәк» мәгънәсен алуын күрәбез.

Буддизм һәм манихеизм кабул ителгәннән соң язылган төрек-уйгыр әсәрләре белән Күк-төрек әсәрләрен чагыштырсак, шаман Күк-төрекләр дөнья карашының көчлерәк һәм акылга ятышлырак булуын да күрербез. Манихеист һәм буддистларга хас текстларда «тәңре» сүзе Күк-төрек текстларындагы мәгънәдә кулланылса да, материаль барлык итеп күз алдына китерелгән «тәңре» (күк, сәма) аларда аерым карала һәм еш кына «күк» сүзе белән генә белдерелә.

X гасырның беренче чирегендә угызларны күреп киткән Ибн Фадлан аларның «бир тәңре» (бер тәңре) дигәннәренә игътибар итә. Аның аңлатуына караганда, угызларның берәрсе кыенлыкка очраса яки күңеленә хуш килмәгән берәр нәрсә күрсә, күзләрен күккә төбәп, «бир тәңре» ди икән, бу исә бер Тәңре системасы турында сөйли (Ә.Вәлиди Туган, «Ibn Fadlan's Reisebericht...»). Шул ук авторның башкортлар хакында биргән мәгълүматларында бу халыкның унике тәңресе булып, алар арасыннан иң бөегенең күктә икәнлеге әйтелә. Угызларның «бир тәңре»гә, башкортларның күктәге бөек тәңрегә ианулары белән бүгенге якутларның Өрүнг Артойонга, ә алтайлыларның Өлгәнгә иманулары арасында әллә ни аерма булмавына шик юк.

Бүгенге шаман догаларының кайберләрендә «күктәге бер тәңре»гә мөрәҗәгать ителсә дә, бу догаларны яхшылап тикшергәннән соң, «бер тәңре» сүзенең исем өчен генә кулланылуы аңлашыла. Шаманнар «бер тәңре» тәгъбирен мөселман яки христианнардан алган булса кирәк.

Иске төрекчәдә «тәңре» сүзе күзгә күренгән күкне дә, Аллаһны да аңлата. Бүгенге шаманнар тауны яки елганы бер үк вакытта рух дип кабул итсә, борынгы төрекләр дә күк белән бөек рухны (Тәңрене) бер үк әйбер дип кабул иткән.

Борынгы төрекчәдәге «тәңре» сүзе бүгенге төрки диалектларда Тәңре, Тәңгәрә, Тенгри, Тангри, Тангара, Тура һ.б. дип әйтелә. Бүгенге шаман төркиләр «тәңре» сүзен борынгы төрекләрдәге мәгънәдә кулланалар. Аларда бездәге кебек «күк» сүзе юк. Алтай камнары (дини йола башкаручылары) Тәңрегә дога кылганда «югарыда торган бөек атабыз хак тәңгәрә», «дөньяны йолдызлар белән бизәгән тәңгәрә» «бар нәрсәне яраткан тәңгәрә», дигән мөрәҗәгать сүзләре кулланалар.

Якутларның борынгы дастан һәм әкиятләрендә «тангара» сүзенең Күк һәм Күк рухын (Тәңре) аңлаткан булуы күзгә ташланса да, бүген алар бөтен рухларга, хәтта рухларны гәүдәләндергән сыннарга да «тангара» диләр.

Алда әйтеп үтелгәнчә, борынгы төрекчәдә «күк» һәм «иң бөек рух» төшенчәләре бер генә сүз («тәңре») белән атап йөртелә, «күк» (синий) сүзе исә сыйфат рәвешендә кулланыла. Ислам динен кабул иткән төркиләр «күк» сүзен һава, «тәңре» сүзен Аллаһ өчен яраклаштырганнар. Борынгы төрекчәдә «һава» мәгънәсендә кулланылган «калык»ны Ислам кабул ителгәннән соң «күк» мәгънәсендә кулланырга теләсәләр дә, бу тормышка ашмаган һәм ул сүз бөтенләй онытылып калган. Угызларда «тәңре» сүзе урынына йөри торган «чәләп» яки «чалап» сүзе нәстури (несториан) христианнары аша кергән булса кирәк. Кояш, ай һәм йолдыз белән бәйле иманулар Күк-Тәңре культына барып тоташкан. ■

İstiklâl Marşı

Korkma, sönmez bu şafaklarda yüzen al sancak;
Sönmeden yurdumun üstünde tüten en son ocak.
O benim milletimin yıldızıdır, parlayacak;
O benimdir, o benim milletimindir ancak.

Çatma, kurban olayım çehreni ey nazlı hilâl!
Kahraman ırkıma bir gül! Ne bu şiddet bu celâl?
Sana olmaz dökülen kanlarımız sonra helâl,
Hakkıdır, Hakk'a tapan, milletimin istiklâl!

Ben ezelden beridir hür yaşadım, hür yaşarım.
Hangi çılgın bana zincir vuracakmış? Şaşarım!
Kükremiş sel gibiyim, bendimi çiğner aşarım;
Yırtarım dağları, enginlere sığmam, taşarım.

Garbın âfakını sarmışsa çelik zırhlı duvar,
Benim iman dolu göğsüm gibi serhaddim var.
Ulusun, korkma! Nasıl böyle bir imanı boğar,
«Medeniyet!» dediğin tek dişi kalmış canavar?

Arkadaş! Yurduma alçakları uğratma sakın!
Siper et gövdeni, dursun bu hayasızca akın.
Doğacaktır sana vaadettiği günler Hakk'ın;
Kim bilir? Belki yarın? Belki yarından da yakın!

Bastığın yerleri «toprak» diyerek geçme, tanı!
Düşün, altındaki binlerce kefensiz yatanı!
Sen şehit oğlusun, incitme, yazıktır atanı;
Verme, dünyaları alsan da bu cennet vatanı.

Kim bu cennet vatanın uğruna olmaz ki fedâ?
Şüheda fışkıracak toprağı sıksan, şühedâ!
Canı, cananı, bütün varımı alsın da Hüdâ,
Etmesin tek vatanımdan beni dünyada cüdâ.

Rûhumun senden, ilâhi, şudur ancak emeli;
Değmesin mabedimin göğsüne na-mahrem eli!
Bu ezanlar ki şahadetleri dinin temeli,
Ebedi yurdumun üstünde benim inlemeli.

O zaman vecd ile bin secde eder varsa taşım;
Her cerihamdan, ilâhi, boşanıp kanlı yaşım,
Fışkırır rûh-i mücerret gibi yerden nâşım;
O zaman yükselerek arşa değer belki başım!

Dalgalan sen de şafaklar gibi ey şanlı hilâl;
Olsun artık dökülen kanlarımın hepsi helâl!
Ebediyyen sana yok, ırkıma yok izmihlâl.
Hakkıdır, hür yaşamış bayrağımın hürriyet;
Hakkıdır, Hakk'a tapan milletimin istiklâl!

Истиклял (бәйсезлек) маршы — Төркиянең Дәүләт гимны



Мәһмәт Акиф Ирсой — Төркия Дәүләт гимнының сүзләрен иҗат иткән шагыйрь.
Ул 1873 елда Истанбулда дөньяга килә. Ветеринарлыкка укый, озак еллар шул өлкәдә хезмәт куя. 1920 елда Төркия Парламентына депутат итеп сайлана. Мәһмәт Акиф, нигездә, дини шагыйрь буларак таныла, гарәп, фарсы һәм француз телләрендә яхшы аралаша. 1921 елда ул Төркиянең милли гимны өчен игълан ителгән шигырь конкурсында җиңеп чыга (гимнның көен 1924 елда Госман Зәки Үнгүр яза). Мәһмәт Акиф гомеренең соңгы елларында Корънәнең шигъри тәрҗемәсен эшли. 1936 елда Истанбулда вафат була.
Дәүләт гимнының авторы буларак, аны халыкта «Милләт Шагыйре» дип атап йөртә башлыйлар.

Курыкма, төшмәс бу шәфәкъләрдә йөзгән ал байрак;
Сүнмәс йортыбыз өстендә төтенләп соң учак.
Ул минем милләтем йолдызыдыр — яначак;
Ул — минеке, ул минем милләтемдер һәрчак.

Ятма, корбан булмас ул һичкайчан назлы һилал[1]!
Каһарман ыруыма гөл! Син көчле дә, син гүзәл.
Синең өчен түгелгән каннарыбыз булыр хәләл,
Хакка табынсак, килер халкыбызга истиклял.

Без һәрвакыт дөньяда хөр яшәдек, хөр яшәрбез.
Нинди тинтәк безгә зынҗир кидермәкче? Шашарбыз;
Күкрәрбез сил шикелле, һәм күкләргә ашарбыз,
Тауларны ертып, офыкларга сыймый ташарбыз.

Көнбатыш явын кире кагар корыч көбәле дивар,
Күкрәгебез тулы иман — безнең яклаучыбыз бар.
Олы син, курыкма! Сиңа өстән кодрәтле тәңре багар,
«Мәдәният!» диеп кенә тешсез калырмы җанвар?

Аркадаш! Йортка түбәнлек килүеннән син саклан!
Гәүдәң белән капла, туктар безгә каршы агым.
Туачактыр безгә вәгъдә ителгән көне хакның;
Туар бәлки иртәгә ул, бәлки аннан да якын.

Баскан җиреңне «туфрак» диеп үтмә һич тә, син таны —
Төшен, аяк астында күпме кәфенсезнең ятагы.
Син — шәһидләрнең улы, языктыр оныту атаны;
Бирмә дөнья нигъмәтенә бу җәннәтле ватанны.

Кем бу җәннәт ватаны өчен җанын итмәс фида?
Шәһид булып ашла туфракны, мәңгелек дан шәһидкә!
Ил хакына бөтен барлыгымны алсын да Хода,
Тик ватаннан аермасын, аермасын ул һич тә.

Рухым синдә, и Илаһым, шулдыр минем теләгем —
Кагылмасын изге җиргә дошманнарымның кулы.
Бу азаннар, шәһадәтнең асыл дәлиле булып,
Яңгырасын ил өстендә, авазы якты, олы.

Ул заман сәҗдә итәр, әгәр булса, кабер ташым;
Һәрбер ярамнан, Илаһи, түгелер канлы яшем.
Җәсәдне калдырып җирдә калкыр да өскә җаным,
Ул заман, бәлки, күкләргә кагылыр минем башым.

Ялкынлан син дә шәфәкъләр кебек, и шанлы һилал!
Булсын түгелгән каннарыбызның һәммәсе хәләл.
Юкса һичбер кайчан килмәс халкыма минем ирек.
Хактыр, хөр яшәрбез һаман байракны өстә тотып,
Хактыр, Хакка табынган милләтемә — истиклял! ■

*Төрекчәдән **Ркаил Зәйдулла** тәрҗемәсе*

[1] Һилал — яңа туган ай.

ТӨРКИ ДӨНЬЯ ӘДИПЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

FROM THE HERITAGE OF THE TURKIC POETS AND WRITERS.

Булмас

Мәхтүмколый
(1727 (1733)-1783)

IT'S IMPOSSIBLE
Makhtumkoliy

Һәр ахмакка да чәчмә син сүзеңне,
Әрәм итмә, янып-көйгәнгә тармас,
Ачы яшьләр түгеп ике күзеңнән
Ела син — файдасы бөртек тә булмас.

Горур бул, сер сынатма — тот үзеңне,
Булып мескен, кызартма син йөзеңне,
Ә куркакка сөйләмә сер-сүзеңне,
Сереңнең кадере бар күк тә булмас.

Масайма тиңләшеп тормыш гөленә,
Кибәрсең саргаеп сахра җиленә,
Яшәп тә йөзгәчә, әҗәл килүгә —
Гомер иттем дигән кебек тә булмас.

Сөләйманнан да артык дәртле булсаң,
Һавалар тетрәтер гайрәтле булсаң,
Үлем-җәллад килеп күкрәккә орса —
Бетәрсең шунда ук — «әһ» дип тә булмас.

Усал ниятлегә һич булма юлдаш,
Бәлаләргә тарырсың һәм бетәр баш,
Күмерне, күпме мактама, итәр фаш —
Йөзең каралмыйча әлбәттә булмас.

Мәхтүмколый тапмый тынгы әмәле,
Үткен пычак кебек ялган зәһәре,
Яман телгә караганда, зәһәрле
Елан чагу — чебен чакканга тормас.

Кызыйлар

Токтогул
(1864-1933)

THE GIRLS
Toktogul

Гөл-чәчәкле даланы
Буйлагызчы, кызыйлар.
Йөрәктә дәрт барында
Уйнагызчы, кызыйлар.
Кире кайтмас яшь гомер,
Уйлагызчы, кызыйлар.
Уйнамыйча, көлмичә,
Җан рәхәте күрмичә,
Яшьлек үтеп, картаеп
Куймагызчы,кызыйлар.

Хәйран яшьлек таңында,
Гомер матур чагында
Алсу гөлдәй чәчәклән,
Көл шатлыгың барында.
Картлык куып җитәр дә,
Гомер узып китәр дә,
Туфрак белән күмелеп,
Калырсың үз җаеңда...

Кабат килми яшь гомер,
Уйлагызчы, кызыйлар.
Уйнамыйча, көлмичә,
Җан рәхәте күрмичә,
Матур чакны үткәреп
Куймагызчы, кызыйлар.

Нури Арслан *тәрҗемәләре*
Translations of ***Nuri Arslan***

Шәрык нуры

Чулпан
(1897-1938)

THE RAY OF EAST
Chulpan

Мулланур Вахитов рухына

Соң дәвердә юксыл шәрык тарихы
Бер бит булсын —
ак юл-сәтырь күрмәде.
Дөнья тарихын язган мөәррих тә,
ахры,
Яхшылыкка каләмен һич бормады:

Шәрыкның кайсы чорына күз салсаң,
Юклык, үлем, золым,
каргыш күрерсең,
«Тәмуг» дигәнне белергә теләсәң,
Шәрыкта башыннан ахырына йөрерсең.

Бер заманнар җир йөзендә «үз башлы»
Олуг, шанлы мәдәният тудырган
Ул — гүзәл Шәрык...
туфрагы соң заман
Булды читләр кысасында, күз яшьле! —

Аның мондый кызганычлы хәленә
Һәркемнән күбрәк яшь койган
син идең.
Аны изгән ерткыч куллы залимгә —
Син олуг яу, аяусыз, кискен идең.

Инсаннарга «бәхеткә —
бердәнбер, дип
Тугры юлны күрсәткән» Маркс иде.
Шәрыкка — безгә котылу юлын бит
Күрсәтүче олуг даһи син идең, —
Синдәй кеше Шәрыкка тансык иде.

Синең пакъ күкрәккә угын атканны
Уйлама, дип, ул —
тик синең дошманың.
Ул дошман — бел,
Шәрыкның чын дошманы,
Күптән эчеп килгән аның көч-канын.

Кояш та, Ай да —
Шәрекътән чыгадыр,
Тик син генә Гаребтә чыгып, баттың...

Шуңа минем Шәрыклек рухымдадыр
Гаҗәеп дәһшәтле уйлар уяттың:
— Шәрык кояшы керсә
болытлар астына?! —
Синең соңгы көннәреңне уйлыймын.
Батып барган Айга карап: —
Әй, юксыл,
Ул олуг нур сүнмәсме? —
дип сорыймын.

Ихтималдыр, сине һәрбер нәрсәдән
Газиз күргән — ул үзең
сөйгән Шәрык! —
Рухыңны ул Ай урнына элсә әгәр?! —
Җан күзебездә — нур бер, аерма юк!

...Минем шәрыклык күзем рух-эзеңне
Шәрыкның һәр
почмагыннан күзлидер.
Чын: шәрыксөяр нур-рухың инде
Һаваларда рәшә булып йөридер...

Инде, күрәм, очып үтте — Мисырның
Серләр ташып аккан Нилы буена.
Нилны буйлап, килеп керде ул рухың
Фәллахларның фәкыйрь яшерен туена.

Аннан үтеп Сүриянең Шамына,
Гасырлар эзеннән урамнар әйләнде.
Шул минутта ук Һималай тавында
Һинд кызына тиң яр булып
сайланды...

Кичә күрдем аны: Будда янында
Чын камиллек остазына баш иде.
Аннан инде Нишапурда — бакчада
Хәйям белән гыйшкый шигырь укыды.

Узган атнада Чин-Мачин йортында
Конфуцийның фәлсәфәсен ишетте.
Бу атна Иран: зардәштлек турында,
Ничегрәк? — дип Ницшега
киңәш итте...

Һиндстанда Бәдил белән йөрүен дә
Минем шәрыклык күзен анык күрде.
Аламутта — Хәсән-сәйях илендә
Минем рухым белән ул бергә йөрде...
Шуңа ахры сөя сине бар Шәрык:
Син — Шәрыксең, Шәрык —
Син, аерма юк!

*Үзбәкчәдән **Рәдиф Гаташ** тәрҗемәсе*
*Translation of **Radif Gatash** from Uzbek*

МӘХӘББӘТ ӘСИРЕ

Хикәя

Рәшат Нури Гүнтәкин
(1889-1956)

THE PRISONER OF LOVE (story)
Rashat Nuri Guntakin

Шулай берчакны, мәктәптән кайткач та, Рәсимнең күзенә хат чалынды. Яхшы сыйфатлы кәгазьдә яңа язу белән (яңа, латинлаштырылган әлифба Төркиядә 1928 елда кабул ителә) болай дип язылган иде:

«Рәсим бәй, мин Сезне читтән генә яратып йөрүче яшь кенә, бик чибәр бер кызмын... Бу хакта кыюланып әйтергә җөрьәт итәм. Иң зур теләгем — мәхәббәтегезне яулап алып, Сезнең хатыныгыз булу. Әмма дә без икебез дә бик яшьләр әле, шул сәбәпле, берничә ел көтәргә туры килер. Хатларыгызның тышына «сорап алганга кадәр» дип куегыз. Чөнки әткәем иске карашлы, беркадәр диндар да кеше. Шуңа да карамастан, очрашуыбызга өметемне өзмим. Үземне сөйгәнегез вә кәләшегез дип исәпләп, Сезнең белән очрашырга хакым бар, дип уйлыйм. Гел өйдә генә утыру — минем өчен әйтеп бетергесез зур газап, ә Сезнең хатларыгыз мине бу авыр газаптан коткарыр иде. Бәдыйга».

Уналты яшен тутырган мәктәп укучыларының һәммәсе кебек үк, Рәсим дә бу тормышта мәхәббәттән дә әһәмиятлерәк нәрсәнең юклыгына инанган иде. Әлеге хатны укып та бетерергә өлгермәде, инде аның йөрәгендә дөрләп ялкын да кабынды: таныш түгел Чибәркәйгә булган сөю хисләре Рәсимнең вөҗүден биләп алды. Кичкырын ул кинога барырга уйлаган иде. Инде бу уеннан да кире кайтты. Бүлмәсенә бикләнеп, кызга озын гына хат язып ташлады. Язган хатын почта тартмасына төшереп җибәргән мәлдә Рәсим әле моңарчы сизелмәгән кичерешләр дөньясында кайнавын тойды. Әйтерсең лә ки, нәкъ менә ун елга олыгайган ул, җитдиләнгән...

Исемен Бәдыйга дип атаган яшь кыз исә Рәсимнең хатларына бик тә пөхтә итеп язылган төгәл җавапларын һич тоткарлыксыз җибәрә торды. Егетебезнең җавап хатлары бер-ике көнгә генә тоткарланса да, чибәркәй «күк күкрәтеп, яшен яшьнәтергә» кереште:

«Саф сөюен Сезгә тәкъдим иткән бичара кызны нигә диеп кенә тилмертәсез икән? Инде болай да дүрт ягымда дүрт дивар... Шул ябык өемнән матур дөньяларга чыга алмагач, мин Сезгә серләремне сөйләдем... Хатларыгызны уку — бердәнбер шатлыгым вә юанычым иде... Их, Сез! Инде килеп, анысын да кыска гына итеп язасыз. Әллә инде ихлас булудан ояласыз дамы? Янә бер үтенечем: хатларыгызны мөмкин кадәр танылырлык итеп язсагызчы!»

Егетебез... Менә шуннан соң инде егетебез... Үзгәрде. Юк, юк. Дөресрәге, үзгәрә генә башлады әле... Хәзер инде ул кичләрен бүлмәсендә утыра һәм сәгатьләр буе озын-озын хатлар язар-

га керeште, күнегүләр өчен каралама да булдырды.

Бәдыйга бик кызыксынучан кыз икән. Хатларының берсендә ул Рәсимгә мондый сорау белән мөрәҗәгать итте:

«Туебыздан соң, ширбәтле айда (өйләнешкәннән соң беренче ай.— Тәрҗ.) *кай якларга сәяхәт кылырбыз — Италиягәме, әллә Швейцариягәме? Беләсе иде, анда ничек икән? Кешеләр ни рәвешле яшиләр, ни белән шөгыльләнәләр? Юлыбыз кайсы диңгезләр вә нинди мәмләкәтләр аша үтәчәк икән?»*

«Сез Габделхак Хәмит бәйнең соңгы китабын укыгансыздыр инде. Языгызчы, кайсы бүлеге бигрәк тә күңелегезгә хуш килде?» — дип сорый иде Бәдыйга Рәсимнән.

Укучы егетебезгә килсәк, ул сөйгәне каршында дәрәҗәсен бер тамчы да кимсетмәскә карар кылды: көннәр буе тырыша-тырыша җәгрaфия һәм әдәбиятка кагылышлы китаплардан үзенә кирәклесен эзләде. Чираттагы хатларының берсендә Бәдыйга Рәсимгә янә үпкә вә шелтәсен белдерде: *«Сезнең белән очрашырга булган идем әле менә. Һәм кичә, Сез мәктәптән кайтканда, үзегезне туктатырга да уйлаган идем. Әмма сөйкемле вә яшь кызның сөйгәне булуыгызны, күрәмсең, онытып җибәргәнсез: киемегез җыйнаксыз, ботинкаларыгыз пычранып беткән. Бала-чага шикелле, иптәшләрегез белән кыйнашып йөрмисездер ич? Менә шуңа да, Сезне кыен хәлдә калдырмас өчен, яныгызга килергә кыймадым».*

Хатны укыгач, Рәсим бик тә уңайсыз хәлдә калуына оялып куйды һәм моннан ары гел җыйнак вә пөхтә йөрергә үз-үзенә сүз бирде.

Ә бер тапкыр Бәдыйга сөйгәнен дәресләр тәмамлангач, өйгә кайтмыйча, төнгә кадәр урамда селкенеп, җил куып йөрүе өчен әрләде. Рәсименең бүтән кызлар артыннан чабуына ышанасы килми иде аның. Дүрт дивар эчендә тилмерә-тилмерә мәхәббәт утынnан янып-көйгән кызыйны егет ташламас ич инде...

Бәдыйгага җавап хатында Рәсим, аннан кала гомерендә беркемне дә яратмаска ант итте һәм урамда селкенеп йөрүдән дә, кызларга хәтта күз кырые белән генә караудан да ваз кичте.

...Көннәрнең берендә, акшам алдыннан кичкырын, Рәсимнең әнисе Нәдимә ханым, олы хәсрәте булган кеше кыяфәтендә, ире Әхмәт бәйгә болай диде:

— Аһ, бәй, йортыбызда ниләр булганын син хәтта күз алдына да китерә алмассың. Бәдыйга исемле нииндидер җиңел холыклы бер «себерке» зат улыбызны үзенә өйләндерергә тели. Рәсимнең бүлмәсен җыештырганда мин аның хатларын таптым... Улыбызны югалтабыз бит... Ни булса да эшләргә кирәк... Чарасын тап! Әмма дә, Ходай хакы өчен дим, берүк кызып кына китә күрмә. Болай да кызу канлы кеше бит син!..

Әхмәт бәй исә кызып китәргә уйламады да.

— Бер дә борчылма, хатын, — диде ул көлемсерәп һәм, тавышын киметеп, болай дип тә өстәде:

— Улыбызга мәхәббәт хатлары язган әлеге җиңел холыклы зат — мин ул. Үзең беләсең, малайның ялкаулыгы көнләп түгел, сәгатьләп арта бара иде. Мәктәптәге укытучылары да, мин дә, ничаклы тырышып та, ул малайны хәтта дөрес язарга да өйрәтә алмадык ич. Уйладым-уйладым да, уйлап таптым менә. Иманым камил: Рәсимнең теге «кызга» яза торган хатлары аны яңа әлифбаны өйрәнергә дә мәҗбүр итәчәк, киләсе сыйныфка да ул уңышлы күчәчәк. Әйткән иде, диярсең! Элеккеге язуны, бик беләсең килсә, мин үзем дә сиңа хатлар язганга күрә генә үзләштерә алган идем.

Төрекчәдән
***Марат Закир** тәрҗемәсе*

*Translation of **Marat Zakir** from Turkish* ■

ӨЙЛӘНҮ

Хикәя

Мохтар Әүэзов
(1897-1961)

MARRIAGE (Story)
Mukhtar Auezov

Җәйге челләнең эссе бер көне. Көннең дә нәкъ төшке бер күлеме, көн урталары. Күк йөзе аяз, ник бер болыт әсәре күренсен. Нәкъ баш түбәсендә торган кояш җирне кыздыра, өтә сыман. Аңа күтәрелеп карап та булмый, күз чагылып ирексездән йомыла. Тын алырлык түгел — бөркү һава сулышка каба, буылган кебек тоясың үзеңне. Әйе, мондый көннең кызуы кешеләрне әлсерәтә, тын кысыла, тән үзеннән-үзе авырая бара. Шунда берәр җайдан талгын гына җил исеп куйса да, хәлсезләнгән тәннәргә нинди рәхәт булып китәр иде!

Әйе, мондый көндә күләгәдә ятуың хәерлерәк. Җанга рәхәт тапсаң да, шул иркен ак тирмә эчендә генә табарсың. Җил йөрсен дип ишек белән төнлек өстендәге киезләрне кайтарып та куйсаң, һава бөркүлеген тоймый да башлыйсың.

Байбулсын хаҗи авылы әле шушы көннәрдә генә бу җәйләүгә күчеп килде. Биредә көтүлекләр иркен, тугайда үлән мул, су күп. Еракта күкселләнеп утырган биек таулардан башланган инеш бу тирәгә агып килә-килә киңәя, зурая, акрыная. Шушы талгын елга ярына сибелеп утырган ак, соры төстәге тирмәләр, алар өстеннән күтәрелгән күксел төтен баганалары тирә-якта кипшенеп, саргая барган киң даланың күңелле бер почмагы сыман. Яшел үзән буйлап утырган берән-сәрән авыллар сары дала уртасында ерактан ук күренеп, ерактан ук күңелне үзләренә тартып торалар. Байбулсын хаҗи авылы исә башкалардан бер читтәрәк, алардан көнбатыштарак урнашкан иде. Әйткәнебезчә, ул елга-үзәннең суы мулрак, тугайлары иркенрәк бер төшенә утырган. Хаҗиның ишле малына ишле көтүлек кирәк, билгеле. Текә ярлы елга аръягындагы сөзәк калкулыкка күтәрелүгә, хаҗиның авылы күренеп тора.

Авылда барлыгы унбер-уникеләп киез тирмә. Боларның дүртесе — зур ак тирмәләр. Берсе Байбулсын байның үз өе, икесе — аерылып чыккан балаларыныкы. Ә дүртенчесендә, матурлап, бизәкләп сугылган яңа киезле биш канатлысында — аның кызы. Кияүгә биреләчәк кыз атавы бу. Авылның калган өйләре күбесенчә кечкенә — өч-дүрт канатлы тирмәләр бер-берсенә сыеныбрак утырган сыман күренә.

Башлыча болар байның кош-кортын, малын караучы ярлырак кардәш-ыру атаулары, канатлы кечерәк тирмәләр — байның ярлырак кардәшләре белән ялчыларныкы булыр.

Киез өйләрдән ике йөз адымнар читтәрәк ат бәйләр өчен баганалар утыртылган. Тик әлегә анда ат заты күренми, бәйдә берничә колын гына. Дәү атлар су буенда. Төркем-төркем өерелешкәннәр дә елга эченә үк кереп басканнар. Ни чыдам ат хайваны да түзми шул бу эссегә. Хәер, атларга кешеләргә караганда авыррак: кигәвен дә интектерә аларны. Ул бызылдыклардан һичничек котыла алмый малкайлар. Атларның беришe суга сыртыннан ук кереп баскан. Шулай да тынгылык юк мескенгә. Теге бәйләнчек затларны әле пошкырып, әле баш чайкап, әле сырт буена койрык белән шапшоп суккалап куркытырга туры килә.

Сыерларга исә атлардан да яманрак әләгә. Сыер малы үзе дә түземсезрәк шул, эссене дә, суыкны да алар авыр кичерәләр. Кигәвен — аларның җан дошманы, тәмам шаштыра ул аларны. Кигәвеннең безелдәп килүен ерактан ишетеп алу белән сыерлар нишләргә белми котырына башлыйлар, шуннан бер түземсезрәге койрык чәнчеп йә авылга, йә суга таба чабарга тотына. Башкалары аңа иярә.

Бүген дә, эсседән һәм кигәвеннән котылырга теләп, атлар да, сыерлар да суга кереп баскан, тын гына торалар иде.

Ә авылда исә, киресенчә, көтелмәгән бер җанлылык сизелә. Шулай булмый ни, кичә кич бит бирегә буласы кияү үзе килеп төште. Яучы һәм якыннары белән килде кияү. Шуңа күрә дә, тышта никадәр генә эссе булмасын, җәйләү халкы иртәдән үк аяк өстендә. Яшь җилкенчәкнең, аеруча яшь килен белән яшь кызларның йөзе шат, күңелләре хуш күренә. Кияү чатырының киез ишеге бер дә төшеп тормый: берсе керсә, икенчеләре чыга. Кияү белән танышырга дип, Байбулсын авылыннан гына түгел, якын һәм ерак авыллардан килә кешеләр. Иртәдән бирле килгән-киткәннең сөйләшкән, көлешкән авазыннан җәйләү тынмый. Олысы-кечесе, кызы-килене кияүне хөрмәтләп сүз әйтә, туйны котлый.

Байның киенеп-ясанып алган үз киленнәре дә, аларга булышчы кызлар да кияү тирмәсе тирәсендә. Туктаусыз кереп-чыгып йөриләр, кадерле кунакларны сыйлыйлар. Тик әлегә кияүнең дә, кияү егетләренең дә җәйләүдә күренгәннәре юк. Яшь ит, яңа кымыз, уен-көлке, шаян сүз белән юанып өйдә утыралар. Инде ничә табак кымыз чыгарылганын да хәтерләүче юк. Савытлар бушый тора, кымыз өстәлә тора, телләр язылa төшә, сүз-бәхәсләр куера бара. Егетләрнең кызуыраклары инде, әңгәмәдәш эзләп, табынның бер очыннан икенче очына җиткәннәр. Менә берәү кулына думбра алып, аның кылларын чиртә башлады, аннары салмак кына итеп нечкә, йомшак тавышы белән көй сузып, җырлап җибәрде. Тирә-якка мәгълүм җырчы Матай тавышы иде бу. Аны, әйтер сүзеңне онытып, онытылып тыңламый мөмкин түгел!

Бу күңелле шау-шуга бары тик олылар гына катнашмыйлар. Кияү янында булу аларга килешми. Алар авыл кырыенда, су буенда сөйләшеп, хатирәләргә бирелеп утыралар. Бик күбесенең үз-үзен бик дәрәҗәле, эре тотарга тырышуыннан ук боларның бик мөхтәрәм кунак икәннәре чамалана. Аларның хаҗи бай белән кияүгә хөрмәт йөзеннән генә монда килгәнлекләрен дә бик белгертәселәре килә. Кияү дә бит бик мөхтәрәм ир, шундый ук бай авыл кешесе. Быелгы сайлауларда аның «ширкәте» җиңеп чыкты, аның үзен тирә-як авыллар өстеннән баш «башкарма» иттеләр. Дөрес, болай карап торышка аның башкалардан бер аермасы да юк: ни батырлык, ни берәр төрле осталык белән алдырмаган. Булган даны да ата даны гына. Әйтәләр бит: «Авызы

чалыш булса да, бай баласы һәрчак туры, хак сөйли», — дип.

Кияү бүген, булган бу дандәрәҗәләрем генә җитмәсә, дигән кебек, үзе белән Усман түрәне дә алып килгән. Ә инде сайлау «йоласын» белгән һәркем Усман түрәнең инде дүртенче өяз башлыгын «күтәрүен» чамалый иде. Әнә бит шуңа күрә Касыйм да аның алдында ничек кенә яхшы атлы булырга белми, җаена туры килсә дә, килмәсә дә, һаман мактарга гына тора. «Усман түрәдән дә галимрәк кеше юк бездә», — дип җибәрә. Касыйм «башкарма» үзе дә остазыннан күп нәрсәне отып калмакчы. Аңа бигрәк тә остаз түрәнең кешеләр белән тотышы ошый. Үзен Усман шикелле үк дәрәҗәдә торткан бер генә бай түрәне дә әле аның күргәне булмады. Менә ичмасам түрә! Әлбәттә, Усманның кияү егете булып килүе туйны бермә-бер күтәрәчәк иде. Шул өмет белән чакырды да инде Касыйм аны үзе белән.

Дөрес, Усман түрәнең бер кимчелеге дә бар, ул дала сәясәтен, дала тормышын белеп бетерми. Әмма «казакъ халкына булган мәхәббәтен» истә тотып, ул Касыйм тәкъдимен кире какмаган, Байбулсын кызын алышырга килгән.

Яңа өяз башлыгы шулай ук изге теләк белән йөри, аның тукаллы, ягъни икенче хатынлы буласы килә иде. Ашына күрә табагы дигәндәй, бу хәлендә аңа Байбулсын хаҗи кызыннан да ким кәләш килешми иде. Шуңа күрә ул аны башта яучылады, ата-анасының ризалыгын алды. Инде үзе килде.

Касыймга хәзер кырык яшь чамасы. Чәчәк авыруы кайчандыр аның битен бераз бозган, шадралаткан иде. Ә болай үзе таза гына гәүдәле, дәүрәк башлы ир затыннан. Сыек кына сакалы да бар. Сүзгә артык осталыгы булмаса да, үзен, кирәк чагында, шактый тапкыр кеше дип белә. Әнә бит әле шул тапкырлыгы аркасында ул Усман түрәне тапты... Әйе, Усман түрәне ул нәрсәсе белән алдыргандыр инде. Бәлки, остазы әйткән һәр сүзне дөньяның бөек ачышы итеп кабул итүе аларны шулай якынайткандыр.

Берникадәр вакыт утырганнан соң, Усман түрә йөреп кермәкче булды. Аңа үзенең «адъютанты» һәм башкалар иярделәр. Әмма һава бөркүлеге әле сүрелмәгән иде. Усман тиз әлсерәде. Ләкин кияү тирмәсенә шундук кире кайтып керүне хуп күрмәде. Башкалар ни әйтер, ни уйлар? Әле бит аның авыл белән танышасы бар. Йорттан йортка йөреп киттеләр. Күшәп яткан сарык очраса да, чәбәләп чапкан сыер күренсә дә, бик озаклап, ниндидер мәгънә эзләгән кебек итеп карап тордылар. Түрә, бәйләүдәге колыннарны күреп, бөтенләй гаҗәпләнгәндәй итте: «Бу бичаралар ничек түзә эсседә... Бигрәк каты бәгырьле инде безнең казакъ халкы!» — диде.

Урам уртасында учак өстендә эремчек кайнатучы карчыкка юлыгу зур вакыйга булды.

— Монардан ни ясыйсыз гой, кәмпер? — диде түрә тукталып. Аннары җентекләп бу эшнең ничек башкарылуын сорашырга кереште. Түрәне озатып килүче егетләр, астан гына елмаешып-көлешеп торсалар да, ара-тирә сүзен җөпләп: «Эремчексез вә кортсыз булмый инде ул безнең казакъ тормышында», — диешкәләделәр. Әй, Усман, Усман! Әнисенең дә шулай корт кайнатуларын, аптыратма дип, ара-тирә үзен казан тирәсеннән аш чүмече белән куууларын оныткан лабаса.

Шулай туктала-туктала, җәйләүне бер әйләнеп чыккач кына, кияү янына кайттылар. Касыйм Усманны көткән икән. Шундук бер читкәрәк чакырып: «Сөйләшәсе сүз бар», — диде. Җиләс һавалы тирмә эченнән чыгасы килми иде. Мәгәр, аулак эзләп, тагын далагарак карап киттеләр. Тирмәләрдән илле-алтмыш адым ераклашкач, чирәмгә утырыштылар. Касыйм күтәрелеп карамыйча, киресенчә, дәү бүреген каш

өстенәрәк тартып, башын тагын да ия төшеп, сүз башлады:

— Түрә! Миңа бик күңелсез хәбәр ишеттерделәр әле. Бер дә күңелгә ятмый торган сүз. Нишләргә? Үзегезгә мәгълүм, мин Байбулсын хаҗиның кызын алдан яучыладым. Ата-анасы миңа ризалык бирделәр. Калымның да байтак өлеше — вәгъдәләшкән аяклы мал аларда инде. Хәзер аптыраган, ата-анага бу хакта белгертүче булгандырмы, юкмы, кызлары миңа кияүгә чыгудан баш тарта, имеш. «Заманалар башка хәзер, без ирекле, ул миңа өмет итмәсен. Хатыны, гаиләсе бар, үзе миннән карт», — дип әйтә ди. Тутасына тагын әйтеп чыгарган: «Әйткәннәремә генә күнмәсә, бу хакта Усман түрәгә җиткерермен, закон нигезендә яклау табармын», — дигән.

Моңа син ни әйтәсең? Ни киңәш бирәсең? Без бит инде ярәшкән дип кичә дә, бүген дә үзен аулакка чакырып карадым. «Бармыйм»нан башка җавап ишетмәдем. Инде килешенгән, малы түләнгән, туйга дип җыелып килгәнбез. Шул исәптән сезне дә бик мәшәкатьләдем — каладан китерттем. Туйны күтәрерсез дип хыялланган идем. Инде бар ышанычым Сездә. Сез бит… болай мәсхәрә булырга ирек бирмәссез. Үзе дә бит Сезгә зарланырга, Сезгә ышыкланырга уйлаган. Сез генә аны үгетли аласыз. Зинһар, ахмаклык эшләмәсен. Үгетләгез, тыңлар ул Сезне!

Усман түрә бер ара тирән уйга чумган сыман башын иеп утырды. Аннары:

— Ярый, мин аның белән сөйләшермен. Замана башка булса да, кыз кешегә әдәп саклау кирәк. Казакъның ата-бабадан килгән йоласына кул селтәргә ярамас! — диде.

— Дөресен әйтәсең, түрә, — дип, аның сүзләренә сөенүен белдерде кияү. — Ул «ирек» дигән канунда ярәшкән кыз кияүдән баш тартырга хаклы диелмәгәндер бит? Һич тә алай түгелдер!

Усман эшне озакка сузарга ниятләми иде. Турыдан кәләш тирмәсенә юл тотты. Кызны әле ул күрмәгән иде, күңелендә аның белән кызыксыну уянды. Кызның өе кияү чатырыннан ерак түгел. Кыз тирмәсе ишеге төбендә тукталып, тиз генә өс-башын каккалап, чәчен тарап алды да, килгәнен белгертү өчен тамак кырып, эчкә үтте. Кыз юрган-түшәкләр өеме янында кул машинасы белән нидер тегеп утыра иде. Янында башка һичкем күренмәде. Җәмиләнең бөтен яктан да килгән матур кыз икәнен аңлау өчен ике карап торасы түгел иде. Кара чәч үремнәре өстендә чиккән затлы калфак. Йөзе апак, ачык. Бит алмалары чак кына алсуланып тора, уртада сөйкемле, туры борын. Кара бәрхет камзул белән озын ак күлмәк сын-буена сарылып, килешеп кенә тора.

Башта Усман, дустының кәләшен күрү белән, бераз каушап, аптырап калды. Хәтта кыз алдында нинди дә булса яхшылык эшлисе килеп китте аның. Үз кадерен белеп кенә, кунак урынына үтте, Җәмилә белән танышып күреште. Кыз да шундый ук осталык, тыйнаклык белән аңа җавап бирде, күз сирпеп кенә карап-карап алгалады.

Усман, берникадәр вакыт төрле юк-бар, шаян сүз белән мавыкканнан соң, мәсьәләнең асылын, Касыймның рәнҗүе хакында сөйли башлады. Җәмилә бу үзгәрешкә гаҗәпсенгән төсле итеп аңа текәлеп карап тора иде.

— Әти-әниегез инде сезне ярәшкән. Кияү буласы зат ихтирамга лаек кеше, бик зур түрә хәзер. Уйлап, барын да чамалап әйттегезме икән аңа «бармыйм» дип белдергәндә? Ялгышмадыгызмы икән? Бәлки һич тә алай итәсе түгелдер, — дип, кызны үгетләргә тырышты Усман. Дөрес, Җәмиләгә боларны әйтү җиңел булмады аңа. Җәмилә исә бер дә каушап та калмады, бүлдермәде дә. Усман түрә бутала-бутала сүзен төгәлләгәч, аның күзенә туп-туры карап әйтте.

— Боларны сез чын күңелдән сөйлисез дип ышануы кыен. Сез —

кияүнең кунагы, шуңа аның сүзен сүз итмәкче буласыз, — диде.

Усман ни дияргә дә белми аптырап калды. Үзен ике ут арасында кебек тойды. Шулай да ягымлы елмаеп дәвам итте:

— Бәлки, сез дә хаклыдырсыз. Әмма мин үз сүзләремә әле туры җавап алмадым. Ни дип әйтергә кияүгә? — диде.

— Бу тәкъдим белән башка берәү килсә, мин бер дә аптырамас идем. Сез боларны әйтеп карагач, мин ни дим? Без бит сезне бу мәсьәләдә хатын-кызны яклаучы дип, таянычыбыз дип белә идек. Хатын-кыз ирке хакында сездән күпме ишеткән идек. Инде бүген димче булу сезгә килешерме? Мин белмим…

— Ул кадәр үк рәнҗетмәгез мине, Җәмилә. Димче, имеш. Арадашчы… Юк!..

Җәмилә күз карашы белән генә елмаеп куйды.

— Рәхмәт бу сүзегезгә. Мин бит сезгә таяныч итеп… олы ышаныч багладым югыйсә. Аңларсыз хәлемне, дип уйладым. Сез бит зур кеше, түрә. Үзегез шундый яшь икәнсез… Сез дә аңламагач…

Усманның каршы әйтер сүзе калмаган иде. Бу юлы ул үзен җиңелгәнгә санады. Кызның кыюлыгы, тапкыр сүзләре аңа ошады. Ә инде Җәмиләнең аны үз тиңедәй күреп, «сез шундый яшь, сез дә аңламагач», дип сүзен бетерүе бөтенләй фикерен чуалтып җибәрде. Әх, ул караш, ул күзләр! Һәрьяклап уңган да, бик сөйкемле дә икәнсең бит, Җәмилә! Акыл дисәң дә, төс-бит дисәң дә бар үзеңдә. Нишләп соң әле Усман шуны күрмәмешкә салышып утыра?

Шәһәрчә киенгән, ыспай, «галим» егет Җәмиләнең күңеленә дә хуш килгән, кыз күңелен дә кузгаткан иде шул. Алар берара сүзсез генә берберенә карашып утырдылар. Күз карашлары күңел түрендәген әйтеп салды. Кияү Касыйм кайгысы онытылды.

Ә бу вакыт «кияү» үз тирмәсендә ут йотып, түрәнең үз язмышын хәл итүен көтеп утыра иде.

Усман белән кыз, күптәнге танышлар кебек, сөйләшеп киттеләр. Торган саен Җәмилә түрәгә ошый төште. Торган саен Усман түрә тәвәккәлләнә барды. Хатын-кыз алдында югалып калучылардан түгел иде шул ул! Сүз иярә сүз чыгып, күңел түрендәген әйтер җае да табылды. Кыз да моны күптән көтә иде. Ул:

— Тик без мәңгегә, мәңгегә бергә булырга сүз куешсак кына… — диде.

Усман аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде, биленнән кочып тотып, суырып үбеп тә алды. Җәмилә каушап калды. Ялт итеп ишек ягына карап куйды. «Килеп керсәләр…» — дип пышылдады.

Ике сөйгән ярга тагын ни кала иде — ничек кавышу хакында уйлашасы, «туй» мәсьәләсен хәл итәсе бар иде. Ашыкмаска, алдан беркемгә берни сиздермичә, эш итәргә уйлаштылар. Башта Касыйм «кияү»не ризалык бирми кайтарып җибәрергә кирәк. Шуннан соң Усман түрә, ерак шәһәренә кайтышлый, Җәмилә артыннан керәчәк тә үзе белән аны алып китәчәк. Шулай килештеләр, тагын бер кат кочаклашып үбештеләр дә аерылыштылар.

Кияү тирмәсенә кайткач, Усман түрә, әлбәттә, кыз белән үзенең вәгъдәләшүен әйтеп тормады. Җәмиләне төрлечә үгетләп каравын, шулай да берничек күндерә алмавын аңлатты. Бик тискәре кыз икән, дигән булды. «Инде миннән дә бу эш барып чыкмагач, кемнең дә булса Җәмиләне ризалаштыра алырына өмет өзелде», — дип бетерде ул сүзен.

Касыйм моңа ышанды да, ышанмады да. Ничек инде ул алай, ата-ана ризалыгы белән ярәшкән кыз аңа кияүгә чыгудан баш тарта алсын ди?! Кияү һаман шул хакта уйланды.

Ул арада авыл буйлап Байбулсын хаҗи кызының «башкарма» Касыймга кияүгә чыгудан баш тартуы турындагы хәбәр таралып өлгерде. Ерактан урап,

бу хәбәр ата-ана колагына да барып ирешә. Ай Аллам, ата-анага моның хурлыгы ни тора! Кеше күзенә хәзер алар ничек күренерләр дә, туйга дип җыенып килгән кунаклар, туган-тумача моңа ни дип әйтерләр? Алар күбрәк шул хакта борчылды. Шулай да заманалар башка, күрәләтә үз кызыңны көчләп кияүгә бирә торган чак түгел иде.

Иртәгә билгеләнгән туй таралды. Авылда моңсу бер тынлык урнашкан кебек булды: картлар да, яшьләр дә — туйга дип төрле тарафтан килгән егетләр-кызлар да — шыпырт кына таралыша башладылар. Җәмиләне төрлечә үгетләүләр дәвам итте. Кардәш-ыру да, могтәбәр кунаклар да аңа сүз катып карадылар. Җәмиләдән исә «юк», «бармыйм»нан башка сүз ала алмадылар. Аннан соң ярәшкән кияүгә: «Бераз көтәргә туры килер инде. Кызыбыз никтер киреләнә. Күңелегезгә авыр алмагыз. Ике атнадан соң хәбәрләшербез... Күнәр, ата-ана сүзенә дә күнмәсә...» — дип белдерергә мәҗбүр булдылар.

Касыйм «кияү» белән кияү егетләре шул төнне үк үз авылларына таралыштылар.

Бу вакыйгалардан соң тагын биш көн үтте. Көннәр һаман эссе, аяз тора иде. Көндезге эсседән әлсерәгән авыл халкы йокыга талу белән, Байбулсын хаҗи җәйләвенә яхшы атлар җигелгән зур тарантас килеп туктады. Алдан вәгъдәләшкән буенча Усман түрәнең Җәмилә артыннан дип килүе иде бу.

Түрә үз теләгенә ирешү өчен хәйләне нык корган иде. Башта ул Касыйм белән бергә китте. Биш көн буе «кияү» авылында, тегенең кайгысын уртаклашып, аны юаткан булып йөрде. Түрә болай астыртын эш йөртәдер дип кемнең башына килсен!

Тарантас авылдан бер читкәрәк килеп тукталгач та, җәйләүдә ике шәүлә күренде. Дөрес, бу минутлар түземсезләнеп көткән Усманга сәгатьләр булып тоелды. Өстә, биектә, аерым-аерым йолдызлар җемелдәшә, кайдадыр терлек-хайваннар кыймылдашып куйгалыйлар, ә тирмәләр ягыннан бернинди дә тавыш килми сыман иде. Әллә... Әллә...

Берәр сәгать чамасы шулай газап чиккәннән соң, колакка тонык кына итеп, чулпы чылтыраганы ишетелеп киткән сымак булды. Җиргә иелебрәк карагач, ике шәүлә килгәне дә күренеп калды. Менә бераздан алар якын ук килеп җиттеләр. Үзара әкрен генә сөйләшүләре дә ишетелә хәзер. Хатын-кыз тавышы. Менә берсенең өстендәге ак күлмәге ялтырап күренеп калды. Җәмилә!

Усман, канатланып, аңа каршы йөгерде. Куллар кулга тотыныштылар. Җәмилә, кеше-кара күзенә чалынмас өчен дип, башына кара чапан бөркәнгән икән. Чапанны озата килүче җиңгәсенә салып бирде. Аннары алар тиз генә саубуллаштылар да — тарантас кузгалып та китте. Ашыгырга кирәк иде. Шәһәргә кадәр йөз чакрым кайтасы бар. Таң атар, авыл халкы, уянып, кәләшнең юкка чыгуын чамалар. Якын-тирә авылларга чапкыннар чаптырырлар. Ул чакны инде бәхетле Җәмилә белән бәхетле Усман ерак калада булырлар.

Байбулсын хаҗи җәйләвендәге тәшвиш шул кичне үк Касыйм «кияү» авылына да барып җитте. Хаҗи байныкылар, башта ни дип уйларга да белми, аптырашта калганнар иде. Төш вакытлары авышкач та, Җәмиләне якын-тирәдән тапмагач, ата-ана кызларының кемгәдер «ябышып» еракка китүен абайладылар. Тик кая, кемгә? Кем ияртеп киткән аны — бу кадәресен әле тагын бер көн белми аптырашта тордылар.

Баксаң, бу — галим түрә эше икән.

*Казахчадан **Лирон Хәмидуллин** тәрҗемәсе*

*Translation of **Liron Khamidullin** from Kazah* ■

Дөньяда спорт төрләре дә, көч сынашулар да бихисап. Һәр халыкның үз көрәш төре булу – көч сынашуларның, чыннан да, бик борынгыдан килүен раслый. Моны археологлар казып тапкан табылдыклар, борынгы рәсемнәр дә раслый. Әйтик, борынгы грек илендәге Фиохxотен каберлегендә табылган бер рәсемдә көрәш алымнары сурәтләнгән. Тарихчылар исә әлеге рәсемнең б.э.к. берничә дистә мең еллар элек ясалганлыгы хакында әйтәләр.

БЕЗНЕҢ НИЧЕК КӨРӘШКӘННЕ ТАРИХ БЕЛЕП ТОРА...

Алмаз Гафиятов, *КФУ аспиранты*

THE HISTORY KNOWS HOW WE WERE FIGHTING…
Almaz Gafiyatov, post-graduate student of KSU

Археологлар тарафыннан Алтай төбәгендәге Ордос дигән урында табылган бил каешы каптыргычына да биш мең елдан артык. Анда көндәшләрнең бер-берсе биленнән тотып көрәшүе сурәтләнгән. Сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрелеп, бронза кадәр бронзадан коярлык булгач, көрәш ул чорда гына тумагандыр, ә бәлки, шактый элегрәк барлыкка килгәндер.

Әлеге археологик табылдык безгә бик якын. Ни өченме? Чөнки без чыгышыбыз белән шул яктан. Әйе, бүгенге Таулы Алтай яклары төрки халыкларның борынгы ватаны булып санала. VI гасырда оешып, 740 елларга кадәр яшәгән, байтак халыкларга үз дәүләтчелеген оештырырга үрнәк күрсәткән Төрки каганат нәкъ менә шунда булган. Әлбәттә, аңа кадәр һәм аннан соң тарих җилләре безнең бабайларны — болгар-кыпчак төркиләрен — Идел, Каспий, Дон буйларына гына түгел, бөтен дөнья буйлап сипкән.

Иң әүвәле Олимпия уеннары тарихына күз салыйк. Әлеге ярышлар борынгы Грециядә б.э.к. 900 еллар чамасы элек барлыкка килгән. Һәрхәлдә, Олимпия уеннарына багышланган беренче язма б.э.к. 884 елга карый. Аның ярышлар программасында башта йөгерү төрләре һәм ат чабышлары гына булган. Соңрак программага хәзер без грек-рим көрәше дип атап йөрткән көч сынашу да килеп керә.

Бераз алгарак китеп булса да әйтик, әлеге көрәш төре безнең көрәшебезгә бик якын. Иң зур аерма шунда:

безнекеләр кулларына сөлге, билбау тотып, яисә аны билләренә бәйләп көч сынашалар. Грек-рим көрәшендә исә сөлгеләр, билбаулар юк, әмма ирекле көрәштәге кебек билдән аска, ягъни аякларга, ботка тотынырга ярамый.

Олимпия уеннарын һәм безнең сабан туен (бу очракта мин беренче чиратта үзебезнең татар көрәшен генә түгел, ә үзбәк, казах, кыргыз, төрекмән, карачай кебек халыкларның милли көрәшләрен дә күздә тотам) чагыштырып карасак, байтак кына уртаклыкларын күрәбез. Шулай икән, безнең милли бәйрәмебез сабан туе да бәлки грекларның Олимпия уеннары белән бергә, ә бәлки аңардан да алда барлыкка килгәндер.

Алдарак без һәр халыкның диярлек үз көрәш төре бар, дигән идек. Бу чыннан да шулай. Ә менә шул көрәшләрнең алымнарын, кагыйдәләрен берләштереп гомуми бер көч сынашу төрен уйлап чыгарырга омтылулар элегрәк тә булган һәм хәзер дә очраштыргалап тора. Әйтик, XX гасыр башларында, дөресрәге, 1925-1930 елларда СССРда СамБО дип аталган көрәш төре барлыкка килә. Исеменнән үк күренгәнчә (Самозащита Без Оружия), яңа көрәш төре, иң беренче чиратта, илгә көчле, батыр, бернинди дошман алдында да куркып калмаучы солдатлар җитештерүне максат итеп куя һәм үз максатына күпмедер дәрәҗәдә ирешә дә. Самбо көрәшенең төп өлешенә илдә яшәүче төрле милләт халыкларының көрәш алымнары салынган.

Бүген самбо белән дөньяның 170тән артык илендә шөгыльләнсәләр дә, ул Олимпия Уеннары программасына кертелмәгән әле. Ә моннан унбиш еллар элек барлыкка килгән көч сынашу — билбаулы көрәшнең дөньяны яулаячагына ышаныч зуррак. Русча «борьба на поясах» дип аталган әлеге спорт төре милли көрәшебездән әллә ни аерылмый. Аңа шулай ук төрки халыклар һәм, нигездә, мөселман динен тотучы халыклар (үзбәк, казах, кыргыз, карачай, таҗик) көрәшендәге бик күп алымнар кергән. Бүген дөньяның җитмешләп илендә билбау көрәше федерацияләре бар һәм алар көннән-көн арта бара. Әлеге көрәш төре 2013 елда Казанда үткән Универсиада программасына да кертелде һәм аның классик төрендә катнашкан алты егетебез дә алтын медальләр яулады.

Келәмдәге финал очрашуларын Россиянең спорт министры Виталий Мутко да зур кызыксыну белән карап утырды һәм журналистларга: «Меңәр еллык тарихы булган татар көрәшен алга таба Олимпия Уеннары программасына кертсәң дә, йөзебез кызармаячак!», — дип белдерде.

Россия 2024 елгы җәйге Олимпия Уеннарын үзендә үткәрү өчен, кандидатурасын МОКка, ягъни Халыкара Олимпия комитетына тәкъдим итәргә җыена. Әлеге хыял тормышка ашса, Олимпиадага, нигездә, татарча көрәш элементларыннан торган билбаулы көрәшнең дә керү ихтималы зур. Чыннан да, үз көрәш төрләрен (дзюдо, ушу, тхэквондо) зур халыкара ярышлар программасына күптән керткән японнардан, кытайлардан, кореялеләрдән безнең кай җиребез ким?! ■

Фото inkazan.ru

ТАРИХИ МИРАС

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ*

Йосыф Акчура

YENI TÜRK DEVLETININ ÖNCÜLERI

Yusuf Akçura

КӨНБАТЫШ ТӨРЕКЛӘРЕНДӘ ТӨРЕКЧЕЛЕКНЕҢ ИКЕНЧЕ ДӘВЕРЕ

1865-1879 елларда, Кырым сугышы азагыннан һәм Русиянең Төркестанны басып алу хәрәкәтнең әүвәлге дәвереннән соң, 1876-1880 елларда көнбатыш төрекләрендә милләтчелек фикере яңадан җанлануын күрәбез. Бу дәвернең төрекчеләре — Сөләйман паша [1] белән үзбәкләр шәехе Сөләйман әфәнде һәм румилеле Әхмәт Мидхәт [2] белән Әхмәт Җәүдәт пашалар. Бу чор төрекчелегендә тел, тарих, мәгариф, сәясәт тармаклары мәйданга чыга.

Төркичелекне болай дәверләргә бүлгәннән, алар арасында ниндидер аерымлану күрү чынлыкка туры килмәс иде. Тик фикер сөреше генә аерымлана. Али паша [3] вафатыннан соң, солтан Габделгазиз [4] истибдады (реакциясе) котырына. Баш вәзир урынын биләгән Мәхмүд Нәдим паша [5] һәм аның иярченнәре патшаның кәефен саклап, аның реакцион фикерләренә һәм чыгышларына комачаулык күрсәтмиләр. Шул сәбәпле, Танзимат заманына [6] караганда, хөрриятпәрвәрлек күпкә кимегән иде. 1871 елга, барлык фикри хәрәкәтләр кебек үк, төрек милләтчелеге хәрәкәте дә җимерелгән иде.

1876 елга таба, Госманлы дәүләтенең күпчелек халкы христиан динендәге халыклар тәшкил иткән Румиле вилаятендә, Европа дәүләтләре һәм, аеруча, Русия империясе тәэсире һәм котыртуы белән революцияләр, халык күтәрелешләре башланып киткәч, солтан һәм вәзирләрнең халык хәрәкәтен бастыру тырышлыклары артканнан артканга, халык шактый кырылганнан соң, ризасызлык авазлары арта, төрле фикер хәрәкәтләре кузгала башлады. Шул шартларда солтан Габделгазиз тәхеттән читләштерелде. Морад V нең [7] акылдан язуы, солтан Габделхәмид IIнең [8] мәшрутиять (конституциячелек) вәгъдә итеп тәхеткә чыгуы, Босния, Һәрсәк (Герцеговина), Сербия, Болгария күтәрелешләре-гыйсьяннары, алардан туган төрек-рус сугышлары (1877-1878) кебек тышкы эшләр вакыйгалары тәэсире кысу-куркытуларга таянган хөкүмәт идарәсен оештыруны котылгысыз итә. Габделхәмид тәхеткә килгәч, тәхеткә ныклап тамырланып алганына кадәр, үз кәефенә карап изүкысулардан сакланыбрак эш йөртә, фикер хөрлеге һәм иҗтимагый эшчәнлек каты кысрыклау астына алынмый.

* Дәвамы. 2014 елның 1 нче санынннан басылып килә.

Төрекчелек фикере хәрәкәтенең икенче дәвере менә шундый заманга туры килә.

СӨЛӘЙМАН ПАША

Габделгазиз тәхеттән төшерелгән заманнарда хәрби мәктәпләр идарәсе башлыгы булган Сөләйман паша төрек милләтчелеге фикеренә хезмәт итүчеләрнең күренеклеләреннән иде. Сөләйман паша эшчәнлегенең беренче дәверендә үк бу юнәлештә эш йөртүе турында хәбәрем юк. 1834 елда тууына караганда, беренче дәвердә үзен күрсәтеп өлгермәве мөмкин. Сөләйман пашаның төрекчелеккә, гомумән укыту-тәрбия өлкәсендәге мөһим хезмәтләре «Җәмгыят-и тәдресия-и исламия» (Ислам педагогик җәмгыяте) һәм хәрби мәктәпләр идарәсе белән бәйләнгән. Солтан Габделгазиз дәверендә хәрби мәктәпләр идарәсе карамагында хәрби мәктәпләр генә түгел, гаскәри игъдадияләр (хәзерлек) һәм гаскәри рөшдияләр (тулы булмаган урта мәктәпләр) дә аның кул астында иделәр. Сөләйман паша җитәкләгән заманда Хәрби мәктәпләр нәзарәтенең статусы Мәгариф министрлыгы дәрәҗәсендә иде. Сөләйман паша хәрби мәктәпләр өчен ике томда «Мөбәниүл инша» (Бина төзү), «Кәбир (зур, олы) гыйльме хаљь», «Сагыйрь (кече) гыйльме хаљь», «Сарф-и төрки» (Төрки тел морфологиясе), «Тарих-и галәм» кебек күп кенә дәреслек-кулланмалар язган кеше. «Сагыйрь гыйльме хаљь»не мин хәрби рөшдиядә укыганда [9] дәреслек итеп файдаланган һәм өйрәнгән идем. Бу зур китап ачык, гади төрки телдә язылган. Китап гарәпчә-фарсыча сүзләрдән һәм терминнардан чистартылган. Мәсәлән, Аллаһ Тәгаләне тәгъриф иткәндә: «Бердер, кәндесенең һич уртагы вә ярдәмчесе юктыр, дөньяда күрдегемез вә белдегемез шәйләр һичберсе аңа биңзәмәс. Ата-анадан, угыл кыздан, уйкудан, эчмәдән, көлмәдән-агламадан, йөренмәдән азаттыр», — дип саф төрки телдә яза. «Мөбаниел иншасы» илә «Сарф-и

Сөләйман паша

төрки»ен табып күздән кичерә алмадым. «Тарих-и галәм» — хәзер күз алдымда тора. Безнеңчә, авторның иң мөһим әсәре дә шул.

Сөләйман пашага, солтан Габделгазиз хакимиятенең соңгы елларында, гаскәрбашы Хөсәен Авни паша [10] тарафыннан хәрби мәктәпләр өчен махсус «Гомуми тарих» дәреслеге язу эше тапшырыла. Шулай итеп «Тарих-и галәм» китабын яза башлаган. Зур күләмле китап язу күз алдында тотылган. Китапның «Әүвәлге гасырлар» бүлеге язылган һәм укучылар кулына тапшырылган. «Урта гасырлар», «Яңа гасырлар» бүлекләрен язарга вакыт табылмаган. Сөләйман паша вафат булган. «Тарихи галәм»нең «Әүвәлге гасырлар» бүлеге 1876 елда, Морад V заманында басылган. Әсәр солтан Габделхәмид дәверендә тыелган китаплар исемлегенә кертелә һәм, булган нөсхәләре Хәрби матбугат архивына тапшырылып, күп елларга күздән югалып торган. Икенче мәшрутиять вакытында [11] мәрхүм Сөләйман паша шәкерте Тәүфикъ паша — Хәрбия мәктәбе җитәкчесе, остазыннан алган төрекчелек рухында үзе дә хәрби игъдадияләр өчен «Тарих-и Госмания» дәреслеге язган кеше. Остазына тирән хөрмәт йөзеннән, аның «Тарих-и галәм»

китабын, Хәрби матбугат архивының дымлы караңгы бүлмәләрендә ертылып-череп ятудан коткарып, дөньяга чыгара, яңадан фәнни әйләнешкә кертә. Кайбер битләренә төзәтмәләр кертеп, 1911 елда яңа басмасын чыгара. Яңа басманың кереш бүлегендә автор файдаланган көнчыгыш һәм көнбатыш чыганаклар күрсәтелә. Чыганаклар арасында де Гюенең «Хуннар тарихы» белән Раймондның «Татар тарихы» һәм Әбелгазыйның «Шәҗәрәи төрек» китаплары да бар. Сөләйман пашага кадәр де Гюедан һәм Раймондтан файдаланып язылган төрек телендәге тарих китаплары безгә билгеле түгел. Фәкать Мостафа Җәләлетдин паша гына, француз телендәге әсәрен язганда де Гюега мөрәҗәгать иткән.

Сөләйман паша «Тарих-и галәм» китабының керешендә әсәрнең язылу сәбәбе турында: «Хәрби мәктәпләрдә укытыла торган гомуми тарих китаплары чит телләрдән сүзгә-сүз тәрҗемә булганга, аларда ислам кагыйдәләренә лаексыз фикерләр бар. Моның өстенә «Борынгы гасырлар» бүлегенә бик аз урын бирелә. Көнчыгыш тарихы вакыйгалары бөтенләй булмау сәбәпле, игътибарны шул кимчелекләрне бетерүгә юнәлтеп, яңа дәреслек язасы иттек», — дип аңалата [12]. Китапның эчтәлегенә күз төшерү белән, күп битләр (җидедән биш өлеше) борынгы төрки тарихка бирелгәнлеге күзгә ташлана. Хәлбуки, Сөләйман паша китабыннан соң басма күргән «Борынгы тарих» дәреслекләрендә, Европа мәктәпләрендә укытыла торган гомуми тарих дәреслекләре үрнәгендә борынгы чорга дәреслекнең егермедән бер өлешен генә бирү гадәткә кертелә.

Сөләйман паша төркиләрнең борынгы тарихына мәхәббәт һәм хөрмәт күрсәтә. Чит һәм төркиләргә ачулы милләтләрнең төрекләргә сылаган ялалы, шөбһәле, төрекләрне усал, явыз холыклы итеп күрсәткән хикәятләрне китабына кертүне кирәк тапмаган. Бик борынгы заманнардан бөтен Азиягә җәелеп хөкем сөргән төрки кавеменең каһарманлыкларын төрек яшьләрен тәрбияләүдә үрнәк материал итеп файдалана. «Тарих-и галәм»нең тәэсирендә күп кенә төрек батырлары барлыкка килә.

Сөләйман пашаның башка әсәрләрендә дә төрекчелек тәэсире күренсә кирәк. Әмма бүген кулыбызда башка документлар булмаганга, бу турыда бернәрсә дә әйтеп булмый. Гөкалып Зыя бәй 1923 елда басылган «Төрекчелек әсаслары» дигән китабында гаскәри рөшдия мәктәпләрендә укытылган «Әсмаи Төркия» («Төркиянең географик аталмалары») китабын да Сөләйман паша әсәре дип күрсәтә. Хәлбуки, безнең кулыбыздагы «Әсмаи Төркия» китабының авторы «Риза бәй» дип язылган.

1. Сөләйман паша (1838-1892) — төрек хәрби начальнигы, генерал (1877).
2. Әхмәд Мидхәт (1844-1913) — төрек язучысы, мәгърифәтче.
3. Мөхәммәд Әмин Али паша (1815-1871) — Госманлы империясенең дәүләт эшлеклесе, вәзир. Танзимат реформалары лидерларыннан берсе.
4. Габделгазиз (1830-1876) — Госманлы империясенең 1861-1876 елларда идарә иткән солтаны.
5. Мәхмүд Нәдим паша (1818-1883) — Госманлы дәүләтенең эшлеклесе, ике мәртәбә империянең бөек вәзире була.
6. Танзимат заманы — Госманлы империясендә 1839, 1876 елларда уздырылган үзгәртеп кору реформалар. 1876 елда Госманлы империясенең беренче Конституциясе кабул ителә.
7. Морад V (1840-1904) — Госманлы империясенең 1876 елның 30 маеннан 31 августына кадәр идарә иткән солтаны.
8. Габделхәмид II (1842-1918) — Госманлы империясенең 1876-1909 елларда идарә иткән солтаны, хәлифәсе.
9. Мәгълүм булганча, Йосыф Акчура 1892-1896 елларда Хәрби мәктәпкә укый.
10. Хөсәен Авни паша (1821-1876) — госманлы маршалы, Госманлы империясенең бөек вәзире.
11. Икенче мәшрутиять вакыты — 1908 елның 3 июлендә булган «Яшь төрекләр» инкыйлабыннан соң икенче Конституция дәвере. 1876 елгы Конституция торгызыла һәм яңадан Парламент җыела.
12. Тарих-и галәм. Кыйсьме әүвәл. Коруне әүвәл / Мәкәтибе Генерал-лейтенант Сөләйман Хүснү. — Истанбул. (Басылган елы күрсәтелмәгән). Й.Акчура искәрмәсе.

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе*
*Türkçe'den çeviren **Mesğud Ğaynetdin***

АЛТЫН УРДА ЧОРЫ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЭТНИК ТАРИХЫНА КАРАТА КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР

Марсель Әхмәтҗанов*

THE THOUGHTS ABOUT ETHNIC HISTORY OF THE TATARS OF GOLDEN HORDE PERIOD

Prof. Marsel Akhmatzyanov

XIV гасырның соңгы чиреге – татар халкы тарихында катлаулы һәм үтә авыр чорларның берсе. Бу дәвердә Алтын Урда ханнары арасында тәхет өчен аяусыз көрәш барган. Кырым Олысында йогынтысы көчәя барган Мамай мирза зур авантюралар оештырып, Болгар Олысына Мәскәү кенәзлеге гаскәрләрен җибәртеп, Идел-Кама төбәгенең икътисадын җимерү юлына баскан.

1380 елда Туктамыш хан Алтын Урда тәхетенә үзенең дәгъвасын белдерә һәм көчле тетрәнүләр кичергән дәүләтне ныгыту чарасына керешә. Ул, ушкуйниклар һәм урыс кенәзләренең туктаусыз һөҗүмнәреннән бөлгенлек хәленә җиткән Болгар олысын ныгыту өчен, 1382 елда Кырым һәм Азак диңгезе буйларында яшәгән халыкларны туплап Идел-Чулман буйларына җибәрә.

Әлеге вакыйгалар татар тарихи чыганакларында берничә вариантта тасвирланып, безнең заманга бу язмаларның XVIII-XIX гасырларга нисбәтле күчерелмәләре килеп җиткән. Чыганакларда Габдулла ханның нәселнәсәбе (Кара бәк шәҗәрәсе) Румнан, Госманлы төрекләреннән, Эрзерумнан, Кырымнан Болгар олысына барып тоташа дип күрсәтелә. Әлбәттә, бу очракта документларга тәнкыйди караш та булырга тиеш. Татар шәҗәрәләренең асылына төшенер өчен шактый зур тәҗрибә кирәк. Мәсәлән, Кара бәк шәҗәрәләренең борынгырак текстларында татарларның, Кырым якларыннан Болгар олысына күчү юлы, шул исәптән хронологиясе дә берникадәр буталган, ә башка тарихи чыганаклар ярдәмендә бу мәгълүматларны шактый төгәлләштерергә мөмкин.

Эпиграфик һәм топонимик чыганакларны өйрәнү 1382 елда Габдулла хан кул астында Кырымнан һәм Кара диңгезнең төньягыннан күченеп килгән төркемнәрнең этник яктан төрле булуын ачыкларга мөмкинлек бирде. Алар арасында, татарлардан тыш, **караимнәр, румнар (орумнар) – төркиләшкән греклар, оетлар (готлар)** булганлыгын да күрсәтә алабыз.

Кырымда яшәүче **караимнәр** борынгы хәзәрләрнең нәсел дәвамчылары һәм яһүд дине вәкилләре булып торалар.

***Редакциядән**: Күптән түгел күренекле галимебез үзенең 75 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Аны юбилее белән ихластан котлыйбыз, исәнлек-саулык һәм яңа иҗат уңышлары телибез!

Морза Хәким Сәлим углына куелган кабер ташы. XIX гасыр. Оренбург өлкәсе Каргалы бистәсе

1989 елда СССРда караимнәрнең саны 2400 кеше булган.

Татарстан Республикасы территориясендә XIV-XV йөзләргә нисбәтле кабер ташларында караимнәр белән бәйлелекне күрсәткән «алтыпочмаклы йолдыз» мотивы төшерү очрагын әйтергә кирәк. Мондый йолдызлы кабер ташларының Кырымдагы караим зиратында да саклануы хакында хәбәрләр бар.

Хронологик яктан иң борынгы «алтыпочмаклы йолдыз» билгесе 1382 елның 13 июлендә үтерелгән Габделҗаббар углы Әйнүк кабере ташына уелган (Биектау районы Ямаширмә авылы зираты). Ул бик тупас эшкәртелгән. Язылган тексты Болгар олысында 1360 елга кадәр куелган башка кабер ташлары арасында саф татар телендә язылышы һәм бик гади бизәлеше белән аерылып тора. Анда датаны аңлаткан «дүрт» саны «түрүт» рәвешендә язылган. Мондый язылыш фәкать Кара бәк нәселенә бәйле эпиграфик текстларда гына очрый. Мәсәлән, Актаныш районы Әҗәкүл авылының зиратындагы кабер ташына «тарих мең дә туксан түрүтдә ирди, Үтәгәннең Килди би углы Ишкәй...» дигән сүзләр уелган, ә Менделеев районы Туйгуҗа авылының зиратында саклanучы кабер ташына «тарих мең дә, йөз дә түрүтдә...» дип язылган. Әлбәттә, бу мисалларның санын тагын да арттырырга мөмкин булыр иде, ләкин күп кабер ташларының текстлары тулы килеш сакланмаган.

Ямаширмә авылы зиратындагы кабер ташыныкы кебек схема рәвешендәге «алтыпочмаклы йолдыз»ны Олы Нырсы авылында (хәзерге Теләче районы) 1443 елның июнь аенда бакый дөньяга күчкән Йосыф ибне Шәйех кабер ташында һәм 1473 елда 6 декабрьдә вафат булган Мөхәммәд углы Әйүб кабер ташында да күрергә мөмкин [1]. Алар эшкәртелү сыйфаты ягыннан XIV гасыр татар кабер ташларыннан нык калышалар. Бу мәрхүмнәрнең 1523 елда Казанда Сахиб-Гәрәй ханнан тарханлык ярлыгы алган кешеләрнең бабалары булганлыгы да ачыкланды.

Кырым татарлары белән этник бәйләнешне Казан арты төбәгендә сакланган мөселман кабер ташларының тагын бер үзенчәлеге дәлилли. Эш шунда ки, биредә зиратларындагы күп кенә кабер ташларының очларында сай түгәрәк яки дүртпочмак рәвешендә чокыр ясалган. Мондый үзенчәлек Казан арты авылларыннан Оренбург янындагы Сәет бистәсенә (хәзер Татар Каргалысы авылы) һәм Әстерхан якларына барып урнашкан татарларның кабер ташларында да очрый. Казан арты ягы кешеләре бу күренешне мифологик ышануларга бәйләп, кеше үлгәч, аның җаны кошка әйләнеп, гәүдәсе күмелгән урынга очып килә, шунлыктан аның җаны (кош) эчәр өчен кабер ташының очында аз гына булса да су җыелып торырга тиеш, дип аңлаталар иде. Ә башка төбәкләрдә бу күренешнең асылын аңлата алмадылар.

Безгә Кырым кабер ташларындагы су чокырларына нисбәтле мондый ышануны фәнни әдәбиятта да очратыр-

га туры килде. Мәшһүр рус тюркологы В.Смирнов кабер ташларындагы су чокырлары һәм җан кошы турындагы сюжетны 1886 елда Кырымда уздырган археографик экспедиция вакытында язып алган [2]. Димәк, бу дини-мифологик ышануны да безнең якларга XIV гасырда Кырымнан килгән мирас дип саный алабыз.

Караим этнонимының татар топонимнарында саклануына да мисаллар бар. Мәсәлән, югарыда искә алынган, зиратында «алтыпочмаклы йолдыз» билгеле кабер ташы сакланган Теләче районындагы Кара Ширмә авылының атамасы да тарихи яктан кызыклы. Авыл исемендә 1382 елда Кырым ягыннан килгән төркемнең этник атамасы чагылыш тапкан. Кара Ширмә янәшәсендә генә Орым Ширмә авылы булу, Ямаширмә, Кара Ширмә, Орым Ширмә исемнәрендәге Ширмә компоненты кабатлану бу авылларның ерак тарихларындагы уртаклык хакында сөйли.

Орым Ширмә авылының исеме кыйммәтле тарихи мәгълүмат саклый. Әлеге топонимдагы **орым** компоненты — XIV гасырлардан Кара һәм Азак диңгезләре буйларында яшәгән төркиләшкән грекларга нисбәтле этноним. Күрәсең, 1382 елда Габдулла хан караимнәр белән төркиләшкән грекларның бер төркемен үзе белән Болгар Олысына алып килгән.

Саба районындагы **Оет** авылы исеменең дә тарихы кызыклы. Бу топоним да Кара диңгез буеннан килгән этнонимнарның берсе. Тарихтан мәгълүм булганча, борынгы готлар V-XV гасырларда Кара диңгез буйларында яшәгәннәр. Аларның бер өлеше болгарлар, бөҗәнәкләр, кыпчаклар, татарлар тарафыннан ассимиляцияләнгән. Готлар татар чыганакларында «оетлар» дигән термин белән аталалар. Аларга ул исемне Кара диңгез буйларындагы күршеләре биргән [3].

Готлар Нугай Урдасы татарларыннан калган дастаннарда да искә алыналар. Мәсәлән, Себер татарларыннан чыккан акын Мәүлекәй Йомачыков 1882 елда Казанда басылган «Кыйсса-и Кара бәк» дастанында:

«Инде әйтәйен җегетләр,
Борынгы үткән батырны:
*Ун мең өйле **ойотны**,*
*Кырык мең өйле **кыйатны**.*
*Туксан мең өйле **коңгыратны**.* —
Шуныңча йортның башы икән,
Кадыйр дигән хан икән.
Кадыйр ханның Кара бәк
Җалгыз туган улы икән...» — дип

яза [4].

Габдулла ханның Кара бәк дип аталуын, Идел буена күченгәнче Кырым ягында аның кул астында кыйат, оет, коңгырат кабиләләре булганлыкны искәртсәң, Оет авылы исеменең мәгънәсе тирәннән ачыла.

Кыйат — Буа районындагы рус авылы исеме. Димәк, бу урында кайчандыр кыйат кабиләсе вәкилләре яшәгән. Әйткәнебезчә, Габдулла хан кул астында кыйатлар да булган, һәм алар Болгар олысында урнашып калганнар.

Коңгыратлар — Габдулла хан белән килгәндә Агыйдел буенда тукталып калып, соңрак Биләр шәһәренә килеп урнашкан кабилә. Ләкин алар Аксак

Арыслангали Габделкадыйр углына куелган кабер ташы. XIX гасыр. Оренбург өлкәсе Каргалы бистәсе

Тимернең 1391-1395 еллардагы һөҗүме вакытларында анда кала алмаганнар.

Татарстан Республикасында Кырым ярымутравы белән уртак булган башка топонимнарны да атап үтик. Мәсәлән, Суыксу топонимы Кырымда бик мәгълүм. Татарстанда да Суыксу (Биектау районы), Татар Суыксуы (Әлки районы), Яңа Суыксу, Иске Суыксу (Буа районы) исемле авыллар бар. Аларның да исемнәрен Кырымнан күчкән кешеләр бирергә мөмкин, дип уйлыйбыз.

Иске Йөрек — Киров өлкәсенең Татарстан чигендә урнашкан татар авылы. Йөрек атамасы угызлардан зур бер төркемнең этнонимы буларак мәгълүм.

Балыклы — Кукмара районындагы авыл. Этник җәһәттән Нократ татарлары белән бәйле. Бу топоним Кырымдагы Балаклава шәһәре исеме белән кардәш.

Кизләү (Нурлат районы) — Кырымда да Гёзлёв шәһәре атамасы булуы мәгълүм [5]. Кырымлылар аркылы бу атама Касыйм татарларына да үтеп кергән.

Чатыр Тау — Азнакай районындагы биек тау атамасы. Кырымда да шул исемдә атаклы тау бар.

Ор — Татарстан Республикасының Арча районында Түбән Оры, Югары Оры, Балтач районында Ор исемле авыллар бар. Кырымда Ор исемле бер шәһәр булуы мәгълүм.

Кече Кирмән, Кирмәнбаш, Урта Кирмән — Мамадыш районындагы авыллар. Кырымда да Яни Кирман, Ик Кирман-Ак Кирман исемле шәһәр атамалары билгеле.

Мангуб — Кырымдагы шул исемле шәһәрдән чыккан борынгы нәсел шәҗәрәсе. Балтач районында «Дийү Мәнгуф нәселе» шәҗәрәсе сакланган.

Карәтмән (Кара Төмән) исемле авыл хәзерге Яшел Үзән районында урнашкан. Биредә яшәүче татарларның бабалары, Карагуҗа авылы риваятьләре буенча, Кырымнан күченеп килгәннәр [6].

Салтык. Кырымда Салтык авылы булган. Татарстанда Салтык этнонимы Кече Салтык, Олы Салтык (Кама Тамагы районы), Салтык Ерыклы (Кукмара районы), Салтык (Менделеевск районы) исемле авыл атамаларында бар.

Карасу — Аксубай районындагы авыл исеме. Кырымда Карасубазар исемле шәһәр бар.

Габдулла хан белән Кырымнан килгән татарларның бер өлеше Урал буйларында ук тукталып калулары гаҗәп түгел. Кара бәк нәсел шәҗәрәләренең таралыш географияләренә караганда, аның белән Болгар Олысына күчеп килгән татарлар Чулманның уң як ярын биләп яшәгәннәр. Аларның тупланып яшәгән урыннары Нократ елгасы буендагы Кирмәнчек шәһәре тирәсендә булган. Казан артындагы авыллардан Кырым белән бәйле Суыксу, Оет, Орым Ширмә, Балыклы, Кара Ширмә, Ямаширмә, Мулла Иле, Кара Гуҗа, Олы Җәке, Тархан, Теләче, Келәче, Яңасала, Котлы Бүкәш, Акташ, Аппак, Субашы авылларын атарга мөмкин.

Кырымнан килүчеләр Касыйм ханлыгында тукталып, аннан Идел буйларына күчеп килеп Тау ягына да утырганнар. Шулай итеп, Борындык, Кыят, Карабай, Яңасала, Тархан, Аксу, Тутай, Шәмәк, Җиде Кизләү, Биябаш, Шәм Балыкчы һ.б. авыллар барлыкка килгән.

Бу авылларның килеп чыгышы проблемасын тарихчы Е.Чернышевның хезмәте белән генә ачыклап булмый, чөнки ул файдаланган төп чыганак 1602-1603 еллардагы теркәү кенәгәсе. Әлеге хезмәт XVI гасырның икенче яртысындагы Казан арты тарихи вазгыятен тулысынча тасвирламый. Эш шунда ки, Казан ханлыгы яулап алынганнан соңгы дәвер белән Е.Чернышев үз хезмәтендә файдаланган 1602-1603 елларга нисбәтле чыганакларда логик эзлеклелек нигезе югалган. Моны торгызу өчен, беренче чиратта, татар шәҗәрәләре материаллары һәм Кырымның XVI-XVII гасырлардагы тарихи топонимиясен чагылдырган ышанычлы карталар кирәк. Эш шунда ки, СССР хөкүмәте Кырым татарла-

рына карата гаделсез һәм шәфкатьсез чаралар кулланып, Кырым ярымутравындагы татар җир-су атамаларын бозып, юкка чыгарып, уйдырма атамалар белән тутырылган карталар бастырып чыгарды.

Ниһаять, 2009 елда Симферополь каласында Кырым җирләренең «1708 тарихи исем, 934 югалган торак пункт» дип исемләнгән топонимик картасы нәшер ителде [7]. Әлбәттә, бу басмага 1920 еллардагы Кырымның күп татарча атамалары кертелмәгән. Мәсәлән, без анда тарихта яхшы мәгълүм булган Балаклава (Балыклы, Чумбали) һәм Кизләү (Кёзлёв) кебек шәһәр атамаларын күрмәдек. Бу бик аяныч, әлбәттә. Шулай да әлеге картадагы борынгы татар топонимнарын һәм аларның структур төзелеше турындагы мәгълүматларны без Татарстан, Касыйм һ.б. регионнар белән чагыштырып, татар этногенезы турында кайбер нәтиҗәләр ясый алабыз.

Әлеге картографик топонимнарны структурасы буенча өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

Беренчесенә структурасы буенча аерым мөстәкыйль лексик берәмлек тәшкил иткән Кыят, Оет, Тархан, Борындык, Тутай кебек атамалар керә.

Икенчесенә ике тамыр сүздән кушып ясалган, аларны бер-береннән аерырга мөмкин булмаган кушма лексика керә: Яңасала, Аппак, Субашы, Акташ, Аксу, Ташкирмән, Суыксу, һ.б.

Өченче төркемгә бер-берсенә логик бәйләнешле, ләкин бер конструктив лексика булмаган атамалар керә: Җиде Кизләү, Олы Җәке, Котлы Бүкәш, Кара Хуҗа, Шәм Балыкчы, Урта Кирмән, Кызыл Кыпчак, Кара Китән, Иске Шәйморза, Иске Табын, Дийү Мангуф, Кара Табын, Чатыр Тау, Яңа Байсар, Иске Байсар һ.б.

Без шул өч төркемгә кергән тарихи топонимнарның структураларына карап, Кырымда һәм бүгенге Татарстан территориясендә милли топонимнар ясау калыбының уртак типологиясе булуын күрә алабыз.

Хәзерге Татарстан туфрагына Кырымнан күченү хәрәкәте бер генә мәртәбә тапкыр булмаганлыгы да билгеле. Тәүге мәртәбә бу хәрәкәткә Габдулла хан нигез салса, 1438 елда Олуг Мөхәммәд хан белән күчеп килүчеләр дә булуы мәгълүм. Шәҗәрәләрне тикшерү нәтиҗәсендә Мөхәммәд-Әмин хан, Сахиб-Гәрәй хан, Сафа-Гәрәй хан заманнарында да Казан ханлыгына Кырымнан килүчеләрнең нәселләре булуы ачыкланды. Казан ханлыгы яулап алынгач, Касыйм ханлыгының Кырымнан чыккан аксөякләре Чанышевлар, Аппаковлар, Яушевлар, Алишевлар, Шакуловлар, Дәүләткилдиевлар, Дибердиевлар һ.б. Казан төбәгенә һәм Урал буйларына күчеп киләләр.

Югарыда саналган фактларны анализлап, түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин: XIV гасырда Кырымнан Болгар Олысына күп кенә татар ыруларының күчеп килүе эпитафик, этнонимик, топонимик чыганаклар белән раслана. Бу фактлар татар халкының этник тарихында әһәмиятле һәм әлегә кадәр җентекле өйрәнелмәгән сәхифәләрне ачып бирәләр, Кырым һәм Болгар Олысы җирләрендәге этник процессларны чагылдыру өстенә, Алтын Урданың тышкы сәяси үсеше ничек барганын да аңларга ярдәм итәләр.

Искәрмәләр:

1. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфию. — М.-Л.: изд-во АН СССР, 1960. (51, 52 нче таблицалар).
2. Смирнов В. Археологическая экскурсия в Крым летом 1886 г. // Записки Восточного отделения императорского русского археологического общества. Том первый. — СПб.: Типогр. императорской АН, 1886.
3. Голденков М. Русь: другая история. — Минск: Современная школа, 2010. — С.55.
4. Кыйсса-и Кара бәк (Казан басылышы, 1882) // Бабалар сүзи. Җөз томлык. Батырлар жыры. — 44 том. — Астана: «Фолиант», 2007. — Б.205-207.
5. Возгрин В.Е. Исторические судьбы крымских татар. — М.: «Мысль», 1992. — С.132.
6. Чура батыр. Татар халык дастаны. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1993.
7. Призраки прошлого на карте Крыма. Топономическая карта. — Симферополь: «Союзкарта», 2009. ■

МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫН КАЙГЫРТЫП...

(Гаяз Исхакый көндәлеге)

GETTING WORRIED ABOUT NATION'S FUTURE...
(The diary of Gayaz Iskhaki)





Татарлар дөньяның төрле кыйтгасында яши. Бүген Төркиядә егерме биш меңгә якын татар яшәве билгеле.[1] Идел-Урал төбәге татарларның Төркиягә күпләп күчүе XIX гасырның икенче яртысында күзәтелә. Һәр күченүнең үз тарихы, үз сәбәбе булган. Төркиягә кайберәүләр гыйлем, бәхет эзләп кузгалса, икенчеләр... Гаяз Исхакый кебек, сәяси сыену урыны эзләп киткән.

Татар әдәбияты классигы, күренекле сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый шактый катлаулы һәм каршылыклы гомер кичерә. Бу, бер яктан, сәяси-иҗтимагый вазгыять белән бәйле булса, икенче яктан, шәхеснең холкы, теләк-омтылышлары белән бәйле.

Тормыш юлы Кама аръягындагы Яуширмә авылында башланган Гаяз Исхакыйны язмыш җилләре урау юллар аша Төркиягә алып килә. Ягъни, 1919 елның язынан әдипнең мөһаҗирлек чоры башлана. Ул, күп кенә Аурупа һәм Азия шәһәрләрен кичеп, 1939 елның ахырларында Төркиягә килә һәм 1954 елның 26 маена кадәр ялгызы Истанбул шәһәрендә яши, гомеренең калган соңгы көннәрен Анкарада кызы белән кияве тәрбиясендә үткәрә.

Туган җирдән читтә яшәү, котылгысыз рәвештә, аның шәхси тормышына да нык

[1] Бүген Бөгределик, Әфәнде Күпере, Гүрсу, Османия авылларында татарлар күпләп яши.

тәэсир итә, иҗат мөмкинлекләрен дә чикли. Ләкин халыктан чыккан әдип буларак, ул, Ватаныннан ерак яшәсә дә, халкыннан аерылмый. Гомере буе үз милләтен саклап калу өчен көрәшә. Үзенең матди барлыгын гына түгел, хәтта гаилә бәхетен дә шул юлда корбан итә.

Г.Исхакый, милләт язмышын кайгыртып, читтә яшәүче татарларны берләштерү юлында гаять күп көч куйган. Ул дөнья буйлап таралган милләттәшләребезне барлап, аларның милли-мәдәни ихтыяҗлары белән кызыксынып, дистәләгән мәмләкәтләрне иңләгән, төрле-төрле кешеләр белән очрашкан. Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге татарларны рухи яктан тәрбияләү максатыннан оештырылган Ерак Көнчыгышка һәм мөселман илләренә сәяхәтләре билгеле.

Рәсми төстәге сәфәрләреннән тыш Г.Исхакый еш кына Истанбулдан ерак булмаган Искешәһәр, Бурса, Ялова шәһәрләрендә була. Мөмкинлек булганда якын тирәдәге татар авылларына да сәяхәт итә. Соңгы елларында бу шәһәрләргә баруының сәбәбе, сәламәтлеге какшаудан, дәвалану, кайнар су чыганакларына керү өчен булса да, Г.Исхакый бервакытта да үзенең төп максатыннан читкә китми, ул, мөһаҗирлектәге татарлар алдында торган көнүзәк мәсьәләләрне кайгыртып, татарларны бердәмлеккә өндәп, читтәге татарлар яшәешенең тарихи алшартлары, тормыш итү рәвешләре, милли гореф-гадәтләрне ничек саклап калулары белән кызыксына, төрле кешеләр белән аралаша.

Татарстан милли архивында 1997 елда Төркиянең Мәңгәр фонды президенты Сафия Имре тапшырган материаллар (2461 фонд) арасында Г.Исхакыйның бер көндәлек дәфтәре саклана. Г.Исхакый үзенең әлеге көндәлегендә шундый сәяхәтләрдән берсе Төркиядәге татар авылы Корыөеккә баруы турында язган.

Г.Исхакыйның түбәндәге язмасы әлеге авыл халкының 1943 елдагы тормышын күзалларга ярдәм итә. Бу көндәлек моңа кадәр тулысынча беркайда да басылмаган, матбугатка беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ 1943 ЕЛГЫ КӨНДӘЛЕК ЯЗМАСЫ

1943 ел, 20 май, пәршәнбә (пәнҗешәмбе) көн иртә берлә сәгать 8дә 30 терәне (поезды) берлә Искешәһәргә таба хәрәкәт итдек. Юлчы ипдәшләремез — Мәрьям ханым, кызы Төзәр. Урынымыз өченче классда. Билетны 7,38гә алдым. Юл бик тыгыр (тыгыз) булучан булганга, беренче вапур (пароход) берлә 6,30да Хәйдәр пашага чыгар өчен сәгать бишдүк тордым. Урынымыз яхшы булды һәм дә бер дә тыгырлык булмады. Терәнемез экспресс булгангамы, юлчылар күп түгел иде. Юл буе ягъмур яуды да торды. Ашлыклар бик һәйбәт, ләкин һава суык. Өйләдән соң бишдә Искешәһәргә килеп җитдек. Куйучы (кое остасы) Әдһәм әфәнде каршы алды. Аның өенә мөсафир (юлаучы) төшдек. Ләкин өе суык иде. Кичкә таба мангал берлә утырдык. Ашап-эчеп, сыйланып, радио тыңлап, сәгать 11ләрдә уйкуга (йокыга) ятдык. Бик арыган булганга, иртәнге сәгать 8гә кадәр уйкуладык. Сау-сәламәт тордык.

21 май, җомга көн, Искешәһәр

....

Бүген көнемез мөсафирлык берлә кичде. Мин җомгадан соң хамамга (мунчага) бардым. Бунда йирдән кайнар су чыгып торганга, шул кайнар судан файдаланып, искедән мунча салганлар. Суның эсселеге 55 дәрәҗәдә. Соңгы елларда бәләдия (муниципалитет) бик күп акча түгеп, бик һәйбәт бер мунча эшләткән. Гомум өчен сауна бар. Аерым party отлары (дөресе: одалары — бүлмәләре) да бар. Мин Искешәһәргә килгәндә шул мунчага керергә яратам. Бу юлы да кердем. Ләкин салкын суы

[2] 7,38 лира

туктаганга, ваннасы бик кайнар иде. Алай да суга кереп карадым. Таяна алмадым, чыкдым. Ваннаның янында кайнар суларга пешә-пешә юындым. Бүлмәдә эсседән тәрәзәнең ачылуы өчен тәртибат (механизм) алынган булса да, ул бозылганга тәрәзә ачылмады. Һавасызлыкдан буыла башладым, башыма капды. Ишекне ачып куйдым. Суның суынуын көтдем. Ахырдан суык су да килде. Душы эшләми иде. Шулай итеп, һәйбәт мунча акрын гына ватыла, җимерелә. Монда гадәт шул.

22 май

……………………………………………

Бүген җумартәси (шимбә). Авылга китәргә хәзерләнәмез. Өй хуҗасы Әдһәм әфәнде иртә берлә сәгать 7.30ларда уятып: «Әзер булыңыз, автобус булса, сәгать тугызларда китәрмез», — диде. Торып, юынып, чәй эчдем. Хәбәр булмагач, Әдһәм әфәнденең кибетенә чыкдым. Анда: «Сәгать икесез китә алмамыз, ахрысы», — диде. Өйгә дөндем (кердем), йәмәк йидем (ашадым). Сәгать 1.30да автобуска китдек. Автобус кеше башына биш лира ала икән. Алтмыш чакрымлык бер юл өчен бу фәүкылгадә (гадәттән тыш) күп. Сәгать икедә утырышып, чыгып китдек. Сәгать бишдә Чифтелер дигән базарлы бер авылга килдек. Бу безнең автобусның соң ноктасы иде. Монда безне авылдан алырга килгәнләр иде. Монда мөһаҗирләрдән Хәмид исемендә бер тегүчедә бер бардак (стакан) чәй эчеп, авылга ике атлы арабада (арбада) китдек. Әдһәм әфәнденең кияве Фәттах Җауска сәгать 7дә килеп җитдек. Чәй эчеп, аш ашап, радио тыңлап, ятып йокладык. Ләкин һава суыкка, өй дә суык иде.

23 май

……………………………………………

Бүген иртәдән бирле авылның картлары, яшьләре килеп күрешделәр. Һәммәсе татарча сөйли. Авыллары шактый зур, сиксән йорт бар икән. Биналар балчык, кирпечдән салынганлар. Авылның утырган йире коры, сусыз булгангамы, бакча бик аз. Өйләрнең тәртибе төрек авылларыннан башка, һәр йортның капкасы бар. Мәмләкәт капкасы кебек. Тәрәзәләр урамга карый. Йортлары зур, эчләре пакь. Мал-туар шактый күп булырга охшый. Авылның рәсми исеме Госмания (1923 елда Төркия Җөмһүрияте игълан ителгәннән соң, авылны Османия дип йөртә башлыйлар — Ф.Ф.), халык авызындагы исеме «Коры йөк», «Коры өек» булу ихтималы бар. Авылның якынында сонгый (ясалма) рәвешдә өелгән бер тау бар. Бәлки шул тауга нисбәтән «Коры өек» исеме бирелгәндер. Бу авылга безнең халык 1310 елда (миляди ел исәбе белән 1892-1893 елларда — Ф.Ф.) солтан Габделхәмид дәверендә йирләшкәнләр. Төп халыклары Оренбург казачийларыдыр. Тәк түк (сирәк) бөгелмәлеләр, уфалылар да бар. Авылның ун мең дә дүрт йөз дөнүм (мәйдан үлчәве — 919,3 м2) ягъни, бер мең дә йөз дисәтинә чамасы йире бар, ләкин, агар сулары юкка, кое берлә генә яшиләр. Урманлары да юк. Бик һәйбәт мәсҗедләре бар. Үзләренең яллап тота торган имамлары да бар. Имамлары — Румыниядән килгән Кырым татарыдыр. Мәктәпләре дә яхшы гына. Аның бинасын да үзләре салдырганлар. Җитмеш кадәр бала укый икән. Бу тарафда беренче мәгариф тарафыннан тасдыйк ителгән (расланган) мәктәп, диделәр. Мөгаллимләре дәүләтдән мәгаш (эш хакы) ала торган румынияле Кырым егете. Әтрафына бераз бакча да ясый башлаганлар. Ләкин илдә бакчачылык берлә мәшгуль булмагангамы, бакчалары күз кунарлык түгел. Халык үз арасында татарча сөйләшә. Кыз алып, кыз бирүне үз арасында ясарга ярата. Авылда азып-тузып йөрүче юк, һәм дә мохтаҗ булыр дәрәҗәдә ярлысы да юк. Бик күп кеше, мәмләкәт хәлләрендән сөйләшеп, көнне үткәрдек. Радиода большевикларның Коминтернның мәркәзне бетерүләре хәбәре сөйләнелде. Бу, әлбәттә, Американың тасдыйкы (фикере) берлә эшләнә. Ләкин большевиклар бу эшне, әлбәттә, җандан эшләмиләр. Ни булса да, куәт галәмәте (билгесе) түгел.

24 май

Бүген иртә, чәйне эчеп, өйдә сөйләшеп утырдык. Төнлә бер ягъмур яуганга юллар бик сазлы иде. Уникеләргә таба кырга чыгып китдек. Авылның әтрафын, хайван ашарга дип, чәчми калдыралар икән. Һәр тарафдан бер ярым чакрым чамасы игенсез йир. Фәкать чирәмлеге шәп түгел. Иң күп үскән үлән — әрем. Андан соң әллә нинди хайван ашамый торган бер ут (чүп үләне). Ашлыклар быел яхшы булырга охшый. Көздән чәчелгән арпалар баш куышып яталар. Ашлыклар арасында төрле чәчәкле үләнләр дә шактый күп очрый. Исле баллы чәчәкләре дә шактый бар. Өйлә йәмәгенә (төшке ашка) авылның карты һәм дә бае хаҗи Нәгыйм бабай әфәнделәргә китдек. Алар аккумулятор берлә өйләренә электрик керткәнләр. Монда радиолар да аккумулятор берлә эшли. Авылда телефон мәркәзе бар. Ләкин бу хөкүмәт тарафыннан һава һөҗүмләренә каршы тәдбир (тиешле чара) төсендә эшләтелгән, халык истифадә итә (файдалана) алмый. Бүген мине үзләренең мунчаларына кертделәр. Мунчалары мәмләкәт ысулында эшләнелгән. Ташлы, себеркеле мунча. Һәйбәтләп чабынып юындым. Кич берлә тутырган тавык берлә сыйладылар. Радиодан яңа хәбәрләр юк. Иң зур мәсьәлә итеп, Коминтернның ябылуындан хәбәр итәләр. Бу, әлбәттә, большевикларның Американы алдар өчен бер уен гына. Ләкин алай да булса, үзенең көчсезлеген күрсәтә торган бер зур галәмәт. Алманлар һаман һөҗүмгә кичә алмыйлар.

25 май

....

Авылның бер картына мәҗлескә бардык. Шурпаны бер табакдан ашатдылар. Йәмәкләре (ризыклары) гүзәл (затлы). Монда һәркем дә кайнаган каймак ясый икән. Ул бик тәмле була. Кырга чыгып, сөйләшеп йөрдек. Авылның бер дәрде (газаплануы) дә — сусызлык. Икенче кайгысы — күрше рум иле (Византия) мөһаҗир авылының боларның тупракларына күз куюлары. Ул рум иллеләр, үзләренең дәүләт эшләре аркылы һәм дә ришвәт ысулы берлә, боларның авылларының йирләрен үзләренә борырга тырышып йөриләр икән. Авылда мәҗмугалар алып, безнең милли мәсьәләләремез берлә мәшгуль булган кешилә (кеше белән) очрамадык. Безне кунакка чакыралар.

26 май

....

Көн буе картрак кешеләрне күреп, кунак булып йөрдек. Утыз Имән авылыннан Хәсәншаһ дигән берсене күрдек. Гыйлем дәгъвасындагы кеше, шактый китаплары бар. Бунларның күпчелеге диндар, хәтта мөтәгассыйб (фанат) адәмләр, әмма милли мәсьәләләрдән хәбәрдар түгелләр. Шулай диндар булдыклары хәлдә балаларына дин дәресе укыта алмыйлар, куркалар. Меллалары да алай ук җәсарәтле (батыр йөрәкле) адәм түгел, аңарга хөрмәт дә зур түгел. Аны һичбер безнең мәҗлескә чакырмадылар. Иртәгә, насыйп булса, Искешәһәргә китәмез. Мин бу халыкның кайсы авыллардан чыгуын язып алдым. Бәлки бервакыт эшкә ярар. Сәлим дигән бер карт бакча ясаган. Инде шулай йөзем, мәйва (җиләк-җимеш) бакча үсдерү тасмим итә (планлаштырыла) башлаган икән. Ләкин әле бакчалары яшь, мәйва бирүләре яңа икән. Радиода һаман урыс-алман сугышы хакында бернәрсә юк.

27 май

....

28ендә иртә берлә сәгать 6да тордык. Чәй эчеп, сәгать 7.20дә, Фәттах әфәнденең атларына утырып, Чифтелер дигән авылга, автобуска дип китдек. Авылда телефон булса да, алдан телефон итеп сөйләшә алмаган идек. Шуңаргамы, без килгәндә автобус киткән булып чыкды. Без монда һәмшәһри (ватандаш) Хәмид әфәндене, һәм дә Госман дигән берсене, Әхмәд әфәнде дигәнне, һәм дә Фәйзулла исемле бер һәмшәһри егетләрне күрдек. Чәй эчдек, каһвә (кофе) эчдек. Сөйләшдек. Андан соң Хәмид әфәнденең өенә чәйгә китдек.

Анда чәй эчкәндә: «Автобус килде», — диделәр. Без богдай (бодай) капчыклары тутырган автобуска утырып китдек. Сәгать 3дә Искешәһәргә килеп җитдек. Ашап-эчеп ятдык. Авыл сәяхәте аз гына да мин теләгәнчә булып чыкмады. Халык берлә мөнәсәбәтне самимиләшдерә алмадык. Аларның картлары «Намаз укысаң, эш бетә», — дигән фикердәләр. Яшьләре дөнья көтүгә, пара (акча) туплауга төшкәнләр. Бала-чаганы алып барырга тәмамән (бөтенләй) теләгән һичбер гаялары (теләкләре) юк. Үзләре намаз укып, бала-чагаларын ни милли, ни дин тәрбиясенә биш паралык әһәмият бирмиләр. Үзләре юмартлыклары берлә шактый мактанырга яратсалар да, там (нәкъ) тәкә вакытында, кузу (бәрән) вакытында (сарыклар суярлык вакытта) һичберсе бер кузу кисеп сыйлый алмадылар. Йагдыр (майдыр), ондыр кебек нәрсәләр алырмын дип уйлаган идем, бик суык давранганга (салкын булганга) — сүз чыгармадым. Әдһәм әфәнденең кардәш кабиләсе генә аның хөрмәтенә безгә аз-маз хөрмәт итделәр. Фәттах Җаус һәркөн тәмле кайнаган каймак кызганмаенча ашатды. Юл йоргунлыгы (юлда арыганлык) басканга, иртүк ятып йокладык.

28 май

....

Бүген акшам Истанбулга китәргә хәзерләнәмез. Әдһәм әфәндегә бик зур зәхмәт итдек (мәшәкать тудырдык) вә бик зур хөрмәт күрдек. Кичә кич берлә харбинлы — Агишева Хәнифә ханым ире доктор Әмин берлә кичке ашка килделәр. Әмин бәк — бик һәйбәт бер доктор. Мөгаллим Салих дигән бер әфәнде дә күрешергә керде. Ул хәятдә мәзлум (кыерсытылган) булган һәм дә бик [бу урында сүз аңлашылмый] сөя торган кеше икән. Вазгыяте агыр булырга ошый. Бүген вак-төяк нәрсәләр алып, төнлә сәгать бердә Истанбулга китәргә торамыз. Сәяхәтем бик үк мәгънәле булып чыкмады. Ике көндән бирле турмадан (дөресе: дурмадан — бертуктаусыз) ягъмур да кәефкә фәна (начар) тәэсир итде. Орхан Хәсән Бәгъри бәкне зиярәт итдем. Бәрабәр (бергә) йәмәк йидек (ашадык). Гомум әхвалдән шикаятьче. Кадыйри бәкне дә күрдем. Ул әҗзаханә (даруханә) ачмакчы булып йөри. Ләкин акчасы кяфи (җитәрлек) түгел, ахрысы.

29 май

....

Истанбулга китәр өчен терәндә (поездда) билет таба алмадык. Шуңарга юлчылыгымыз иртәгә калды. Истанбулдан Кәбир килде. Пазар көн (якшәмбе) шәһәри гиздек (шәһәрне әйләндек). Низаметдин исемле бер һәмшәһри берлә утырышдык. Кич берлә сәгать 11дә Истанбулга юлландык. 31ендә иртә саусәламәт дөндек (кайттык).

31 май

....

Корыөек авылының халкының чыкдыгы авыллар (Корыөек авылы кешеләре чыккан авыллар):

Иске Зубачи [Казачий]. Оренбург вилаяте (губернасы). Татищев.
Яңа Зубачи. Барысы урыс.
Чисноков. Ярты урыс.
Тукмак. Барысы урыс, казачий.
Утыз Имәндән чыккан, Кызыл мәсҗеддән Шаһи мелла. Уфа вилаяте.
Иштирәк авылы. Бөгелмә өязе.
Өби авылы. Бөгелмә өязе.
Дүртөйле. Уфа вилаяте. Агыйдел буе.
Семипалат. Сабир хәзрәт балалары. Шакир.
Мөслим авылы. Шадрин өязе. Пермь вилаяте.
Оренбург шәһәре.
Ашыт авылы. Бәләбәй өязе.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре ***Фәния Фәйзуллина*** *әзерләде.*

Introduction and publish version was prepared by ***Faniya Fayzullina.***

АРЫСЛАН

Газинур Морат

THE LION

Gazinur Morat

Лев Гумилёв рухына

Хакның фатихасы кирәктер ул
Хакны әйтер өчен халыкка...
Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан,
Көн итсә дә үзе тарлыкта.

Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан,
Чорлар буйлап җилгән туратта.
Бөек, диеп, кушаматын хәтта
Каторжаннар кушкан ГУЛАГта.

Бөек шагыйрьләрнең бөек улы,
Гаҗиз калып ялган, мәкердән,
Тимер читлектә дә, яшеренеп,
Хак тарихны язган хәтердән.

Язган —
кыйтгалардан кыйтгаларга
Кубарылып илләр көчкәнен.
Һуннар хакын хаклап, берьялгызы
Әйләндергән тарих көпчәген.

Дала хакын, Алла хакын хаклап,
Аралаган безне яладан.

Әлмисакта төрк һәм тереклек
Бер тамырдан гүя яралган.

Бер тамырдан гүя яралганбыз,
Таралганбыз җиһан буйлата.
Мәрткә киткән Дала балбалларын
Хәтер үзе килеп уята.

Мәңге тынмас Сак-Сок иңрәүләре
Сеңеп калгандыр күк ташларга.
Мәшригендә һәр бирмеш көн, әнә,
Татар бугазыннан башлана.

Мәгърибендә һәр бирмеш көн, әнә,
Алып тауга кайтып сыгына.
Сак-Сок иңрәүләре әверелгән
Кыйтгаларның уртак җырына.

Бөек шагыйрьләрнең бөек улы,
Арыслан да үзе, алып та...
Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан,
Көн итсә дә кимлек-тарлыкта.

ВАХИТ ИМАМОВ:

«NEIN, NEIN, ICH BIN KEIN RUSSISCH, ICH TATAR!»

VAKHIT IMAMOV:
«NO, NO, I AM NOT RUSSIAN, I AM TATAR!»

Татар бугазыннан Әдрән диңгезенә кадәр җирләргә хуҗа булып яшәгән, XIV гасырда ук чуен койган, 1500 еллык тарихы булган татар милләтен ни өчен дөньяда белмиләр? Татарның кем икәнен Җир шарында таныту өчен бүген нишләргә кирәк? 20 ел элек Финляндиядә табылган Казан ханнары тарафыннан язылган 150ләп хатны кем һәм кайчан барып өйрәнеп кайтыр? Ни өчен Биләрдәге җамигъ мәчете янында чучка баласы койрык болгап, чинап йөри? Күпсанлы тарихи романнар авторы, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире, Г.Исхакый һәм Э.Касыймов исемендәге премияләре иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай бүләгенә биелгы намзәтләрнең берсе Вахит Имамов белән әңгәмәдә шул сорауларга җаваплар табарга тырыштык.

– Вахит әфәнде, безнең мирас...

— Мирас, дибез инде без! Уйлап карасаң, барысы да мирас. Кайсы гына якны алып карама — мирас. Әйтик, беркемгә дә сер түгел, христиан һәм ислам дөньялары арасындагы көрәш булган, бар һәм дәвам итәчәк. Без ни югалтабыз бу көрәштә? Чит илдә бүген татарның кем икәнен, нинди милләт икәнен белмиләр. Без монда үз казаныбызда кычкырып ятабыз, «Без — җир шарын селкеткән милләт», «Татар бугазыннан Әдрән диңгезенә кадәр җирләргә хуҗа булып яшәгәнбез», дибез. Шул рәвешле үзебезне юатабыз. Үзебезгә бөек милләт кебек без, тик Россия чиген атлап чыктыңмы, безне белмиләр.

Бу турыда инде язсам да, Берлинда булган бер вакыйганы сөйлисем килә. Россия илчелеге бинасы каршында фотога төшкәндә, 70 яшьләр тирәсендәге бер немец килеп, мине куа башлады, янәсе, тапкансың фотога төшәр урын. Юлдашларым Россиядән булуымны аңлата башлагач, төкереп китеп барды. Мин гарьлегемнән немец артыннан йөгердем: «Nein, nein, ich bin kein Russisch, ich Tatar!»* — дип кычкырдым. Туктады да аптырап тора: «Татар?!» — ди, аңлый алмый нинди милләт турында сүз барганын. Ә мин уйлап торам: бу бабай төшенсен өчен татарның кайсы шәхесен мисал итеп китерим икән, дим. Бөтен дөнья белә торган кешебез бармы соң безнең? Яки берәр бина, йә булмаса, берәр бренд, әйтик, «Фольксваген» кебек. Эзлим-эзлим, таба алмыйм, юк бездә! Кемне белә ул 70 яшьлек немец, Тукайны белми дә белми инде, Җәлилне белүе дә бик шикле, гәрчә Германиядә җәзаланып үтерелгән булса да. Аптырап беттем, аннары: «Чыңгызхан!» — дидем. Немец бабаң мине кочаклап алып, шап-шоп аркага кагып, үбә башлады, аңлаштык, ниһаять! Мин бу хәлләр турында: «Аллага шөкер, Берлинда бер туганым артты», — дип язып та чыктым.

– Ни өчен безне чит илдә белмиләр?

— Димәк, мөселман вә төрки дөньясы тарафыннан үзебезне пропагандалау, ирешкән уңышларыбызны дөньяга күрсәтү, алар турында шаулап хәбәр итү җитми. Мактанырга яратабыз инде, безнекеләр беренче булып XIV гасырда чуен койганнар, ә Европа чуеннан туплар ясауны XVI гасырда гына үзләштергән, дибез. Без, күрәмсең, шулай итеп, үз күңелебезне үзебез тынычландырабыз. Тик бит кухняда бер-береңә мактанышып утырып кына милләтне Җир шарында танытып булмый.

– Нишләргә?

— Менә хәзер Баку университеты зур медиа-үзәк төзеп куйды. Шуның өстенә энциклопедия чыгара башладылар. Төп максатлары — Көнбатыш пропагандасын, аларның күкрәк сугып мактануларына ничек тә булса каршы тору. Чөнки аларның да үзәкләренә үткән бу әйбер. Алар ун китап чыгара икән, димәк, син дә ун китап чыгар, алар үзләрен күккә чөя икән, син дә чөй, бүген башкача ярамый. Баку университеты галимнәре, аларны субъективлыкта гаепләмәсеннәр өчен, төрекләр белән килешү төзегәннәр (Мәрмәрә, Әнкара, Истанбул университетлары белән), шулай ук казахлар, үзбәкләр белән дә. Алар бу эшкә хәйран гына акча сарыф итәләр. Әгәр бөтен мөселман дөньясыннан җыелган конференция быел Бакуда үтсә, икенче елга ул Төркиядә узачак, аннары Астанада яки Фирганәдә үтәргә мөмкин. Шушы медиа-үзәккә минем «Запрятанная история татар» дигән китабым барып эләккән дә, алар миңа чыктылар, бу китапны пропагандалауга да алындылар.

Моның бер сере дә юк: Мәскәү безгә үз тарихыбызны күтәрергә юл куймый, татар халкы үз тарихын белмичә яши. Мин Баку галимнәренең хәлен дә бик

* «Юк, юк, мин урыс түгел, мин — татар!»

яхшы аңлыйм. Чөнки аларга да Мәскәү басымына каршы торырга кирәк, Көнбатышныкына да. Бер милләт тә, рус та, француз да, немец та «без генә бөек милләт!» — дип күкрәк сугарга тиеш түгел. Тарихи фактлардан чыгып эш йөртергә кирәк.

Әйтик, Батый хан Болгарны инде җимергәч, без инде дәүләтсез калган бер вакытта, болар рус кенәзлекләрен яуларга киткәннәр. Рус галимнәре бу турыда ничек яза? Владимир каласындагы алтын капкалы София соборын, Рязань, Суздаль һ.б. калалардагы безнең монастырьларны кыргый Батый хан җимереп бетергән, диләр. Ә үзләре бүген шуларны бөтен дөньяга күрсәтеп мактаналар! Бөтен кеше күреп тора: Владимирдагы София соборы да, Киевтагысы да утыралар бит гөрләп, исән бит алар! 1000 ел буена утыралар ул соборлар, Батый да җимермәгән аларны, татар да, монгол да. Ләкин аларга үзләренең артта калганлыгын аклар өчен безне пычратырга, гайбәт таратырга кирәк. Нәкъ шушы вакытта 1237 елда Берлинның беренче ташын салганнар. Сез күз алдына китерәсезме, ул чакта Берлин әле җир шарында булмаган да хәтта!

Әйе, немецлар тырыш милләт, кулларыннан эш килә. Бүген алар чыгарган «Фольксваген», БМВ, «Мерседес» һәм «Ауди»лар белән бөтен дөнья тулган. Ләкин бит мин күргән һәрбер немец алдында моның өчен тезләнергә тиеш түгел, чөнки мин үзем дә 1500 еллык тарихы булган бөек татар халкы вәкилемен. Шул ук вакытта немец үзен пропагандалый белә, бөтен дөньяны үз кулында биетә, ә без, татарлар, берни дә эшли алмыйбыз. 1500 еллык тарихыбыз бар, дип үзебезгә китап бастырып ятып кына...

— Анысы да кирәк эш!

— Һичшиксез! Чөнки надан татарларның күзен ачасы бар. Үз тарихларын белмәгән татарлар бездә 70-80 процент тәшкил итә. Монысы бер юнәлеш. Икенчесе — чит илләр өчен китап бастырып тарату, бөек милләт икәнебезне исбатлау. Безнең дәлилләребез күп: заманында Алтын Урданы да тотканбыз, Алтайда 30 мең билгедән торган кабер ташларыбыз да бар, саный китсәң, бик күп. Тик тәрҗемә итеп, Европага таратмагач, алар бу турыда белмәгәч, безне кем белсен дә, кем хөрмәт итсен. Менә шундый чакта безнең хөкүмәт теләсә нинди максатларда акча түгәргә мөмкин, ләкин татар милләтенең зурлыгын чит илгә чыгарып таныту өчен генә түгел.

Татар җитештергән байлыкның 80 процентын Мәскәү талап ята, ләкин бит фәннәр академиясе, тарих институты, бөтен җәмәгатьчелек исеменнән таләп итсәң, дәгъваләшсәң, кайвакыт Мәскәү авызыннан да калҗа тартып алып була. Аның өчен безгә бердәм булу кирәк. Кырымдагы референдум алдыннан андагы татарларга ниләр генә вәгъдә итмәделәр? Җир мәсьәләсен хәл итүне дә, тел мәсьәләсен дә, һәр министрлыкта бер урынбасар урыны Кырым татарларына биреләчәк, диделәр. Янәсе Украина хакимияте Кырым татарларының мәсьәләләренә салкын караган. Ә Казан татарларының мәсьәләләрен кем хәл итәр микән соң? Ә чувашныкын, удмуртныкын, мариныкын, башка халыкларныкын? Көнбатышны ике төрле стандартлар куллануда гаеплиләр, ә мин Мәскәү авызына кычкырам: «Нигә Кырым референдумын таныдың, ә Татарстан үткәргән референдумны танымадың?» Мәскәүдә ике төрле стандарт түгелмени? Әйе шул, кол милләтнең, дәүләтен югалткан милләтнең язмышы бик аяныч. Рәсми тарих битләрен җиңүчеләр яза.

Шуңа күрә минем бүген татар галимнәренә мөрәҗәгать итәсем килә. Әйткәнемчә, Бакуда медиа-үзәк төзеп куйдылар, алар төрки халыкларның галимнәре белән берлектә эшләргә әзер, 100дән артык китап чыгарырга җитешкәннәр инде. Без дә шушы эшкә кушылыйк. Һәр китапны, 7-8 телгә тәрҗемә итеп, бөтен дөньяга тарату

өчен бик күп акча кирәк. Аларда үз милләтләре өчен янган-көйгән спонсорлары да бар, тагын дәүләт тә акча бирә. Чөнки алар, әйткәнемчә, төрки дөньяны өскә чыгару, аны таныту өчен көрәшәләр.

– Мирас турында сөйләшкәндә 1552 елны читләтеп узып булмас...

— (Авыр сулап) Без еш кына 1552 елда Кырым ханлыгы да, төрек солтаны Сөләйман Кануни да ярдәмгә килмәгән, дип зарланырга яратабыз. Тик бернәрсә турында онытабыз: ул вакытта Сөләйман Кануни Җир шарында мөселман дөньясын саклап калучы бердәнбер хаким, таҗ иясе булган. 1492 елда Колумб Американы ачкач, португаллар, испаннар, башка Европа халыклары яңа җирләрне талый башлаганнар, бу аларның чәчәк аткан чоры булган. Болар Урта диңгезне үз кулларына эләктергәннәр, бүгенге Мисыр, Алжир, Тунис, Марокко дәүләтләре урнашкан җирләрне яулап алганнар, Кызыл диңгез — аларныкы, бүгенге Һиндстанның яр буе — аларныкы. 20 миллион мөселман халкы коллыкта калган. Аларны бит Сөләйман Кануни коткарган, берүзе!

Бөтен Европага хуҗа булып алган Карл V белән сугышып яткан Кануни ул вакытта. Венага яу белән килгәч, Кануни Карлга чапкын җибәрә, аланга чыгып, йөзгә йөз килеп бергә-бер сугышырга чык, ди. Бөтен Җир шарына «Карл Великий» дип танылган патша шулвакытта төрек солтанына каршы чыгарга курыккан. Безнең балалар мәктәптә укый торган тарих дәреслекләре Карл Великий белән тулган, ә Сөләйман Кануни турында сыңар хәреф тә юк. Ә бит бу мөселман дөньясын, ислам динен саклап калган солтан! Чөнки дәреслекне Мәскәү төзи, татар төземи. Бу әйберләрне татар галимнәренең, фән докторларының ничәсе генә белә икән? Белмәсәгез, Татарстанда 2200 фән докторы һәм кандидаты бар. Катыргылы! Ботыннан тотып селкесәң, «а» да, «б» да төшми торганы 2000 генә җыеладыр, дип уйлыйм мин.

– Архивларда ята торган, моңа кадәр казып чыгарылмаган мәгълүматлар күпме?

— Чиксез! Бер генә мисал. 20 еллар элек Финляндия галимнәре, үз архивларында казынып, Казан ханлыгыннан җибәрелгән 150ләп хат тапкан иде. XV гасыр урталарыннан башлап, Казан ханлыгы җимерелгәнчегә кадәр 100 ел чамасы хатлар алышып яткан булганнар. Алар безнең хөкүмәткә: «Галимнәр җибәрегез, монда килеп хатларны өйрәнсеннәр», — дип мөрәҗәгать итте. Җибәрмәгәннәр, акча таба алмаганнар! Һәм бүгенге көнгә кадәр бу хатларны кулына тотып караган бер татар да юк.

Тагын бер мисал. Сарапулда завод төзелеше башлангач, мөселман зираты килеп чыккан. Удмурт галимнәре килеп тикшергәннәр, Казанга телеграмма җибәргәннәр, 3000гә якын кабер таптык, килегез, дигәннәр. Бер генә галим дә бармаган шунда! Ул урында күптән завод төзеп куйдылар инде. Мин элеккеге хәлләр турында гына сөйләмим, бүген дә шулай ук дәвам итә. Биләрдә җамигъ мәчете урынын таптылар, бер метр чамасы казылган, 64 колоннаның нигезе һаман да ачык һавада утыра. Шушы урыннан 250 метр ераклыкта —дуңгыз фермасы. Болгар дәүләтеннән калган мәчет янында чучка баласы койрык болгап, чинап йөрергә тиеш түгел. Моны аңлатып торырга кирәкме соң? Моны аңламас өчен, гомумән, кешедә нинди баш булырга тиеш?! Кайсы якка барып төртелсәң дә, шул! Без үзебезнең үткәнгә шулай «игътибарлы» булгач, моның өчен кемне гаепләргә кирәк соң? Без үз тарихыбызга, үз мирасыбызга шулай карыйбыз икән, безне кем сөйсен дә, кем хөрмәт итсен? Әллә Берлиннан галимнәр чакырыйк микән үз-үзебезне хөрмәтләргә өйрәнер өчен?..

Равил Сабыр *әңгәмәсе*
Interview of ***Ravil Sabyr***

ТӨРКИ-ТАТАР ТАРИХИ ТЕРМИННАРЫНЫҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕН ТӨЗҮГӘ КАРАТА

Ильяс Мөстәкыймов,
тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе архив документларын файдалану һәм халыкара элемтәләр секторының мөдире

AS FOR THE COMPILE OF THE MONOLINGUAL DICTIONARY OF TURKIC-TATAR HISTORIC TERMS
Ilyas Mustakimov

Татар халкының тарихын һәм телен гыйльми өйрәнү нәтиҗәсендә, соңгы ике гасырда фәнни әйләнешкә элекке Үчы һәм, өлешчә, Чыгтай олыслары җирләрендә язылган күпсанлы документаль, нарратив (хикәяләүче), эпиграфик (ташъязма) чыганаклар кертелде.

Ул чыганакларда бүгенге көндә гамәлдән чыккан сәяси, иҗтимагый, хәрби, көнкүреш һ.б. терминнар, тарихи-географик атамалар, кеше исемнәре бик күп. Соңгы ике-өч дистә елда яңа яки электән мәгълүм, әмма төрле сәбәпләр аркасында өйрәнелми яткан, төрки-татар язма чыганакларын тикшерүгә һәм фәнни әйләнешкә кертүгә, төрки-татар тарихи-географик, антропонимик, терминологик аңлатмалы сүзлекләренә, гомумән, зур ихтыяҗ барлыгын күрсәтте. Андый сүзлекләрне төзү, безнеңчә, бүгенге көндә татар тарихчыларының һәм телчеләренең мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

Татар тарихи лексикологиясенең һәм лексикографиясенең тәүге тәҗрибәсе итеп, мөгаен, 1822 елда Ибраһим Хәлфин тарафыннан нәшер ителгән XVII йөз татар ядкяре «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәренә төзелгән сүзлекчәсе исәпләнергә тиеш[1]. Бу басманың максатларыннан берсе итеп И. Хәлфин Казан университетының Шәрык телләрен өйрәнүчеләр өчен гамәлдән төшкән [төрки-татар] сүзләренә аңлатма бирүне күрсәтә[2]. XIX йөз татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрдә тарихи терминнар очраштыргаласа да[3], сүзлекләрне төзүчеләр үзләренә аларны махсус өйрәнү һәм аларга тәфсилле аңлатма бирү максатын куймаганнар. Бу хәл XX йөз башында төзелгән ике телле татарча сүзлекләргә дә хас. Төрки телләргә кергән кайбер тарихи терминнар XX йөз башында күренекле татар җәмәгать эшлеклесе һәм мәгърифәтчесе Ризаэддин Фәхреддин мөхәррирлегендә чыккан «Шура» журналы сәхифәләрендә

[1] Чыңгыз хан вә Аксак Тимер китабының лөгатьләре // Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер = Жизнь Джингиз-хана и Аксак-Тимура / Сост. И. Хальфин. – Казань, 1822. – С.1-67 (кушымта).
[2] Хальфин И. Предисловие // Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер = Жизнь Джингиз-хана и Аксак-Тимура / Сост. И. Хальфин. – Казань, 1822. – С.2.
[3] Юсупова А.Ш Двуязычные словари татарского языка XIX века как лексикографические памятники // Вестник Челябинского государственного университета. – 2007. – №22 (100). – С.171; Юсупова А.Ш Лексика двуязычных словарей татарского языка XIX в. // Учёные записки Таврического национального университета им. В.И.Вернадского. – Серия «Филология. Социальные коммуникации». – Т.23 (62). – 2010. – №3. – С.4.

тикшерелгән[4]. Совет заманында, 1920 елларда, татар тарихын һәм телне өйрәнү фәннәре беркадәр үсеш кичерсә дә, 1920 еллар ахырында СССР хөкүмәте тарафыннан тормышка ашырыла башланган «культура революциясе», һәм шуның белән бәйле ике тапкыр имла алыштыру (гарәп язуыннан латинга, латиннан кириллицага күчү), «феодализм калдыклары», «буржуаз милләтчелек», гомумән, яңа хөкүмәткә ошамаган милли традицияләр белән «аяусыз көрәш», шуларга өстәлгән репрессияләр, Икенче Бөтендөнья сугышы һәм сугыштан соңгы елларда татар халкы тарихын объектив өйрәнүгә куелган киртәләр һәм башка сәбәпләр татар тарихи лексикографиясенең татар тел белеменең мөстәкыйль тармагы булып оешырга мөмкинлек бирми.

1950 еллардан башлап бүгенге көннәргәчә тарихи лексикологиягә багышланган аерым мәкаләләр һәм хезмәтләр басылса да, урта гасыр һәм яңа чор төрки-татар язма чыганакларына нигезләнгән татар тарихи терминнары аңлатмалы сүзлеге төзү максаты озак вакыт көн тәртибендә тормый. 1970—1980 еллар башында дөнья күргән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә[5] һәм XX йөзнең уртасыннан чыгып килгән татар теленең диалектологик сүзлекләрендә[6] борынгы һәм яңа дәвер язма төрки-татар чыганакларында кулланылган тарихи лексика да берникадәр чагылыш тапкан. Шуңа күрә бу хезмәтләрнең әзерләнүе һәм басылып чыгуы, һичшиксез, татар тарихи лексикологиясе һәм лексикографиясе җәһәтеннән алга китеш, дип бәяләнергә тиеш. Басмаларның әһәмиятле якларыннан берсе — аңлатма бирелгән сүзләргә куллану мисаллары китерелү. Ләкин ул сүзлекләрне төзүчеләрнең максатлары хәзерге заман татар әдәби теленең һәм диалектларының лексикасын барлау һәм аңлату булганга, урта гасыр һәм яңа дәвер язма чыганаклары аз җәлеп ителгән. Шуңа күрә шактый тарихи терминнар ул сүзлекләргә керми, кергәннәренең дә бөтен мәгънә төсмерләре ачыкланмый калды. Әйтергә кирәк, кайбер тарихи терминнар һәм гыйбарәләр Нәкый Исәнбәт төзегән сүзлекләрдә аңлатыла[7].

Г.М.Мостафина һәм Р.Г.Галләм тарафыннан төзелгән тарих терминнары сүзлекләрендә рус һәм совет историографиясендә кулланылган халкыбыз тарихы белән бәйле тарихи терминнар татар теленә тәрҗемә ителә һәм аңлатыла[8]. Р.Г.Галләм хезмәтендә шулай ук географик атамаларның, династияләрнең һәм тарихи шәхесләр исемнәренең татарча язылышы, тарихи шәхесләр һәм династияләр турында кыскача мәгълүмат һ.б. китерелә.

Телче галим Рәфкать Әхмәтҗановның «Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге»ндә дә тарихи терминнарга һәм кайбер географик атамаларга аңлатмалар шактый китерелә[9].

Р.Т.Сәфәровның татар хәрби лекси-

---

[4] [«Калгай» сүзенең тарихы хакында сорау һәм «Шура» җавабы] // Шура. — 1910. - №4. — 121-122 б.; Акъюлов Ә. [«Бием» сүзе хакында] // Шура. — 1912. - №18. — 3 т.б.; Сабирҗан М. [«Күкәлташ» атамасы хакында] // Шура. — 1913. - № 23. — 2 т.б. һәм башкалар.
[5] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. — Казан, 1977-1981.
[6] Диалектологик сүзлек: Вып.1-3. — Казан, 1948-1958; Татар теленең диалектологик сүзлеге. — Казан, 1969; Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. — Казань, 1992; Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. — Казан, 2009.
[7] Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: 3 томда. — Казан, 1959-1967; Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. — Казан, 1989-1990.
[8] Мустафина Г.М. Краткий русско-татарский словарь исторических терминов. — Казань, 1993; Галләмов Р.Ф. Русча-татарча тарих терминнарның аңлатмалы сүзлеге. — Казан, 2006.
[9] Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. — Казан, 2001.

касына багышланган диссертациясендә бүгенге татар хәрби терминнарның тарихи тамырларын яктыртуга шактый урын бирелә[10].

Бу мәкалә төрки-татар тарихи терминнарының аңлатмалы сүзлеген төзү мәсъәләсенә багышланган.

Урта гасыр һәм яңа дәвер төрки-татар тарихи терминнарын барлаганда, безнеңчә, Алтын Урда язма һәм фольклор традициясенә нисбәтле чыганаклардан файдаланырга кирәк. Болар билгесез авторның «Тәварихы гөзидәи носрәтнамә»се (XVI йөз башы), Мөхәммәд-Салихның «Шәйбанинамә»се (XVI йөз башы), Үтәмеш хаҗиның «Чыңгызнамә»се (XVI йөз урталары), Кадыйр-Гали бикнең «Җамигыт-тәварих»ы (1602 ел), билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгызнамә»се (XVII йөз ахыры), Мөхәммәд-Ризаның «Әссәбгыс-сәйяр фи әхбары мөлүке татар»ы (XVIII йөз), Габделгаффар Кырыминың «Гомдәтел-әхбар»ы (XVIII йөз) һ.б. тарихнамәләр, безнең көннәргә килеп җиткән күпсанлы документаль, эпиграфик һәм әдәби ядкярләрдән гыйбарәт. Чыгарма рәвешендә, терминнарны барлаганда һәм мисаллар китерелгәндә кайбер чит традицияләргә ия төрки авторларның хезмәтләрен дә җәлеп итүне мәгъкуль күрәбез. Мәсәлән, Сахиб-Гәрәй ханның Кырым тәхетен биләгән чагында (1532-1551 еллар) аның шәхси табибы булып торган госманлы авторы Бәдреддин Мөхәммәд Кайсуни задә Нидаи әфәнде (Рәммал хуҗа) хан вафат булгач, 1553 елда, аның кызларының берсе соравы буенча, Сахиб-Гәрәйнең хөкемдарлык тарихын тасвирлаган «Тарихы Сахиб-Гәрәй хан» исемле әсәрен яза. Анда Рәммал хуҗа үз әсәрендә Кырымдагы татар шивәсенә хас шактый термин һәм гыйбарәләр куллана. Тимериләр династиясе вәкиле Заһиреддин Мөхәммәд Бабәрнең «Бабәрнамә»сендә дә чыгтай һәм төрки-татар телләре өчен уртак терминнар бар. Ничек кенә булмасын, өстенлек XIII — XX гасыр башы язма чыганакларына бирелүе мәгъкуль. Төзеләсе сүзлекнең лексик базасын объектив рәвештә гарәп язулы чыганаклар тәшкил итәчәк, шуңа күрә терминнар гарәп әлифбасы тәртибендә тезелергә һәм беренче итеп терминнарның гарәп хәрефләре белән язылышы китерелергә тиеш. Шулай ук чыганаклардан алынган теге яки бу терминның кулланылышын яктыртучы цитаталар китерелүе гаять мөһим. Терминнарга аңлатма һәм татар, һәм рус телләрендә булырга тиеш, дип уйлыйбыз.

Төрки-татар тарихи терминнарының сүзлеген төзегәндә мондый төр сүзлекләре булган халыкларның (иранлылар, төрекләр, руслар һ.б.ның) тәҗрибәсен өйрәнү зарур. Мәсәлән, 1920 елларда Төркия кичергән радикаль иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үзгәрешләр нәтиҗәсендә (европалаштыру, гарәп язуыннан латин имласына күчү) төрек тарих фәне татар фәненекенә охшаш халәткә тар була: төрек галимнәренең яңа буыннары госманлы дәверенә караган чыганакларны өйрәнүдә кыенлыклар белән очраша. Бу мәсьәләне хәл итәр өчен, госманлы-төрек сүзлекләреннән башка, госманлы тарихи терминнары сүзлекләре хәзерләнеп чыгарыла[11].

Безнең тарафтан үткәрелгән эзләнүләрнең нәтиҗәләрен апробацияләү максатыннан чыгып, берничә тарихи терминга багышланган очерклар тәкъдим итәбез.

[10] Сафаров Р.Т. Военная лексика в татарском языке. Автореф. дисс. … кад. фил. наук. — Казань, 2012.

[11] Pakalın, M.Z. Osmanlı Tarih Deyimleri ve Terimleri Sözlüğü. – C. I-III. – Ist., 1983; Sertoğlu, M. Osmanlı Tarih Lûgati. – Ist., 1986; Kepecioğlu, K. Tarih Lûgati: Osmanlı Tarih Deyimleri ve Terimleri Temel Sözlüğü. – Ankara, 2000.

ТӨРКИ-ТАТАР ТАРИХИ ТЕРМИННАРЫ

TURKIC-TATAR HISTORIC TERMS



ЙАСАК (يساق , يصاق)

Урта гасыр төрки-татар чыганакларында бу сүзнең ике төп мәгънәсе бар:

1. Кагыйдәләр, кануннар җыелмасы.

Бу мәгънәдә «йасак»сүзе кайбер очракларда «йосын» яки «түрә» («горефгадәт») сүзләре белән бергә килә: «Аталарының түрә-тукабын, йасак-йосынын йахшы саклап бәрҗай кылдылар» («Бабаларының гореф-гадәтләрен яхшы саклап үтәделәр»)[1].

Урта гасыр тарихчылары һәм сәяхәтчеләре, кануннар җыелмасы буларак, ясакның барлыкка килүен еш очракта Чыңгыз хан исеме белән бәйлиләр. Фарсы телле чыганакларда «Чыңгыз хан кагыйдәләре һәм кануннары җыелмасы» мәгънәсендә «Йасайы Чыңызый» («Чыңгыз хан ясасы») термины да очрый. Ясакны / ясаны бозучылар авыр җәзаларга тартылганнар. Бу мәгънәдән «йасакка тигмәк»(җәзага лаек булу; җәзалану) һәм «йасакка тигермәк» (җәза бирү, [җәза биреп] үтерү) дигән мәгънәләр барлыкка килгән: «Ул җиһәтдин үз гөнаһымга икърар булып килеп торырмын, йасакга тиг[г]әймен, һәр нә кылса хаким торыр» («Шуңа күрә үз гаебемне танып килдем, җәзага тартылырга лаекмын, [минем белән] ни кылса да, хакы бар»)[2]; «Һөләгү хан аны йасакга тигерде» («Һөләгү хан аны [җәза биреп] үтерде»)[3]; «Тимүр бик… чәрикләрен йыгып, Шәйех-Мөхәммәди дигән бикне базгырып, йасакга тигереп…» («Тимер бик… гаскәрләрен җыеп, Шәехмөхәммәди дигән бәкне бастырып һәм [аңа] җәза биреп…»)[4].

«Җәзалану / җәза бирү» мәгънәсе белән бергә «йасак» сүзенең «тыю» мәгънәсе дә барлыкка килгән. «Йасак» сүзенең бу мәгънәсе аеруча госманлы төрек телендә киң таралыш табып, Кырым ханлыгы документларының теленә аннан күчкән булса кирәк. Кагалгай[5] Ислам-Гәрәй солтаннан Польша короле Владиславка һиҗри 1050 ел җөмадиеләүвәл аеның беренче ун көнендә (милади 1640 елның августында) язылган хатында: «Без дахы фәрмане шәрифемез берлә мөстәхдәм вә мәэмүр улан бәкләремезгә вә мирзаларымыз вә бишбаш агаларымызгә мөхкәм тәнбиһ вә йасак итмешездер, Сезең күйләреңезгә вә шәһәрләреңезгә вармазлар» («Без дә безгә хезмәт итүче бәкләребезгә, мирзаларыбызга һәм бишбаш агаларыбыз-

[1] Таварих-и гузида – Нусрат-наме. – Б.144, юл 2131.
[2] Шунда ук. – Б.196, юл 3065-3066.
[3] Шунда ук. – Б.180, юл 2806.
[4] Шунда ук. – Б.94, юл 1346-1347.
[5] Кагалгай (кагалга, калгай, калга) – Кырым ханлыгында Гәрәйләр нәселеннән булган, ханның беренче варисы саналган ханзадә (солтан, принц).

га[6] фәрмане шәрифебез белән Сезнең авылларыгыз һәм шәһәрләрегез өстенә йөрергә катгый рәвештә тыйдык»)[7].

2. Салым төре яки гомумән «салым».

XVI йөз башында Мөхәммәд-Шәйбани хан кушуы буенча төзелгән «Тавәрихы гөзидәи носрәтнамә» исемле тарихнамәдә Мөхәммәд-Шәйбани ханның бабасы турында болай дип әйтелгән: «Әбел-Хәйер хан… [кештем-]түәләс, Чимги [-тура], башгырт, бүләр вә болгар илләрене бактырып йайлап, ул илләрнең гаделлек берлә йасакын алып, такы кышлай Төркестанга килеп, гаделлек берлә унда бер малын алды» («Әбел-Хәйер хан… [кештем-]түәләс, Чимги [-тура], башкорт, бүләр һәм болгар халыкларын буйсындырып, [аларның җирләрендә] җәйләп, ул халыклардан гаделлек белән ясак җыеп, кышларга Төркестанга килеп, [андагы халыкның] малыннан гаделлек белән уннан бер өлешен алды»)[8].

«Салым» мәгънәсендә яки салымның бер төрен белдереп «йасак» сүзе Алтын Урда һәм татар ханлыклары хөкемдарларының ярлыкларында (фәрманнарында) киң кулланыла: «Бурла тамгасы, Инкенче Өскебул корыты, анбар малы, ындыр хакы, табанлык кыйсмәт, куп[ч]ыр йасагы, калан мөсәмма салыг (калан дигән салым), бурыч-хәреҗ алмасынлар»[9]; «Мин бәгыд бу мөшарен иләйһимларга… йасак-калан, салыг мөсәмма салмасынлар» («Моннан соң бу югарыда әйтелгәннәргә… ясак [һәм] калан [салымнарын], салыг дигән [салымны] салмасыннар»)[10]; «Баса (моннан соң) бу тарханла[р]ымыздан йасак-калан тип (дип) теләмәсен-алмасынлар»[11]. Төрки-татар дәүләтләрендә булган ясак түләүчеләр (ясаклылар) катлавы рус дәверендә дә XVIII гасырга кадәр булган.

ЧУРА (چوره , چورا)

Венгр профессоры И.Вашари ачыклаганча, бу термин фарсы телендәге چهره *чуһра* ‘хезмәтче яшь егет; сакалы үсә башламаган егет’ сүзеннән үзгәргән. Моңа мисал итеп И.Вашари Заһиреддин Мөхәммәд Бабәрнең «Бабәрнамә»сеннән түбәндәге өзекне китерә: «Чуһра калын сахлар иде. Хөкем руйидә чырайлык әмрәд углан булса, һәрнәвегъ билә килтереп чуһра кылыр иде» («Күп чуралар тота иде. Мәмләкәтендә матур чырайлы чибәр егет булса, ничек тә булса үз янына китереп чура итәр иде»)[12]. Алман галиме Г.Дёрфер *чура* термины асылда төрки сүз, дигән фикерне белдерсә дә[13], И.Вашариның фаразы нигезлерәк күренә.

Күп очракта бу термин хөкемдарның яки эрерәк аксөякнең хезмәткәрен, якын хезмәтчесен белдергән. Ул мәгънәсендә *чура* сүзе Тимер бик (Аксак Тимер) нәселеннән хөкемдар булган солтан Әбү Сәгыйдь мирзаның 1468 елда Ак Куенлы дәүләте хөкемдары Хәсән биккә (Озын Хәсәнгә) язган бер хатында, Себер яки Казан ханы Ибраһим ханның XV йөзнең икенче яртысында бирелгән бер ярлыгында һәм 1602 елда Касыйм ханлыгында Кадыйргали бик тарафыннан язылып, фәндә «Җамигыт-тәварих» исеме белән мәгълүм тарихнамәсендә кулланыла: «Гали бик дигән чурамны бетикләр бетеп (хатлар язып) Җиһаншаһга чаптырдым»[14]; «Бу азад (азат) йибәргән кем ирсәләрнең аты

---

6 Бишбаш агасы – Кырым ханлыгында: йолымлык әсирләрне алыр өчен күрше өлкәләргә оештырылган кечкенә сәфәрдә отрядның башлыгы.

7 Материалы для истории Крымского ханства. Изд. В.В.Вельяминов-Зернов. – СПб., 1864. – № 55. – С.262.

8 Таварих-и гузида – Нусрат-наме. – Б.266, юл 4166-4168.

9 Grigor'ev, A.P. Grants of Privileges in the Edicts of Toqtamïš and Timur-Qutluġ // Between the Danube and the Caucasus. – Budapest, 1987. – P.94.

10 Сахиб-Гәрәй хан ярлыгы // Татарстан Республикасы Милли музее, сирәк фонд, № 5757.

11 Березин И.Н. Тарханные ярлыки Тохтамыша, Тимур-Кутлука и Саадет-Гирея. – Казань, 1851. – С.19.

12 Muhamedyarov Sh., Vasary I. Two Kazan Tatar Edicts (Ibrahim's and Sahib Girey's Yarliks) // Between the Danube and the Caucasus. – Budapest, 1987. – P.185-186.

13 Doerfer, G. Türkische und Mongolische Elemente im Neupersischen. – Bd.3. – Wiesbaden, 1967. – S.117-118.

(кемсәләрнең исеме) Гөлбостан хатын башлыг углы [Мөхәммәдгали,] Мөхәммәдгазиз, [кызлары] Ханнәсәб, Шаһнәсәб, Җаникә солтан — бу атлы кем ирсәләр азад йибәрелде, такы Хушкилде атлыг чурасын бергә булсын тидек»[15] («Бу азат җибәргән кемсәләрнең исемнәре Гөлбостан хатын башлап улы [Мөхәммәдгали,] Мөхәммәдгазиз, [кызлары] Ханнәсәб, Шаһнәсәб, Җаникә солтан — бу исемле кемсәләр азат җибәрелде, тагы Хушкилде исемле чурасын бергә булсын дидек»); «Бу Туктамыш хан Идел мәүзыйгта үтте... Котлыкыя углы Идегә Көчек аның чурасы ирде»[16] («Бу Туктамыш хан Идел буенда үтте... Котлыкыя улы Идегә Көчек[17] аның чурасы иде»).

Телгә алынган мәгънәгә бәйле рәвештә *чура* сүзенең '[дастандагы] батырның иптәше' мәгънәсе барлыкка килгән. Сүзнең мондый мәгънәсе, мәсәлән, кыргыз телендә теркәлгән[18] . Бу җәһәтеннән *чура* сүзе монгол асыллы *нүкәр* (татар дастаннарында һәм кайбер татар диалектларында *нүгәр* дип әйтелә) термины белән якынлаша. Ихтимал, 'батырның иптәше' мәгънәсендә *чура* сүзе Чура, Акчура, Карачура, Тиңчура, Җанчура кебек төрки-татар исемнәренә дә кергәндер.

Кайбер чыганакларда *чура* сүзе 'ирекле булмаган кеше; әсирлеккә төшеп кол ителгән кеше; кол (русча эквиваленты: холоп)' мәгънәсендә кулланыла. Мондый мәгънәдә бу сүз, мәсәлән, Касыйм ханлыгында яшәгән Акай мирза углы Галикәй аталыкның 1639 елгы васыятьнамәсендә очрый: «Энемез Дустмөхәммәд мирза... Янбулат углы Котынай хатынынннан сатып алган Иринә углы Корманай атлыг (исемле) нимеч чурам агар (аңа) мирас иттем»[19].

БИСТӘ ЧУХУРЛАРЫ
(بسته چوخورلرى)

Бу терминны татар дин эшлеклесе һәм тарихчысы Морад Рәмзинең бер хезмәтендә генә очратканыбыз бар. Аның мәгънәсен һәм барлыкка килү тарихын галим түбәндәгечә аңлата: «Бездән алда Мәрҗани хәзрәтләре инде язганча, Казан руслар тарафыннан алынгач, казанлылардан һичберсе исән калмый. Коллары исә Казанга кайтып, хуҗаларының йортларына һәм утарларына кереп утырып, үзләрен шушы биләмәләрнең хакыйкый ияләре дип белдерәләр. Һәм руслар аларның ялган дәгъваларын таный. Бүгенге көндә «без асыл Казан кешеләреннән» дип горурланган әфәнделәр шул түбән җан, хәсис колларның нәселләре. Мин әйтәм: бу да хакыйкатькә туры килсә кирәк. Ул кешеләрне хәзерге вакытта «бистә чухурлары» дип атыйлар»[20].

Чухур сүзенең этимологиясен әлегә ачыклап булмады.

ЙАСАЛ (یسال)

Хәрби саф; отряд: «Манкыт чәриге атланып орышга йасал кылганда»[21] («Маңгыт гаскәре[22] [атларга] атла-

---

[14] Kurat, A.N. Topkapı Sarayı Müzesi Arşivindeki Altın Ordu, Kırım ve Türkistan hanlarına ait yarlık ve bitikler. Istanbul, 1940. – S.198.

[15] Мустакимов И.А. Некоторые замечания к чтению и интерпретации ярлыка хана Ибрагима // Актуальные проблемы истории и культуры татарского народа: Материалы к учебным курсам: в честь юбилея академика АН РТ М.А.Усманова. – Казань, 2010. – С.161.

[16] Госманов М. Тагын Ибраһим хан ярлыгы турында // Казан утлары. – 1967. – №6. – Б.151; Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 40т сакл. бер., 61а кгз.

[17] Алтын Урданың мәшһүр бәкләрбәге Идегәй күздә тотыла.

[18] Юдахин К.К. Киргизско-русский словарь. – Кн.2. – Фрунзе, 1985. – С.369 («чоро» мәкаләсе).

[19] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. – Ч.3. – СПб., 1866. – С.234.

[20] Рәмзи М.М. Тәлфыйкыль-әхбар вә тәлкыйхел-асар фи вәкаигы Казан вә Болгар вә мөлүкит-татар. – Әлмөҗәлләдес-сани. – Оренбург, 1908. – С.153.

[21] Библиотека восточных историков, издаваемых И. Березиным. – Т. I: Шейбаниада. История монголо-тюрков на джагатайском диалекте. – Казань, 1849. – Б.64.

[22] Ягъни, маңгыт кабиләсе вәкилләреннән торган гаскәр.

нып сугышка [әзерләнеп] хәрби саф тезегәндә»); «Барангар, җуангар, гул йасал йасап»[23] («Уң кул, сул кул, үзәк [гаскәрләре] хәрби саф тезеп»); «Җанвафа уң йасалыны төзде, йасалын дошманыга күргезде»[24] («Җанвафа [би] уң [кул гаскәренең] хәрби сафын төзеде, хәрби сафын дошманына күрсәтте»).

БУЛҖАЛ (بولجال)

Монгол теленнән кергән бу сүзнең урта гасыр төрки-татар чыганакларында ике төп мәгънәсе булган:

1. Срок.

«Вә ошбу олуг чапкынымызны сез кардашымызга илле көн булҗал биреп җибәргәнмез. Сез дә булсаңыз, сүземездә табылсаңыз да, табылмасаңыз да, булҗалыннан өздерми йәнә ошбу олуг чапкынымызны безгә җибәргәйсез»[25] («Шушы олуг чапкыныбызны Сез кардәшебезгә [барып кайтыр өчен?] илле көн срок биреп җибәрдек. Сез дә үз тарафыгыздан, ничек кенә булса да, тоткарламыйча шушы олуг чапкыныбызны безгә җибәрсәгез иде»); «Вә йәнә Калмашның Җүкәче Бигиш углы бервакыт заклатка баш акча салган ирде булҗал берлә... Вә йәнә ул заклатның булҗалы йиткәч алырга хале йитмәде»[26] («Калмаш [авылы]ның Җүкәче Бигиш улы бервакыт закладка билгеле срокка баш (?) акча салган иде... Һәм ул закладны йолып алу срогы җиткәч, [йолып] алырга хәле җитмәде»).

2. Очрашуның яки җыелышуның алдан билгеләп куелган урыны, вакыты, яки урыны һәм вакыты.

«Анда бер бозык кәрвансарай бар ирде булҗалны анда куйдылар»[27] (Анда бер җимерек кәрвансарай бар иде, җыелышу урынын шунда билгеләделәр); «...Әгәр мондын күчәсез монда калсаңыз Куй суының[28] башында Оло Убада булҗал булсын, без ул тарафка күчәлек»[29] (Әгәр моннан күчсәгез дә, монда калсагыз да, җыелышу урыны Куй суының башында, Олы Убада булсын, без ул якка күчеп китик).

Фонетик вариантлары: булҗар[30], бурҗал, МОЛҖАР *(кара)*, МУРЧАЛ *(кара)*. Бу сүзләр иске татар телендә үзгәрәк мәгънәләр алды.

МОЛҖАР (ملجار)

«Ныгытма камаучыларның җирдән ясалган сыену корылмасы, траншеясы; хәрби позиция». Төрки чыгтай шагыйре Мөхәммәд-Салих XVI йөз башында язган «Шәйбанинамә» исемле поэмасында болай ди: «Имде барча алышып молҗарлар, Кабай ук торсын аны ләшкәрләр»[31] («Инде хәрби позицияләрендә урнашып барча [сугышчылар], камап ук торсын аны (кальганы. — И.М.) гаскәрләр»).

МУРЧАЛ ~ МҮРЧӘЛ (مورچال)

Бу сүзнең фарсы телендә түбәндәге мәгънәләре бар: «ныгытма камаучыларның җирдән ясалган сыену корылмасы, траншеясы; кальганың капка сакчысы; башня»[32]. В.В.Бартольд «мурчал» сүзен «отрядның яки аерым сугышчының сугыш вакытындагы уры-

---

[23] Бабер-намэ или Записки Султана Бабера / Изд. в подлинном тексте Н. И[льминским]. – Казань, 1857. – Б.409.

[24] Мухаммед Салих. Шейбани-намэ. Джагатайский текст. – СПб., 1908. – С.165.

[25] Материалы для истории Крымского ханства. – С.194.

[26] Каныш Макеев васыятьнамәсе // Старотатарская деловая письменность / Сост. Ф.С. Фасеев. – Казань, 1981.

[27] Ivanics M., Usmanov M.A. Das Buch der Dschingis-Legende (Daftar-i Čingiz-nāma). – Szeged: Univ. of Szeged, 2002. – [Bd.] I. – S.66.

[28] Ivanics M., Usmanov M.A. Das Buch der Dschingis-Legende (Daftar-i Čingiz-nāma). – Szeged: Univ. of Szeged, 2002. – [Bd.] I. – S.80.

[29] Куй суы – елга исеме.

[30] Галиәкбәр Дәһходаның фарсы теле аңлатмалы сүзлеге фарсы телле чыганакларда охшаш мәгънәләргә ия «булҗар» (بولجار), һәм «булхар» (بولحار) сүзләренең барлыгын искәртә. Беренче термин фарсы телендә «сыену урыны; сугыш мәйданы» мәгънәләрен белдерсә, соңгысы «[ике яки берничә] ил илчеләренең дәүләтара эшләрне башкарыр һәм килешү төзәр өчен бергә җыелышкан урын, җир», дип тәгъбир ителә. Күрәсең, «булхар» сүзе гарәп язуында «булҗар» сүзенең дөрес язылмавы («җ» авазын белдерүче «җим» хәрефенең ноктасы төшеп калуы) аркасында барлыкка килеп, соңрак үзгәрәк мәгънә алгандыр.

[31] Мухаммед Салих. Шейбани-намэ. Джагатайский текст. – СПб., 1908. – С.198.

[32] Steingass, F.J. A Comprehensive Persian-English dictionary, including the Arabic words and phrases to be met with

ны (позициясе)» («место отряда или отдельного воина во время битвы»), дип тәгъбир итә[33] .

Шәриф Хаҗитарханиның «Зафәрнамә-и вилайәте Казан»нында (1550 ел) «мурчал~мүрчәл» сүзе «башня» мәгънәсендә кулланылса кирәк: «Такы Хан мүрчәледәге дәрвазәдә баһадирлык мәйданының сафдәре, дилавәрлек пишәсенең газанфәре Кузычак углан… җәванане һөнәр-пишә вә дилавәране саваб-әндишәләрне кашыда алып торыр ирде» («Шулай ук Хан башнясындагы капкада баһадирлык мәйданының пәһлеваны, егетлек һөнәренең арысланы Кузычак углан… эшкә батыр яшьләрне һәм тугры фикерле егетләрне янында җыйган иде»)[34] .

МАРЙА (ماريه), МАРҖА (مارجه , مارجا)

Рус яки аурупалы хатын-кызы. «Мария», «Марья»дигән христиан исеменең төркиләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүз.

«Сез деләгән кешеңезне, кәрәк марйа булсын, кәрәк казак булсын — без бонда тавып куйармыз»[35] (Сез теләгән кешегезне, кирәк рус хатын-кызы булсын, кирәк рус ир-аты булсын — без монда табып куярбыз).

«Такы Галибәк хафиз углы көйәвемез Иш-Мөхәммәд берлән харындашымыз Шәһәр-Солтан бикәчкә, аларның икесенә Борнай углы Үтәмешдин сатып алган нимеч марҗам Корманби атлыг мирас булсын»[36] (Шулай ук Галибәк хафиз улы киявебез Иш-Мөхәммәд белән карендәшебез Шәһәр-Солтан бикәчкә, аларның икесенә Борнай улы Үтәмештән сатып алган Корманби исемле нимеч марҗам мирас булсын).

МӨЧӘЛ ~ МҮЧӘЛ (موچل)

Хайван календаренең унике еллык бер циклы. Әстерханлы Габдерахман Гомәринең шәхси архивында сакланып калган, XIX йөзнең беренче чирегенә караган бер кульъязмада шундый язу бар: «Әүвәл ел башы сычкан (1), сыгыр (2), барыс (3), куйан (4), өлү (5), йылан (6), йылкы (7), куй (8), мәчин (9), тавык (10), эт (11), дуңгыз (12). 13тә бер мөчәл, 25тә бер мөчәл, 37дә бер мөчәл, 49да бер мөчәл, 61дә бер мөчәл, 72дә бер мөчәл, 85тә бер мөчәл, 97дә бер мөчәл, 110да бер мөчәл»[37].

«Мүчәл»термины шундый ук мәгънәдә Шәркый Төркестан төркиләрендә һәм кыргызларда, «мүшөл» әйтелешендә казакъларда очрый[38].

Традицион монгол календарендә «мочлог» рәвешендә килә[39].

Дәвамы бар ■

in Persian literature. London: Routledge & K. Paul, 1892. – P.1343; Ләгатьнамәи Галиәкбәр Диһхода. – http://www.loghatnaameh.org/dehkhodaworddetail-e28722a4281948aeb6f21d0313b07228-fa.html

33 Бартольд В.В. Двенадцать лекций по истории т // Академик В.В.Бартольд. Сочинения. – Т.5: Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. – М., 1968. – С.172.

34 Togan, Z.V. Kazan Hanlığında İslam Türk Kültürü (Kanuni zamanında 1550 de Kazandan gőnderilen bir rapor) // İslam Tetkikleri Enstitüsü Dergisi. – C. III (1963) ten ayrıbasım. – İst., 1965. – S.188.

35 Материалы для истории Крымского ханства. – С.251.

36 Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. – Ч.3. – СПб., 1866. – С.235.

37 ТР Милли архивы, ф. Р-5406, тасв.1, эш 44, кгз.32. Кульъязманың шул ук битендә ияләренең берсе шундый язу калдырган: «Сахибеһе Сиддыйк бине Исмәгыйль әл-хаҗиел-хәрәмәйен бине Айтуган бине Алмәмбәт бине Гали бине Баркый, вә кабиләи җәмбуйлык, җәмбуйлык эчендә бүлтмәкле, бүлтмәк[ле] эчендә каранавыт. Тәмам» («Иясе Ситдыйк бине Исмәгыйль хаҗи бине Айтуган бине Алмәмбәт бине Гали бине Баркы, җәмбуйлык кабиләсеннән, җәмбуйлык эчендә бүлтмәкле [ыруы], бүлтмәк[ле ыруы] эчендә каранавыт [төркеме]. Тәмам»). Димәк, бу язу калдырган кеше чыгышы белән нугай татарларының җәмбуйлык кабиләсеннән булган.

38 Самойлович А.Н. К вопросу о 12-летнем животном цикле у турецких народов (Вопросник, источники, варианты названий годов, легенды о происхождении, приметы) // Самойлович А.Н. Тюркское языкознание, Филология. Руника. – М., 2005. – С.239, примеч.7.

39 Зориктуев Б.Р. Актуальные проблемы этнической истории монголов и бурят. – М., 2011. – С.111.

ӘДӘБИ МИРАС

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

The poem is presented in the translation version of Prof. Rifkat Akhmatzyanov

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

KUTADGU BILIG (Knowledge that leads Happiness)
Yusuf Balasagun

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ИКЕНЧЕ ҖАВАБЫ

Үгделмеш җавапта әйтте бу сүзне:
«Яхшылап тыңласаң, аңларсың үзең,

Кешегә файдасыз төгәл өч нәрсә,
И иге дус, шулар, ачыклап әйтсәк:

Беренче — үҗәтлек һәм холыксызлык,
Икенчесе — этлек, ялган сүзлелек,

Өченчесе — саран, комсыз булуың —
Болар бар да надан кеше кылыгы.

Иртән уңмас үҗәт кич уңмас, диләр,
Кич уңмаса исә, һич уңмас, диләр.

Кемнең чабы чыкса ялган телле дип,
Китәчәк абруе, шуны тор белеп.

Саранлар турында, ишет, ни диләр:
«Алар гел хәсрәтле һәм азап чигәр.

Саранлыктан ямьсез ни генә бардыр:
Ашыйсы ашы да ашалмый калыр».

Алтын җыйдың, ашын җийә белмәдең,
Малың — дошман сиңа. Аны җиңмәдең.

И, мал җыеп сыен, бирмәгән кеше!
Барыбер килер бер җеназа ашы...»

ИЛБИКНЕҢ ТАГЫН БЕР СОРАВЫ

Янә әйтте илбик: «Ишеттем моны
Тагын бер сүзем бар — әйтеп бир шуны.

Анаданмы белеп туа бу кеше,
Яки өйрәнәме, җиткәчтен яше?»

Җавапта Үгделмеш әйтте: «И илбик,
Белем, сәләт белән була ирдәмлек.

Туа белми кеше, тора беләдер[1].
Эшкә ярар өчен укыр-өйрәнер.

Анадан туганнар белексез туар,
Белем алыр, шуннан соң түрә чыгар.

Сәләт — ул шул, аңа өйрәтеп булмый,
Тумыштан белмәгән соңынтын белми.

* Дәвамы. Әсәр журналның 2013 елның 10 нчы санынан басылып килә.
[1] Бу сәтыр — татарча мәкаль. Оригиналда «Белексез туар ул, кагыйдәләр өйрәнер».
[2] Җетеру — үз гаебең белән югалту.

Шуннан үзгә барча фазыйләтләрне
Кешегә иңдереп тә була әле».

Бу сүзләрне тыңлап, сөенде илбик,
Әйтте: «Теләгәнне таптым инде», — дип.

Атасын җитердем[2], монавы угыл
*Ата урнын тотты, белеп изге юл.***

Шөкер итте, әйтте: «Илгә бу егет
Китерер гаделлек илә игелек.

Үгделмешне күрәм — өметле кеше,
Җиренә җиткереп башкара эшен.

Бүген кирәк иге әҗер бирергә,
Игелеккә иге җавап тиң килә».

Ни ди әле илдә сайланмыш кеше,
Халыктан сайланып, дан алмыш кеше:

«Яхшылыкка яхшы җавап хәзерлә,
Кешелекле бүләк булсын әҗергә.

Кешелек хаккы ул — вафа, тугрылык,
Кеше бул, исмеңне югары кылып».

Кадерләде илбик көннән-көн аны,
Бөтен илгә җәйде, күр, изге данын.

Бөек булды илдә хөрмәт, сан аңар,
Атына кылынды изге догалар.

Дус-иш арасында олуг, билгеле,
Бәкләр арасында ул бөек иде.

Телдә кечелекле һәм холкы ипле,
Кануннарны төпле белә шултикле.

Күңле ачык, татлы булгачтын телдә,
Яраттылар аны читтә һәм илдә.

Кордашлар, дус-ишләр арта бардылар,
Иргә бик күп эштә кулдаштыр.

Кемнең аркадашы булса, ул — көчле,
Бәхте ышанычлы, эш итсәң, төпле.

Ак күңел килешә бәхеткә бик тә.
Ни матур бик гади кыланса белкә.

Ни яхшы әйткән бер акылдар кеше
(Акыллы сүзне бел — уңар һәр эшең):

«Кем дәүләт-байлыкка килсә-ирешсә,
Кече күңел белән яшәү килешә».

Бәхет-дәүләт килсә кешегә көлеп,
Аны саклау кирәк кечелек кылып.

Бәхет күчәт[3] кебек — су сорап торыр,
Күңел тыйнаклыгы — аның тамыры.

Ни изге булыр холкы алчак кеше,
Ни күрекле — көн дә үтәлер эше.

Тәкәббер, купай[4], күр, әйбәт түгелдер,
Аның абруе да төшәр, түңелер[5].

Дәүләт ул, әлбәттә, килешә һәрчак,
Тик акыллыга бик таман булачак.

Бу хакта бер бәйттә[6] әйбәт язылган
(Шуны укы-тыңла, и егет туган):

«Наданнарга, хәтта, дәүләт яраса,
Галимнәргә инде күптән яраша.
Надан белән дә мал килешә икән,
Галим белән инде бигрәк дуслаша».

Белексезләр бөек мөлкәте белән,
Белекле бөегрәк дан-аты белән.

Надан капкасына кот килеп кунса,
Аны, бик еш кына, ташлый да оча.

Моңа танык булып искә төште сүз
(Тыңла, аңла аны, и күңеле төз):

«Юньле затны бәхет хөрмәтле кыла,
Һәм тагы яхшырта аны еш кына.

** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[3] Күчәт — күчереп утыртыласы үрген, чәчкен.
[4] Купай — кыяфәте тәкәббер һәм мактанчык.
[5] Түңелү — түбәнгә авып төшү.
[6] Бәйт — «кушык, куплет» (бәет түгел!)

Булдыксызга дәүләт килсә дә бермәл,
Югалтыр тиздән үк — көн итә белмәс».

Үгделмешне сынап йөреде илбик,
Аның барча эше дә дөрес кебек.

Кадерләде илбик аны, күтәрде,
Аннары абруен бераз китәрде.

Егет һәр очракта исен җуймады,
Тугрылыгын һәм төп эшен куймады.

Аның эше булды илбиккә ышык,
Ул аны казначы итте, ышанып.

Илбик җаваплы эш йөкләде аңа,
Җан фида җаваплы эштә булганга!

Үгделмеш бик әйбәт башкаргач эшен,
Илбик аны якын итте көннән-көн.

Үгделмеш эш итте төгеллек белән;
Алдан хисаплап һәм бүлеп, билгеләп.

Бәген хөрмәт кылып, үзен саклады,
Үз эшеннән кыек якка сапмады.

Ни ди, ишет, өлкән яшьле бер ушлы
(Яши белгәч, бөтен, җитеш тормышы);

Кыйммәттер кешегә алтын-көмеше,
Көмешләрдән кыйммәт иплe кешесе.

Белеклеләр болай бирә нәсыйхәт:
Күзгә сөрт бер ипле кешене күрсәң.

Тагын да яхшырак әйткән бер абыз:
«Миһербанлыга җан бирсәң дә аздыр».

«Тугры» дип атыйлар. Кем соң ул тугры?
Ышанычны аклый торган зат булыр.

«Алпар» дип атыйлар. Кем соң ул алпар?
Тугры яугир, шуңа таяна гаскәр.

Берәр кеше сиңа күрсәтсә хезмәт,
Онытма! Булма хис-фикерсез бер зат.

Кеше арасында кемне мактарлык?
Юмарт мактарлык ул. Саран — таптарлык.

Адәм баласының кайсы чын мескен?
Шул: кем ки ашарга тапмаса бүген.

Кайсы йөгреп тынмый, дөньяны гизә,
Кайсы җан аямый — керә диңгезгә.

Кайсы бәхет эзләп ташлар җимерер,
Кайсы җир колачлар, җәяү йөгерер.

Кайсы сыртлар аша, Иделләр кичә,
Кайсы чүлдә кое казып су эчә.

Кайсы яралана яуда кылычтан,
Кайсы ятып кала — шунда бирә җан.

Кайсы угры-карак, алдакчы-алдар,
Кайсы үтерүче, ерткыч юлбасар.

Бу кыешулар тик тамак-тән өчен,
Тыныч хезмәткә ник куймаска көчне?

Болай кыланулар наданнар холкы,
Алар хәтта кеше түгел ул, елкы.

Ходайга ышанган тәүфыйклы һәм чын
Кеше үлгәнгәчә табар ризыгын.

Ни ди тәҗрибәле укыган кеше,
Эшләү, ял итүне тиң кылган кеше:

«Кирәк ят, кирәк җир әйләнеп йөгер,
Нәрсә язган булса, сиңа шул тияр».

Нәфес һәм телеңне тыя бел, белкә,
Һәм ризыгың җитәр бар гомерлеккә.

Әгәр син теләсәң күп байлык һәм дан
Табарсың, булалсаң лаеклы инсан.

Инде хакимлек тә теләсәң тагы,
Тугры хезмәт илә яуларсың аны.

Шәп әйткән акылы җиткән бер кемсә
(Ахырда хакимлек иткән ул кемсә):

«Бу дөньяда байлык теләсәң үзең —
Күндәм бул һәм дөрес булсын һәр сүзең.

Инде хакимлеккә ирешим дисәң —
Ачык булсын телең, күңелең, йөзең».

И илбик, шәп бийләр көнен бер кара:
Ни күрекле итә дөрес идарә[7].

Тугрылык, бөтенлек илә кыл эшең,
Һәр мәлдә беленсен чын кешелегең.

Үгделмешнең бәхте гел биекләнде:
Ил белән киңәште — ил тәбрикләде.

Бөтен тапты илбик Үгделмеш эшен,
Тормады шикләнеп, күрсә кылмышын.

Сынады ул аны төрле тарафтан,
Һәм, ахыры килеп, инанды тәмам.

Ни ди, ишет, белкә — кямил акыллы
(И, белемсез, тыңла һәм и башыңны):

«Сынап карый бәкләр хезмәтчеләрне,
Ягъни бу хезмәткә ярар-чыдармы?

Хуҗага эшлекле күренсә колы,
Аңар ачсын хөрмәт казану юлын.

Бу хәлдә хезмәткәр абруйлы булыр,
Ул абруйлы булса, бәк тә абруйлы».

Ни шәп әйткән ягма[8] кавеме бәге
(Һәр шәйгә дә җиткән аның белеге):

«И бәк, бер эш бирсәң, бир син белгечкә,
Иң әйбәт, кыска юл табар ул эшкә.
Яраксыз кешене кушсаң эшеңә,
Төзәтергә туры килер үзеңә.

Аллаһ кемне котлап, күтәрмәк булса,
Аңар кулдаш[9] итеп бирә шәп оста.

Әгәр җәзаларга эстәсә кемне,
Шуңа җибәрә ул юньсез хадимне».

Һәм ул хадим шундый хәлгә төшерер,
Гүя янгын булып, чыгар төтенең.

Хөрмәтләде илбик, күр, Үгделмешне:
Вәзир итеп инде тапшырды эшне.

Күп илгә хакимлек кулларын сузды
Озын булды кулы, абруйлы сүзе.

Аяк[10] бирде, пичәт, чапрак[11] һәм киет [12]—
Вәзирлек билгесе тапшырды бийе.

Күп шанлы ярлыклар, мактау сүзләре
Белән илбик аны сөеп күтәрде.

Сәрай ир-атлары, кече һәм олы
Аңар җанын фида кылырдай булды.

Бар эшчеләр килеп күренер булды.
Табуг-тозгы[13] маллар бирелер булды.

Үгделмеш үзе шәп түрәлек итте,
Хезмәткәрләренең кадренә җитте.

Халыкны бастырган йөкне күтәрде,
Үзенең яраксыз холкын китәрде.

Төзекләнде канун, илнең нигезе,
Ил белән ныгыды Үгделмеш үзе.

Тарафдары артты; каршылар ягы
Илен ташлап качты, сынгач байрагы.

Котылды илбик, ул тынып сөенде,
Яшәү шатлыгына бирелде инде.

Бу кадәр уңышлар белемнән килә.
Булдыра укыган егетләр генә.

---

[7] Бу сәтырлар XI гасырда Баласагун — Җидесу өлкәсендә билекләр күп, феодаль таркаулык булганлыгы турында сөйли.
[8] Ягма — борынгы төрки халыкларның берсе.
[9] Кулдаш — бер эшне бергәләшеп эшләүче.
[10] Аяк (төп текстта шулай) — кешенең югары дәрәҗәсен белдерә торган кыйммәтле савыт (чагыштыр: чынаяк).
[11] Чапрак — ат ябулыгы.
[12] Киет — «обмундирование». Татар сөйләшләрендә — туй киемнәре (кәләш ягы кияүгә киет бүләк итә).
[13] Табуг-тозгы — хакимнәргә бирелә торган бүләк.

Ничек мактамыйсың шундый кешене,
Ничек хурламыйсың ишәк ишене.

Укымышлы кеше була өлешле,
Белексез кешеләр — бары тик үчле.

Белемле-ушлыга бәхет яраша,
Белем ирне шул бизи ләбаса.

Ни ди Или[14] биге менә бу хакта
(Наданнарны аның сүзе уйлата),

Ничек әйбәт әйтә бу шагыйрь теле
(Исе татлылыгы җофар шикелле):

«Белексезгә, хәтта, тәтидер дәүләт,
Белеклегә булса, бигрәк тә әйбәт.

Белексез дә рәхәт торса әгәр дә,
Лаеграк шәп тормыш белеклеләргә».

Белекле сөенеп күтәрсә башын,
Белексезләр шәме сүнәргә башлый.

Кинәнечтә илбик көне яктырды,
Ходайны мактады, шөкерләр кылды.

Күзен күккә тегеп әйтте: «И Аллам,
Мин тик синнән генә чын гыйлем алам.

Белек бирдең, иям, һәм көчле беләк,
Миңа тугрылык бир, ныклык күңелгә.

Бүләк итеп көч бир изге эшләргә,
Кул астымдагылар гамен йөкләргә».

Өләште ярлыга мал-туарларны,
Һәрьяктан Тәңрегә күңел баглады.

Яшәде шул рәвеш ничә көн һәм ай,
Табигълары[15] кара халык булды бай.

Кеше арасында шундый зат була,
Кызганычка каршы, андый тиз үлә.

Илнең шундый углы булса — бәхетле.
Бийнең иле тугры булса — бәхетле.

Яманмы, яхшымы барсы да үлә,
Ләкин яхшылардан яхшы ат кала.

ИЛБИКНЕҢ ҮГДЕЛМЕШКӘ СОРАВЫ

Беркөн илбик ялгыз утырганында
Чакыртты: «Үгделмеш килсен яныма».

Килде. Илбик әйтте: «Атаң эштә, бак,
Акыллы булса да, булды йомшаграк.

Атаң үлеп китте, син калдың кечек,
Өлкәннәр кечегә күрсәтә кичү.

Атаң гыйлем, һөнәр өйрәтәлмәде,
Аннан сиңа бик зур белек тимәде.

Ә сиңа белек һәм акыл җыелган,
Әйтеп бир син миңа — ул каян булган?»

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: «Илбигем,
Гомереңнең үзең билгелә чиген.

Ходай кемгә бирсә сәләт һәм талант,
Теләккә ирешә шул һәм дан ала.

Бу бапта төркичә бардыр бер мәкаль
(Башыннан кичереп әйткән аксакал):

«Ходай биргәненчә үсәдер кеше,
Теләккә ирешә, башкарып эшен.

Ходай бирсә, бирә ниләр булса да,
Җара[16] җир, зәңгәр күк каршы торса да.

Ходайдан бирелсә ярдәм вә терәк,
Шуның белән генә үтәлә теләк».

Янә, илбик, ата алкыган алкыш
Углына һәрвакыт китерер уңыш.

Кулын бирде илбик, күтәрде һаман,
Шарты туры килде, уңайлы заман.

---

[14] Или биге — әсәрдә берничә тапкыр искә алынган бий яки бәк.
[15] Табигъ — хакимияткә буйсынмышлар.
[16] Җара — саргылт көрән. Урта Азиядә җир кара түгел, җара.

Көлеп бакса бәкләр, якласа әгәр,
Шуннан файдалану ярый беркадәр.

Инсан күңеле чүл — сугару мотлак,
Һәм бәкләр сүзен син арыкка[17] охшат.

Су җитсә әгәр дә, хуш ис таратып,
Багың яшелләнер һәм чәчәк атар.

Бәге әмер бирсә елмаеп-көлеп,
Колы да елмаер, хушланыр күңле.

Ачулы кыланып әйтелсә әмер,
Чәчәк корыгандай кәйфе үзгәрер.

Ходайның рәхмәтен телә, кадерлә,
Ачылачак сиңа барча ишекләр.

Югарылый колны Ходай рәхмәте:
Ачып белек юлын, уңга күрсәтер.

Белем-белек илә котаер көнең,
Ни кечекләрне дә зур итә белек».

Янә илбик әйтте: «И Үгделмешем,
Ничек соң белеккә ирешә кеше?

Укып-тырышканмы акылдар була,
Әллә тумыштанмы белекле туа».

Җавабын Үгделмеш болай дип бирде:
«Мәсьәләгә төптән ачыклык кертик.

Ходай сәләт бирсә, әгәр тумыштан,
Бу тик мая гына әле тормышта.

Көннән-көн үсешә сәләтле бала,
«Белим әле» дисә, тиз белеп ала.

Белемгә ирешә һәм була белкә,
Белем илә файда китерә илгә.

Сәләтле килеш тә, күңел бирмәсә,
Бернигә ирешмәс — чыкмас һичнәрсә.

Нәтиҗә: балаңны укытыйм дисәң,
Күнектерү кирәк аны кечектән.

Кечек углан икән белек өйрәнер,
Мәгәр сәләт — ушны Тәңре бирәдер.

Белек, ирдәм, изге ният һәм холык
Тәрбиядән, шуннан килә юл-юрык.

Белем һәм ирдәмгә күнегү кирәк,
Тик олгайгач кына чын белек килә.

Бу хакта бар бер шәп төркичә мәкаль
(Укы аны, кирәк булыр, искә ал):

«Кайбер кеше укый, белеме дә күп,
Тик кайбер нәрсәгә булмый өйрәнеп.

Кайбер шәйгә сәләт Хактан бирелеп,
Бу сәләт бераздан була билгеле.

Сәләт ул, шөбһәсез, Тәңредән бүләк,
Тик аны ачарга күп уку кирәк.

Кешедән олуграк укыган кеше,
Уку була ирдә мең ирдәм башы.

Укусыз кешене кеше дә димә,
Һәм ул ни дисә, ышанып бетмә».

ИЛБИКНЕҢ ТАГЫН БЕРНИЧӘ СОРАВЫ ҺӘМ ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАПЛАРЫ

Янә Илбик әйтте: «Моны ишеттем,
Тагын бер сораулы сүзем бар инде:

Нәрсә ул белек һәм нәрсә ул сәләт?
Шуның аермасын аңлат тәфсилләп.

Сәләт-фәһем[18] каян килә һәм килсә,
Ничек күтәрелә, ничек үсешә?»

Җавабын Үгделмеш әйтте: «И Илбик,
Бик кыйммәтле нәрсә инсанга белек.

Фәһемнең урыны кеше башында
(Иң кадерле нәрсә нәкъ менә шунда).

Сәләт-фәһем азгын хисләргә кешән.
Кыланышны бизи, дәрт бирә эшкә.

---

[17] Арык — сугару канавы.
[18] Фәһем — катлаулы нәрсәне аңлап алу сәләте.

Миһербанлы Тәңре, хөрмәтләп колын,
Кешәнләгән белем илә хис холкын.

Фәһемле — үлек ул, фәһемсез — терек,
Кил, фәһемсез, укы, ал бераз белек!

Кап-караңгы бүлмә — кешенең аңы,
Уку-фәһем шәме яктыртыр аны.

Тик уку-фәһемнән килә игелек,
Белем илә аңың үсә, билгеле.

Белем, фәһем илә кеше зур булыр,
Бу ике шәй таба гаделлек юлын.

Бу хакта белкәләр әйтәләр шәп сүз:
«Белемне эшкә тот — файдасы шиксез».

Кеше бар, хайван бар. Аерма шулдыр:
Кеше белем илә йөретә кулын.

Кил, хайванча йөрмә, укы, ал белем,
Белем илә аваз чыгарсын телең».

Әйтте илбик шунда: «Тагы бер сүзем,
Менә хәзер әйтим, күрекле йөзем.

Миңа тасвирладың уку сурәтен.
Нидән гыйбарәт ул, телгә юмартым?

Йөзе, күрке, холкы-кылмышы нинди,
Яше-коры, буе, кызыкканы ни?»

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ТӘФСИЛЛЕ ҖАВАБЫ

Җавабән Үгделмеш әйтте: «Укуның
Кыланышы әйбәт, күңле көр аның.

Йөзе күркәм, үзе яшь бер сылу ул,
Барча изгеләргә күрсәткән ул юл.

Гәүдәсе туп-туры, холкы да тигез.
Бар җан иясенә әйтер яхшы сүз.

Аның кулы тигән һәрни гөл булыр,
Аның сүзен тоткан саф күңел булыр.

Йөзе нурлы, һәркем өчен сөйкемле,
Кешеләргә аннан гел файда килде.

Җете күзле зат ул — еректан күрә,
Һәр башлаган эшен җиренә җиткерә.

Болганчык эшләрне сөзәр, саф итәр,
Төен ни буталчык булса да, чишәр.

Карар уңга, сулга, аска һәм өскә,
Чарасын, вакытын билгеләр эшкә.

Качканны аулар ул, очканны тотар,
Сыныкны ялгар ул, бозыкны төзләр.

Укымаган беркөн шиксез үкенер:
«Нигә укымадым икән мин,— дияр, —

Миңа тимәдең син — укудан өлеш;
Синсез кеше күңле гүяки үлек».

Чырак ул уку, күр, күз — сукырларга,
Үлек тәнгә җан ул, тел — сакауларга.

Укыган укуга әйтер: «И дустым,
Миңа син шулкадәр әйбәт булыштың!

Укуның эше уң, сулы юк аның,
Бөтен, сәламәт ул, чире юк аның.

Уку кемдә булса, беленеп тора,
Аның билгеләре сизелеп тора.

Укыганның сүзе тугры һәм төпле,
Эшендә, холкында булыр бөтенлек.

Укыганның һәрчак холкы уңайга
Кылмышы дөрес һәркөндә, һәр айда[19].

Тыныч, нурлы йөзле, басынкы, сабыр,
Белеп уйлап кына эшкә тотыныр.

Кыланыш — картларча, көче — яшьләрчә,
Мохтаҗга-моңлыга әзер ярдәмгә.

Бу бапта шундый сүз бар, менә тыңла,
Тыңласаң, мәгънәсе ачылыр чынлап.

[19] Көн һәм айларның бөреҗ (зодиакаль) юралышларына карата әйтелгән.

«Фәһем — ул картларча яшәүче углан,
Фәһем күрсәң, ияр, аерылма, туган.

Яшьлеге сөйкемле, картлыгы салмак,
Үзе төзек-тыйнак, файдасы байтак».

Боларны ишетеп илбик сөенде,
Әйтте: Һай, уяу һәм зирәксең инде.

Бу фазыйләтләрең Тәңредән бүләк,
Үзең дә миңа бер бүләк кебегрәк.

Минем эшем авыр — күтәрү читен,
Аны күтәрүем шәрәфле ләкин.

Йөкне күтәрешең, эшең ярарлык,
Миңа җиңеллек, тик сиңа авырлык.

Ходай бирсен миңа саулык һәм холык,
Хакыңны бирим, өч тапкыр арттырып.

Ачык синең әйбәт хезмәт кылганың;
Мине теләгәнең — миһербанлыгың.

Рәхимлерәк була шундый хезмәткәр—
Үз файдасын түгел, бәкнекен теләр.

Андый хезмәткәрләр, ишет, ни диләр:
«Тугры кол уңышка бәген җиткерә».

Бәк бәхетле-котлы шундый шартларда —
Рәхимле, булдыклы хезмәткәр барда

Бәк белән хезмәткәр тиң канәгатьтә,
Алар бер-берсенә булса теләктәш.

Авыр эш — имгәкне күтәрсә колы,
Бәгенә ачылыр уңышлар юлы.

Каю бәктә булса шундый хезмәткәр,
Ходайдан аңарга бүләк ул, мәгәр.

Дөньядан үттеләр күптән күп бәкләр,
«Шундый колым булса», — диген теләктә».
....
Бар халык юанып, сулады җиңел,
Дога кылды бигә шулчак бөтен ил.

Ишетте бу хакта күрше илләре,
Би йөзен күрергә барча теләде.

Кичерде ел, ай, көн бер арзу белән,
Һәм илен төзеде дөрес юл белән.

ИЛБИКНЕҢ ҮГДЕЛМЕШНЕ ЧАКЫРТУЫ

Үгделмешне беркөн чакырды илбик:
«Мин сөйлим, син дә әйт белгәнеңне,
— дип. —

Җан үз тәнен карый — җиде мөчәсен[20],
Һәр кайсы татлы һәм сорый хиссасын.

Күңел татлыгы ни һәм күз татлыгы?
Бу икедән җанга кайсы якыны?

Сөйгәнеңне күрү — күзеңә шатлык,
Теләккә ирешү — җаныңа шатлык».

Янә әйтте илбик: «Әйтте, Үгделмеш,
Сөюнең билгесе нинди кичереш?

Сөямен, дип барча дәгъва кылалар.
Бу дәгъваның асыл төбендә ни бар?»

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Һәм Үгделмеш әйтте: «Җавап бер генә —
Сөяре сөекле йөздән күренә.

Карар күзгә барча нәрсә өртүле,
Ә күңелгә өртү юктыр, билгеле.

Сөярен-сөймәсен белимче дисәң,
Күңленә багып күр — тиз беленәчәк.

Сөйгәннәр йөзендә булыр билгеләр,
Күзгә-күз караса, гашыйк билгеләр.

Бу хакта бер шагыйрь болай дип әйткән
(Укы яки тыңла, и, егет-мәргән):

«Сөекле кешенең йөзе билгеле,
Тел ачса мәгънәле сүзе билгеле.
Сөярен-сөймәсен белимче дисәң,
Сиңа текәп баккан күзе белдерер».

Дәвамы киләсе санда

[20] Җиде мөчә — ике кул, ике аяк, баш, күкрәк,



ТУКАЙЧА ТАТАР КОДЕКСЫ

Зиннур Мансуров

TATAR LAWBOOK IN TUKAY'S MANNER

Zinnur Mansurov

Каләм әһелләре әледән-әле искәрткәнчә, һәрбер әдип насыйп гомере дәвамында үзенең бердәнбер зур китабын яза. Табигый ки, олуг талант ияләре тарафыннан иҗат ителгән мондый фолиант ил-көн өчен бәһаләп бетергесез рухи кыйммәтләрне гәүдәләндерергә мөмкин.

Әгәр шулай икән, без бөек шагыйребез Габдулла Тукайның бөтен язганнарын халкыбызга мирас кылынган яшәеш дәреслегенә тиңли алабыз. Чыннан да, аның даһилык белән тудырылган иҗаты биниһая тәгълим мөмкинлекләренә юл ача. Бары тик аннан зирәкләрчә файдалана белергә генә кирәк. Мондый затның классик әсәрләрендәге барлык сүзе генә түгел, хәтта һәрбер ым-ишарәсе газиз милләтенә хезмәт итәргә тиеш.

Нәкъ менә шушы куллану осталыгы җәһәтеннән, без үз вазифабызны тулы күләмдә үтәүгә ирешәбезме соң? Раслап әйтү кыен. Әнә, Габдулла Тукайның җәрәхәтле бәгыреннән савылган әлеге «бердәнбер китабы» эченнән «Татар кодексы»н үтәли күреп, аны халкыбыз дикъкатенә юнәлтер өчен дә безләргә бер гасырдан артык вакыт кирәк булды. Аһ, аянычлы кыска гомер шәме ике яктан янып килмәсә, яки кемдер тарафыннан җаваплы йөкләмә куелса, шагыйрь аны үзе дә кәгазьгә төшереп калдырыр иде. Берничә нашир тәрҗемәи хәлен язып бирүен үтенгәч, «Исемдә калганнар» рисаләсенә тотынырга кулы җиткән ләбаса. Җәмәгатьчелек вәкилләре сорагач, «Шәрекъ» клу-

бында халык әдәбияты турында лекция әзерләп укырга да, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән дәреслек-хрестоматиясен төзергә дә өлгергән.

Ә татар халкын озын-озак гасырлар дәвамында тәрбияли алырлык ошбу кодекска килгәндә, сүз дә юк, Габдулла Тукай аны үзенең язганнарында ярылып яткан тәҗрибә нигезендә әзерләр иде. Нишлисең, әлеге эшне тиешенчә ахырына җиткерү бөтен җаваплылыгы белән безгә тапшырылган. Шик-шөбһә тумасын, сезнең игътибарга кануни шәкелдәрәк тәкъдим ителгән бу җыелма төп-төгәл шагыйрь каләме теркәп калдырган сүзләрдән генә тора. Хәрефкә хәреф туры килә, дип, нәкъ шундый очракта әйтеләдер. Хәтта бүлекләрнең исеме дә аның әсәрләре тукымасыннан алынды. Кодекстан файдалану барышын җиңеләйтү максатыннан, нибары тәртип саннары гына өстәлде. Алары да шагыйрь өслүбе өчен ят түгел, Габдулла Тукай бүлем рәкымнәрен шактый еш кулланган.

Инде шундый искәрмә дә биреп үтәргә кирәк: кодекс калыбындагы әлеге уй-фикерләр нинди дә депутатлар төркеме тарафыннан түгел, ә аерым шагыйрь исеменнән юридик таләпләрне күздә тотмыйча язылган. Монда шәхси башлангычның өстенлек итүе табигый. Шул ук вакытта көрәшче әдипнең фикри сөземтәләре дәүләти югарылыктагы иҗтимагый гомумиләштерүләрдән дә мәхрүм түгел. Кыскасы, боларның һәммәсен дә белеп тору лязем дер.

Тукайлы язмышыбызга рәхмәтләр белдерик. Пәйгамбәргә торырлык шагыйребезнең еллар аша безгә җиткерелгән әлеге мөкатдәс бүләге, иҗтиһадка өндәүче әманәт буларак, татар халкының алгарышына янә бер ныклы нигез ташы рәвешендә салынсын. Аллаһ теләктәшлек кылсын.

Биисми Габдулла бине
*Мөхәммәдгариф Тукаев**

I. КЕРЕШҮ СҮЗЕ. АЛЛА ГЫЙШКЫ ХАКЫНА

1. Бисмиллаһ иррәхманир рәхим...

Без дә бер кешедәй дус булыйк
Алла гыйшкы хакына;
Эрелек, төче теллелекне ташлыйк
Алла гыйшкы хакына.

Милләтнең күңеле Аңа юнәлсен
Алла гыйшкы хакына;
Иске чир, түбәнлек юк булсын
Алла гыйшкы хакына.

Шул юлга омтылыйк, и диндәшләр,
Алла гыйшкы хакына;
Мондый омтылыш, тырышлыклар керсен гадәткә,
Алла гыйшкы хакына...

Гыйлемгә кирелек пәрдә булмасын
Алла гыйшкы хакына;
Җанланыйк, кузгалыйк һәр җирдә
Алла гыйшкы хакына.

Дуслык булмау сәбәпле, милләт шушы хәлгә килде, —
Гыйбрәт ал, и Мөхәммәд өммәте!
Алла гыйшкы хакына.

Без дә кеше ич, итик гайрәт
Алла гыйшкы хакына;
Бу дөньяны хәйран калдырыйк
Алла гыйшкы хакына...

Бар һөнәребезгә канәгать булмыйк
Алла гыйшкы хакына;
Тәңре мәрхәмәтенә каршы килмик
Алла гыйшкы хакына.

2. Күп сөекледер бөтеннән — Тәңрегә сынган күңел... Һәрвакыт Аллаһы Тәгалә хәзрәте күңелеңезгә тәүфикъ нуры кертеп изгелек кыйл-

* Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев исеме белән.

мак… Тәкъдир сезгә теләктәшлек белән елмая: мондый зур бүләкнең кирәк кадерен белергә…

Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән… Барчагыз Алла җебенә ныклап тотыныгыз. Алла җебе дигәнем үзара якынаю, дуслашудыр, димәк, үзара каршылыктан, ызгыштан саклanудыр…

Ярдәмендә һәр заманда Алла бар; ал җәсарәт [1], алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!.. И Алла! Алга китүебезгә, югары күтәрелүебезгә булышлык итүчеләргә ярдәм бир!..

Һәр ничек хәер-фатихада булышаек… Эшләреңездә парлак сурәттә муаффәкъ булуыңызны [2] телим… Алла сезне һәр ике йортта (дөньяда да, ахирәттә дә) бәхетле итсен… Алла риза булсын, гомерегез озын булып, байлыгыгыз һәм бәхетегез көннән-көн артып торсын… Милләтнең киләчәге айлы кичтән дә яктырак булсын.

II. БАЛАНЫҢ ЯЗМЫШЫ АТА-АНАСЫНА ТАПШЫРЫЛА

1. Көлле мәүлүдин юләде галя фитърәтел-ислами, фәминә әбәваһе йөһәввиданиһи вә йөнәссыйраниһи вә йөмәҗҗисанаһи…

Хәдис шәрифнең мәгънәсе заһир [3]: һәр тугъмыш бала ислам, ягъни тәслим фитърәтендә [4] туа.

Баланың язмышы, ул тугачук, аның ата-анасына тапшырыла, тәслим ителә… Аның атасы яһүди булса, бала киләчәктә яһүд милләтенә хезмәт итәрлек рәвештә тәрбия ителә. Атасы нәсрани [5] булса, янә, нәсрани милләтенчә тәрбия кыйлынып, киләчәктә үз милләтенә файдалы бала булуы күзгә алына… Менә без, татар балалары да, татар милләтенчә тәрбия кыйлынганбыз… Татар диненчә тәрбия алганбыз…

Вәләкин… Тәрбиямез… коры, рухсыз, мәгънәсез, һич файдасыз рәвештә «дини» генә булмыйча, дини вә милли тәрбия булсын. Мөселман булганымыз вакыт татар икәнемезне дә онытмыйк.

2. Балалар — безнең шатлыкымыз… Балалар — безнең бәхетемез вә сәгадәтемез… Балалар безнең гомер нигеземезне тазарталар, балалар хезмәт өчен безнең көчемезне арттыралар.

Бу сүзләр һәрбер атаның да, һәрбер ананың да йөрәгеннән ләззәтле-ләззәтле генә өзелеп чыккан сүзләрдер.

3. Балалар якты дөньяга килгәндә, гадәтән, бер бәхетлелек диңгезе булып киләләр. Ләкин әнә шул балаларны туган минутыннан алып балигъ булганга кадәр, ата-ана үзләренә бәхет вә башка инсаннарга да шатлык булырлык итеп тәрбия кыйлуы бик читен, ай-һай, бик читен!..

Бала, ир бала, әйбәт кенә тәрбия ителсә, ата-ана өчен, гомернең куркынычлы һөҗүмнәре вакытында шул бала шул ата-анасын сакларга күкрәп, нәгъръә орып чыккан бер арыслан буладыр.

Кыз бала, бик матур гына тәрбия ителсә, бөтен дөнья байлыкларына сатылмаслык егетләрне, картларны, хәтта хатыннар вә карчыкларны үзенә таба тартып тора торган… бер фәрештә буладыр. Аның бер сүзен ишетер өчен, бер генә йөзен күрер өчен меңнәрчә җаннар атылып кына торадыр. Ул үзе шикелле тагы әллә ничә фәрештә кызлар вә әллә ничә арыслан йөрәкле, гайрәтле егетләр тәрбия итә аладыр.

III. УКЫМАК — ҮЗ ХАЛКЫБЫЗГА ХЕЗМӘТ ИТМӘК

1. Очып төш тә балалык бишегеннән, ябыш — аерылма мәктәп ишегеннән… Синең бу барган юлың — галимнәр юлы; бу юл белән барлык олы кешеләр җитешкән. Бу дөнья, бел… Максаты — иксез-чиксез бәхет; соңы — үсү, бөеклеккә күтәрелү… Көне килер: синең дә урының бөек булыр; ихтимал, исемең алтын белән язылыр.

Атагыз, анагызның шатлыгы сез, ике дөньяда йөз аклыгы сез. Барлык мөселманнарның уртаклыгы сез, безнең саф динебезнең пакьлеге сез. Гыйлем

йозагының ачкычы сез, тәрәккый күкләрнең баскычы сез.

Мәгариф бакчасында очып йөр... Һәр чәчәк — сеңлең, апаң; абзаң — үсеп торган агач...

Мәгариф — хәяттыр. Һәр бәхетне, һәр сәгадәтне, һәр нәҗатны [6]... голүм [7] вә мәгърифәттән генә көтмәк кирәктер... Укып, балалар алга баралар...

Каз канатлары ак булыр,
Ир канатлары ат булыр.
Сабыйларның канатланыр вакъты
Мәктәпләрдә укыр чак булыр.

2. Яз, газиз угълым: кара тактаны сыз акбур белән! Һәм кара күңелеңне ялт иттер, сызып ак нур белән! Өч наданга алмашынмас — бер язу белгән кеше; мәгърифәт эстәр, иренмәс һич — кеше булган кеше...

Тынма, эшлә, и сабый!.. Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул; картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!.. Тәңредән эшләргә — көн, эшләп аргачтын, бирелгәндер тыныч йоклар төн. Иртә торгач та язарга, дәресең укырга тотын; тынма, эшлә, торма тик... Гомер итмәк — тырышмактыр ялыкмый, ... гатәләт [8] хурлыгын асла [9] үзеңә ихтыяр итми. Мәгърифәт эзлә, бар әле...

Адаштым дип егълый күрмә: гыйлем чын эз табар әле... Булганы белән канәгатьләнмә, тәрәккый ит, алга бас; гыйлем диңгезләренең иң тирәне сиңа кояр... Бит шуңа бәйле бәхет-рәхәт.

3. Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә, мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканны белсә. Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга, уенга салмаса ихлас — менә бәхете аның шунда. Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә, бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә!..

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт: һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет; ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр, ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар... Очрый калса сезгә шушындый ярлылар, яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар — яшь балалар! Аларны сез яратыгыз, җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз!

4. Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын; мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын...

Укымак — дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак — фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак — үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак — үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр... тугърысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак — хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү юлына ташламак димәктер. Укымак — үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максудка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. Укымак — ... гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер... «Укымак» ләфзы [10] астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр.

5. Беләм инде, сабыйлар, сезгә мәктәптә күңелсездер, аның тоткынлыгыннан сез бигүк разый түгелсездер. Сабый чакта күңелсезләнгәнем бар мин дә... Заман үтте. Азат булдым... Күңелдән сагынам «тоткын»лыгымны, мәктәбемне мин...

Яшьләргә... уку кирәк. Бу аларның иң мөкатдәс, иң беренче вазифаларыдыр. Бу — безнең һәртөрле... бюрократия золымыннан, башка милләтләр илә берлектә, безнең дә котылуымызга иң беренче вә иң тугъры юлдыр... Сүз башында әйткәнемезчә... Аллаһы Тәгалә файдалы гыйлем бирсен.

6. Әй бәһале, әй кадерле,
әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның,
һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген,
ушбу җиһанда якты юл;
Ул — рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә
күп шәфкатьле Ул!
Саф әле күңлең синең, һичбер
бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз
сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең —
барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың,
йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә
кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл
бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле,
әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның,
һәрдәм таян син Аллага!

7. Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан [11]вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә [12], чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятләренә [13] мохтаҗ… Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, … яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ.

Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышымыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз-тавышсыз, рәхәтсез булачактыр. Болардан башка безнең гомеремез бер дә бәйрәмсез, гомерлек мәшгулият яки бер дә җәйге кояшсыз мәңгелек көз көне төсле үтәчәктер.

8. Әүвәл милләт укысын, белсен… Мәгариф тарату булсын бездә гадәт… Ходай орган җәһаләт [14] бит ниләр кыйлдырмый, нишләтми?!.

Мәктәпләр — безнең арсенал, татар. Надан булу — гарь, татар, аңгар дөнья тар, татар; алсаң өлеш һәр фәннән, бәхетең булыр яр, татар… Өмет анчак [15] мәктәпләрдә генә!..

Бармак берлән каткан җирне казып булмый, әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый; шуның төслүк, мәктәпләрне төзәтмичә, «Тәрәккый!» — дип кычкырырга базып булмый. Ислах дәрьясында йөзсен безнең кораб, китсен тугъры… Тик шундин соң — шундый гайрәт аркасында мәктәпләр дә әкрен-әкрен алга китәр.

9. Мөгаллимнәр!.. Һәр нәрсәнең гүзәлен яратабыз бит… Гыйлемнәр бакчасында күңел ачып йөрик… Балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен. Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф [16] булып, анчак гүзәл вә мөкатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр. Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре томанланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез карауччы буладыр.

10. Киләчәктә… ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын… Аллаһы Тәгалә исемемезне, җисемемезне вә рухымызны ислах әйләйә [17]!..

Без дә адәм угълы — адәмчә тормыш итик дөньяда. Гыйлем белән дөньяны кулда тотты япон, немец, француз… Без — бу мәгърифәт гасыры сараеның ияләре һәм балалары… Мәгариф мәйданында без, татарлар, ат уйнатыйк!

IV. ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ

1. Шөкер булсын, гасырыбызның яшьләре уянып тордылар... Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре: аңламак, белмәк, тәрәккый, мәгърифәт, хикмәт белән әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары...

Сөям сезне, сез — чын яшь егетләр; өмет бар сездә, сез — интеллигентлар. Телем, күңелем — бөтен барлыгым сездән риза; үткән чорда сезнең ишеләр булмаган. Сез — яңа пешкән, җитешкән баһадир; хәзер яшь баһадир — бәя биргесез. Без сезне гасырлар буе көтеп алдык; килерсез, дип һәрвакыт күз тегеп тордык. Сәламәт килдегезме — рәхим итегез!

Сез — күңел шатлыгы, таң җиле сез. Черек милләт өчен сынмас терәк сез; тугыз корбан суеп алган теләк сез...

Әгәр пәйгамбәр терелсә, ... сезне ул, һичшиксез, тәбрикләр иде, сезне өндәр һәм димләр иде; дияр иде: каһарманнар, гайрәт итегез; гайрәт итеп, дөньяны хәйран итегез! Бу — нәфислек һәм матурлыкны арттыру; түгелдер бу — ахмаклык һәм бозыклык.

2. Беләсезме, бу дөнья нинди дөнья? Бу дөнья — һәр ике дөньяда бәхетнең башы. Бу юлны, зинһар, мәңге ташламагыз, чөнки бу — милләтне алга илтүче юл... Бу юлда, шөбһә юк, без җан бирербез; ниһаять, милләткә дан һәм шан бирербез... Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары, ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек — без аның бик зур фәхерле [18], чын бриллиант кашлары!

3. Бу тормыш кем белән туктар талаштан? Сугыш син һич тә армас-туктамастан. Синең төсле берәү ул: бергәбер сез, көрәшкәнне җиңә алмый ул каберсез...

Авырлык төшсә түз, сер бирминитми... Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан, вә юлны тапмый калмый һәр адашкан...

Якын дустым! Синңа миннән киңәш шул... Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел, үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл. Ачып яшерен хәзинәңне йөрәктән, сөйләшмә бер дә артык сүз кирәктән... Кача күр, кош кеби, мактауларыннан, хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан. Әгәр басса сине бер-бер заманны егъламый йомшамас хәсрәт вә кайгы, утыр аулакка, кайда һич кеше юк, сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түк. Килеп керсә берәү нәкъ шул чагында, сиңа мин бер киңәш әйтим тагын да — диген син: «Күзләрем никтер авырта, өзелми яшь ага кич һәм дә иртә!..»

Сәгадәт талына менсәң — үзең мен; ни ярдәм килсә дә, килсен үзеңдин... Тартыш кирәк, кирәк тартыш!..

Берәүнең уйларын икенче берәү бикләп куя алмас; теләгендә нык торучыны беркем өметсез итә алмас. Тәңребезнең безгә кушуы: «Өметсезләнмәгез!..» Кояшың яктырсын... Курыкма, синең йолдызыңны Тәңре бәхетсез итмәс... Тырышмалы!..

Ир кеше теләкләрен күңелендә яшереп тотмас; үзен бер генә урынга агач кебек беркетеп куймас...

Саклан, күңелеңдә урын бирмә таләптән башкага; хаклык теләүче үз максатыннан бүтәнгә күз салмас. Хаклык үзенә ияртүчене һәр хәлдә кире какмас; ялганны ялганга чыгарыр... Милләт иблис күләгәсен Тәңре күләгәсе ясамас. Хаклык зәгыйфь дип куркып, юлыгыздан чыктыгызмы? Тоткан юлны ташлау сезне, әлбәттә, бәхетле итмәс...

Ләззәт вә тәм нәрсәдә?.. Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт... Бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

4. Эшнең дөрестен сөйләргә кирәк... Без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек, аның «вәкар»ен бозарга кирәк. Бу — өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кебек кагыйдә инде... Бар егетләр: бик тәкәбберләрчә тоткан позасын... Андый «вәкарь» яшьлектә җимерелмәсә, ... неграмотный үләчәк

«зате галиләрдә» [19] дә кала. Мисал эзләсәңез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез... Инсаф кирәк... Тәкәллеф ише кимчелекләрне ташлыйк!..

Кызыкма һичвакыт шөһрәткә син; бик төренмә, иртәгүк артык булыр чүпрәккә син. Тапмасам шөһрәт, сизә алмаслар, димә күңелемдәген, зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син...

Гафу итәсез... Шулай тәфсилләмәсәң, татар аңламый... Моны яздым, киңәш бирдем, юаттым һәм тыйдым, куштым; шулай булмыйча хәл юк, инде калган мин генә дустың!

5. Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны образауный егетләргә... Барып керик хөрриятнең кочагына, тәрәккыйнең күкләренә очмагына; бу егетләр безне дөнья оҗмахына кулдан тотып җитәклиләр...

Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше!

6. Татар яшьләре... Аналары тәрбиясе алар өстенә фарыздыр... Аналарын карасыннар, тәрбия итсеннәр, чөнки оҗмах аналар аяк астында табыла.

7. Сез — интеллигентлар... Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар... Зыялыларымызга һәр ничек, җәсарәтле пожарныйлар кеби, җәһаләт ялкыны эчендә дөрләп янган милләтне, тизрәк утка атылып, коткарырга тырышу фарыздыр. Пожарны читтән тамаша кыйлып кына көлеп тормак — ирлек түгелдер.

8. Яшәсен гайрәтле милләт арысланнары!.. Яшәсен яңа, яшь милләт каһарманнары!..

Татар яшьләре!.. Һайдәңез... Милләткә... тәкрар әйтәмез...

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем; саулыгың — минем саулык, авыруың — минем авыруым.

Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле; дөнья бирсәләр дә, сатмам ... миллиятемне...

Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы... Үтәргә иде юлда... түләү белән бурычны Тәңремә һәм халкыма... Шушы юлдан ризамын, башка төрле юл да тотмыймын...

Күңел берлән сөям бәхетен татарның, күрергә җанлылык вакытын татарның. Татар бәхете өчен мин җан атармын: татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм... Минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен.

V. НИГӘ ТАРИХТАН ГЫЙБРӘТ АЛМЫЙСЫЗ?

1. Артка карасак борылып... Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе: «Аh!» дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе... Түбәннәр югары ашкан, бөекләр түбән төшкән...

Әйтсәгез, сездән сорыйм мин: бездә нәрсә юк иде?!.

Мәгъмур [20] Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр... Китте Касим, китте Казан. Бетте татар, кырылды хан... Җылый-җылый бирделәр җан: Сөембикә дә Чыңгыз хан; нә дәүләт калды да, нә шан!..

Күпме михнәт чиккән безнең халык, күпме күз яшьләре түгелгән... Аh, ник соң без булдык вәйран? Бөтен дөнья калды хәйран...

Нигә тарихтан гыйбрәт алмыйсыз?

2. Юк шул бездәрдә берләшмәк; юк бергә-бергә гөрләшмәк, бер җан, бер тән булып, һәр нечкә серне бергә серләшмәк... Фида булган мөрәүвәтле [21] бер җан кирәк.

3. Вакытында җирне селкеттек... Инде эш үтте, булачаклар булды!.. Кемгә ләгънәт әйтәсе һәм каргасы?.. Шулай булган. Заман кичкән. Сулар аккан... Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

4. И Җир, синдә — синең куеныңда ничә төрле кавемнәр бардыр?.. Бу, корт-кырмыскалар кеби, дөньяны каплаган адәмнәр эчендә Әмерләренә буйсынып, максудка җиткәннәрне бик аз таптым.

5. Дөньяда һәр нәрсә дә үз асылы-

на бер әйләнә… Эшкә ябышыр чак җитеп, ямьсез озын төн үткәнен күз ачып белдек без, үлчәп күктәге Чулпан белән. Булса да ул чакта бездә кер-сез иман, саф күңел, күз һаман бул-ды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел. Шул сәбәпле дустны, дошманны дөрест фәркъ итмичә [22], күп саташтырдык … шайтанны чын инсан белән. Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек — булсын кабул.

6. Без һаман сабыр итәмез… Бу тор-мышка кальбән [23] разый булган кеше мөселман да түгел, мөэмин дә түгел, инсан да түгел диясем килә.

7. Хикмәти Хода, кая карасаң, анда без фәкыйрь милләтнең бер җире җитмәгәнлеге заһир була!..

Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул; инде эшлик саф, ачык күзләр белән… Фәиннә мәгаль госри йөсра**.

VI. ВӨҖДАНЫҢ БЕЛӘН КИЛЕШ

1. «Аһ!» дисең, без ник болай соң?..

Сүзне ничек башларга кирәк? Хәер, болай башласам да ярый бит… Тугъ-ры әйтергә яраганда, кинаяләргә сы-гыну нәрсәгә?.. Китмәсен хак сүзгә һич кәефең синең… Тыңламасаң бу нәсыйхәтне, язу бушка фәкать…

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без, кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без… Әхлак, вөҗдан, инсафларны сөреп чыгардык истән дә; бозылдык шулкадәр начар, уздырдык без иблистән дә… Мәлганәт [24], пычрак вә ялган берлә тулган безнең эч; бар начарлыктан, бозыклык-тан гыйбрәт безнең эш… Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык, төяп ил-теп Мәкәрҗәдә сатарлык.

2. Шаккатабыз тышкы зиннәтләр, киемнәргә карап… Өстеңдә әйбәт кием булгач, синең бәрәңге генә ашаганыңны кем белә?.. Җан сатабыз әллә нинди вак «тиен»нәргә карап… Йөз сумны урлап килгүче угъры кеби, күз сала-быз чын сүз әйтердән элек як-якка без. Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга, гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без… Акча барда бар да дуст шул, бар да яр; акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!..

Кешеләр үзләрен анчак сөярләр, бәхетсезләрнең өстеннән көләрләр…

Туктале, бер көн килер дә өйрәтер, әлбәт, ләхет, миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс… Анда хакимнәр дә ал-тыннарга һич алданмыйлар; анда адво-кат та юктыр — акчага ялланмыйлар.

3. Күрмәгез бер яклы дип сез бу ва-фасыз дөньяны; ул ике яклы: аның бар-дыр иләк һәм күн ягы. Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә: син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә!..

Килсә теләнче капкаңа, каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама… Бул-са — бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаслыгын, сизми калма ак сакаллы картның Хозыр Ильяслыгын!

4. Дөресне сөйлә, … беркемнән дә курыкма; сабыр бул, чөнки сиңа эшнең җиңеле йөкләнмәгән…

Дөнья яратылганнан бирле ял-ганнар күбесенчә тотылмый кал-ган… Һәр алдауга ышанмаска кирәк, алданмаңыз, карендәшләр, гафил улмаңыз… Алданмаңыз, болар сезнең дошманнарыңыздыр, болар тик үз файдалары өчен генә тырышып, сезне әсирлектән чыкмасын дип тырышучы-лардыр…

Дустлар, тугъры юлдан китик… Барыбер без алданмыйбыз дигәч ал-данмыйбыз!

5. Усаллык хәзинәсе бик зур, ул — күпме алсаң да бетми…

Өметсезлек, усаллык, вәсвәсәләр зәгыйфь җанны теләләр һәм кисәләр… Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа, әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа: «Бу заман шундый заман, — дип, — бу вакыт мондый ва-кыт, син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот…»

** Авырлык соңында җиңеллек тә була.

Дөрест, һәрбер халыкта бар дорыр мондый кара йөзләр... Алар ерткыч, алардан читтә бул син, алар барда бүрең бер якта булсын...

Җитәр, инсаф кирәк, инсаф кирәк... Ярлыкау эстә, шөкер ит, тәүбә кыйл...

Файдаланыйк киңлектән, ваз кичик мин-минлектән... Бүлик без бер алманы биш кисәккә... Җыйналып мәҗлес ясыйк... Тәнемез аерым булса да, бер җан булыйк.

6. Эчә халык суык дип тә, бәйрәм дип тә, эчә халык хәләл дип тә, хәрәм дип тә; «Кытайский әфлисуннар яшьнектә», — дип, «Эчми үткән яшьлек гомере әрәм», — дип тә...

Җөмләдән берсе... Мәктәпләрдә укыр чак... Мин... үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем. Мәсәлән, бер заман... минем илә күрешергә... авылымызның шактый могтәбәр кешесе килде, үзе исерек иде. Миңа килеп сәлам бирде — сәламен кайтармадым, кулын сузды — кулын алмадым. Сәбәбен сорадылар. Мин шул вакыт «Бәдәвам»ның:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә һәм син алма... —
дигән бәетен ярдым да салдым...

Дөнья булгач кеше төрле хәлгә килә шул... Әхлаксызлык... Электән белгәнем хәлдә кешенең тышы яхшы, бозыклыгын эченең ... хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын...

Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел, һич кайгысыз кеше булса — адәм түгел! Бераз вакыт шатлык таба исерек кенә, үз-үзенә ачы агу эчереп кенә...

Эчә дустлар чәкәшеп, күзне-күзгә текәшеп; эчкән була карчык та — үзе беткән бетәшеп... Ушбу халык, кабак ничек ачылгач та, бик нык суга гөнаһы юк бутылкага, диеп аңар: «Эчеңдәге суың чыгар, аның белән безне җылыт, безне сугар; эчтән безгә бишмәт киерт, чикмән киерт, көчле хәмер! Синең кулда зур ихтыяр...»

Әгәр күрсәң кызарган йөз аларда, бер дә алданма: «Оялгандыр», — димә яңлыш, «Җибәргәндер», — дисәң — әүля [25]!

7. «Шайтан аздырган», имеш! «Юлдан яздырган», имеш! Кире татар, иң элек вөҗданың берлән килеш!.. Сезгә һәм безгә ни җитмәгән?..

Без ул милләткә... үз сурәтен үзенә күрсәтик... Көзге каршысына китерик... Милләт күрсен... Ләкин авызы кыйшык кешенең авызын туры күрсәтмәгән өчен көзгене атып бәрмәсен...

Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мең ләгънәт! Яшә, тугъры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!

VII. ИСЛАМНЫҢ МИЛЛИЯТНЕ САКЛАРГА КУШУЫ ТАБИГЫЙ

1. Безләрне туры юлга күндергән Коръән икәндер... Аңлангачтын Коръәндәге бик күп серләр, үз-үзендән агаралар дини керләр...

Ислам бит хак дин, ә хаклык, һичшиксез, гел өстен булыр.

2. Исламның миллиятне сакларга кушуы табигый... Билгеле ки, дин кешеләрдән аерым түгел.

3. Наданлык таптамасын — яньчелербез, каләмгә каршы бармыйк — чәнчелербез. Каләм — хөкем йөртүче Җир йөзендә, аның белән ант ителгән «Нүн» сүрәсендә...

Болар бит исламга терәк, безгә боларга таянырга кирәк... Көчсезләргә иптәш, көчлеләргә җитәкче, болар — бөтен ислам инануларын ачыктан-ачык күрсәтүче...

Каләм — бөек, каләм — дәрәҗәле; Ходайның телендә ант урынында ул. Каләм — данлы, каләм — шанлы; каләм ул — чиргә дәва, кайгыны юар сабындыр...

Исламның миллиятне сакларга кушуы табигый улдыгы кеби, кызганырга лаек инсаннарны да ифрат дәрәҗәдә кызганырга кушуы да табигыйдер...

Дин димәк — бетмәс-төкәнмәс бер хәзинә ул.

4. Шәригатемез — Коръәне хәдистер, Коръәне хәдис тә кыямәт барачак, анда бер дә шик-шөбһә юктыр…

Без, «Хатәмен-нәбиин» аятенә иман иткән мөселманнар, һичбер вакыт Печән базарыннан пәйгамбәр вә мәзһәб башлыгы эзләмәскә тиешлемез…

Һәр кешенең үз хезмәте вә хәләл кәсебе илә тапкан бер телем икмәге юк шәригатьләр чыгарып, фәлән кеше — кяфер, фәлән — фасикъ [26], син генә яхшы дип мактап яхшы булудан артыктыр.

5. Динле булып күренү — бик яхшы бер кәсеп ул… Бер кешене кяфер дип йөрү бик зур кабахәтлектер. Газиз иман капкасының ачкычы сезнең кулыңызга бирелмәмештер. Сез үзеңез теләгән кешеләрне иман капкасыннан кертеп, теләмәгәнне — чыгарып җибәрүгә нинди права таптыңыз? Юк, сездә бернинди дә права юк.

6. Наданлык сәбәпле көфергә төшү җиңел инде… Бер дә исеңез китмәсен: Мәккәи мөкәррәмәдәге кәгъбә янында гөнаһ кыйлу мөмкин булган шикелле, Киевтәге монастырь янында саваплы эш кыйлу мөмкиндер…

Хак Тәңренең каршысында килешмидер тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаҗ!..

Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә… Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй! Фахиш мәгънә! Менә шулар безнең фәхшиятсез, пакь мөселман түрләренә кереп утыралар…

Әйдә, дустлар, бер тибрәник, акны Тәңре яклар бит… Караны бер көн каралтып, акны бер көн аклар бит.

7. Мөхәммәд динен яклаучы!.. Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны, дин эшендә башчы иттек без аларны… Җитәр дин исеменнән кеше талау, җитәр шәригать исеменнән халыкны каралту, җитәр болганчык суда балык тоту! Батсын фанатиклар!

8. Җитми мыр-мыр хәтем — чын, саф Коръән кирәк… Телсез муллалар бер нәрсә әйтмәкче булалар, ләкин, аһ, наданлык, ирennәрен селкетәләр дә, бер нәрсә дә фәһемләнми.

9. Ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, … үзләре яхшы аңлап җитмәгән нәрсәне балаларга укытып, ислам балаларының гомерен ашаган хәлфәләр, … барлык һиммәтләрен [27], һәммә гайрәтләрен трахтирларда, мәйханәләрдә генә күрсәткән байлар… И явызлар!.. Динне хурладыңыз, мөселманлыктан көлдеңез! Галимнәрне танымадыңыз. Тугъры сөйләгәннәрне кыстыңыз, издеңез… Җавап биреңез!..

10. Җәза бирми халык һич тә гөнаһ эш, яшерен эшләргә… Җәзалау камчысын биргән гөнаһлы ул халыкка кем? Түгел, юк. Бирмәгән һичкем; Ходай — гадил [28], Ходай — хаким!

11. Ашау-эчү өчен күңелең борчылмасын. Үзеңне «байлардан ярлы» дип санама; тыр-тыр итеп бәлешләргә йөгермә… Бәлеш белән гыйлем бергә җыелмас, комсыз кеше үлгәнче тыелмас… Комсызлык — түбән, бик түбән сыйфат ул… Азыгыңны Алладан өмет ит…

Хәзрәтләр, хәттин узмагыз!

12. Мөэмин булсаң, чын мөэмин бул — намазыңны калдырма…

Бездә җомга көннәргә дә бер дә игътибар юк: ул көннең бәйрәмлеге бер дә күңелдән хис ителми; халкымыз, бүген җомга, бүген бәйрәм, дип, яңа киемнәр киеп, руслар якшәмбене олуглаган кеби олугламыйлар.

13. Мулла ахрысы фәрештә түгел, аның да остабикәсе бар, бала-чагасы бар, фатир түлисе бар — ни эшләсен, ачка үлсенме?..

Ну, болай булгач, мулла гаепleme? Әллә безнең милләт гаепleme? Әлбәттә, милләт гаепледер…

Бер мулла биш вакыт намазда, җомгаларда, гаетләрдә имам тора, никах, талак эшләрен карый, казыйлык итә, туганнарны, үлгәннәрне, никахланганнарны яза. Шул арада ук мәдрәсәгә кереп мөдәррис тә була… Зиратка да бара. Җә, бер кешегә бу

кадәр хезмәт бирелсен дә, ул кешегә ни өчен жалование алу дөрест булмасын?!

Әүвәл бер кешегә шулкадәр эш бирү дөрест түгел, инде бирелгәч, аңар жалование бирмичә, теләндереп йөртү дөрест түгел. Бер култыкка ике үгез башы сыймавы, бер көймәче ике көймәнең койрыгын тота алмаганы һәркемгә мәгълүм була торып, бер муллага әллә тагы 20 төрле эш биргәннәр. Шулай булгач, ул мулладан нинди укыту, нинди иҗтиһат, нинди хәер көтәргә кирәк?

Минем уемча, муллаларны жалованиеле ясарга кирәк — бер; һәм аның өстендәге йөкләрнең һәрберсен аерып, үзенең ияләренә тапшырырга, йөкләтергә кирәк — ике... һәм боларның һәрберсенә аерым-аерым жалованиеләр бирелсен...

Муллаларның берсе бигрәк тук, икенчесе бигрәк ач булуының һәм дөрес укыта алмауларының... һәммәсенә сәбәп жалованиесезлектер. Шуның өчен мин үз тарафымнан, муллалар жалованиесез хезмәткә көчләнмәсеннәр, дип әйтергә батырчылык итәмен.

14. Үзенә башка хатиб, вагыйзьләр дигәнемез дә, безнең хәзергә чаклы булган муллаларымыз төсле, мөнбәргә менеп, баласын тирбәтеп җоклатучы хатын шикелле, халык аңламаган тел илә көйләп, җырлап, халыкны гыргыр җоклатмасыннар, тик өч мәртәбә «әлхәмделиллаһ»ны гарәпчә әйтсәләр җитәр. Вагыйзьләр безнең үземезнең ана телемез илә безгә, динемезгә, дөньямызга кирәкле вәгазьләр сөйләсеннәр. Халыкның тамырлары буенча каннарын йөгертеп, күз яшьләрен чыгарып, әллә кай җирләрен чеметтереп-чеметтереп алсыннар. Мөнбәргә менгәч, фәлән мәкам берлә җырлау, төгән көй илә көйләү бик зур оятты. Иске муллаларга алай гавам халкын көйләп тирбәтеп җоклатканчы, бер дә кешесез сахрага чыгып, гарәп шигырьләре көйләсәләр, артыграк булыр иде...

Хатибның сүзләре дару хөкемендәдер. Даруны, шифа биргәч, ачы булса да эчәләр бит.

15. Халыкның җыелган җире мәҗлестә, милләт исемене бер-ике кәлимә булса да, халыкны гыйлемгә, сәнгатькә өндәсәләр, нинди яхшы булыр иде... Мөмкин кадәр дөнья, ахирәт өчен файдалы мәгърифәт хасил кыйлмак кирәк...

Кыскасы гына, милләтнең тәрәккыйсенә вә башка милләтләрнең аяклары астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә саваплы вә хәерле бер эштер... Һайдәңез, борадәрләр [29]!.. Галәме исламга нур сачик, нурланыйк, тырышыйк!.. Без... халыкны караңгыда калдырып адаштырырга кулымызда аз гына бер икътидар [30], тәнемездә җан бар вакытта аслан разый булмаячакбыз.

VIII. ГАИЛӘ ӨЧЕН ИҢ КИРӘГЕ — ТИГЕЗЛЕК

1. Өч кешедән дөньяда качып котылып булмый: берсе — кендек әбиседер ки, ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә дөньяга тартып чыгарыр. Икенчесе — җаучы карчыктыр. Ул сине, аласы кызыңны күрсәң дә, күрмәсәң дә, алырга теләсәң дә, теләмәсәң дә — өйләндерер. Өченчесе — мәзиндер. Ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә — җуар да күмәр.

2. ... теләмәсәң дә — өйләндерер... Юк, ул алай булмый шул... Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, — парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы...

Әгәр булса «сөю»... кочаклау куллар арганчы, үбү булса әгәр чут-чут, ирен һәм бит кабарганчы — гомер дә сөйгәнем юк һәм «сөям», дип әйтмәмен һич тә; сөюнең мәгънәсе, минчә, бигүк гали, бигүк нечкә.

3. Үзенә нәрсә лаек икәнен һәркем үзе белә... Мәхәббәт төрлечә... Мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче... Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам.

4. Өйләнү — түгел сөйләнү… Гаилә хакында минем фикерем коры гына: … син аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, шуның өстенә… килерең булса, һәркемгә өйләнү тиеш. Югыйсә, эчеңә сәнәк белән төрткәндә, бер тамчы кан чыкмаслык булса, ике күңелдә чын мәгънәсе белән булган мәхәббәт уты янмаса, гаилә өчен әллә нинди түбән кешеләргә мөрәҗәгать йә тәлинкә тотарга булса — Алла сакласын!

5. Тигез-тиңлеккә юл куймау бездә гадәт. Ярың тиң-пар булмаса, әлбәттә, һәлакәт, пар булу шарт, пар булу шарт, пар булу… Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә31 дөнья бәһа; ул болай бер кыз гына — каршында Мәҗнүн булмаса… Өйләнештә иң кирәге — тигезлек.

6. Күңелсез сүз сөйли бәгъзе гакыллылар хатын-кызга: фәкать бер ел күңелле, дип, календарь һәм хатын безгә… Хатын өстенә хатын алсаң… Җитмәгәнме бер хатын, өч-дүрт хатын асрау нигә?..

Хәзерге өйләнүчеләр… Күңелләр саф чагында шәп, матур кыз сайлыйлар анлар: «Булыр безнең хатын булса йөзе айдай», — диләр анлар. Әгәр басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса, убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

7. Адашкан кыз… Төшкән ул сатлык кызлар рәтенә… Суына төшкән кочагы. Шулай да ул типтерә, бетәсен сизеп тора; җылыйсы күз яшьләрен күз эчендә киптерә…

Уйнаш кыйлуы бик уңгай да, бала табуы бик читен, диләр… «Уйнаш»тагы*** яман күздән Ходай үзе сакласын.

8. Аерылу һәрвакыт начарлыкка илтәдер. Аерылмаңыз!.. Хөррият, ирек — барча кешеләргәдер; бай, фәкыйрь, галим, җаһил, ир вә хатын һәм милләт аерылмаенча, һәркемгә бертигездер.

IX. ТУГАН ТЕЛ. ДӨНЬЯГА ФИКЕРЕБЕЗ ЮЛ АЛСЫН

1. Мин Казанны тәхте пай [32] һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятымыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим.

2. Үз араларында төрекчә сөйләшеп маймылланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, «Госманлыез, әфәндем», дип йөрүче хиффәтләребез [33] дә аз булмады. Ләкин мондый комедияләр вакытында булды да, узды да китте… Без татарлар һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр — Истанбулда, без — монда.

3. Язучы… Каләме — милләткә файда, язганы — Хак көзгесе… Безнең милләткә кирәк… Каләм иясе булып чыгучыларымыз күбәйсен, солдатның өстенә дә шинель, астына да шинель, баш астына да шинель дигән шикелле, алай тартсак та, шул бер-ике мөхәррир, болай сузсак та, бер-ике язучыбыз гына булмасын. Мөхәррирләр гаскәрләр кебидер: сугышка чыкканда, запас гаскәрләребез булмаса, әсир булырмыз, хур булырмыз…

Боларның кемлеген яхшы белик без, боларның артуын Ходайдан телик без…

Әлхәмделиллаһ… Милләтнең яшь каһарманнары каләмгә сарылды… Каләм кулда була торып, … мәгълүмдер ки, курку берлән өркү хәрәм… Ничаклы изсә дөнья, ирке бар — куркытмыйдыр безне…

Илаһым, рәхмәтең белән шагыйрьнең бәйле телен чиш; дуслар һәм дошманнар хәленнән ул бераз хәбәр бирсен.

4. И каләм! Китсен газап, ит син безне шат; без дә синең аркаңда туры юлга басыйк аяк… Милләткә мәрхәмәт ит… Европаны күтәреп син югары күкләргә кадәр, ник төшердең безне — җиде кат җир астына кадәр? Милләтнең бу хәле

*** Г.Камалның «Уйнаш» комедиясенә ишарә.

хикмәт китабына теркәлгәнме?.. Чакырып яз укырга, уку кыйммәтен тәкъдир ит…

Яз караны «кара» дип һәм акны «ак», җөпне «җөп» дип һәм шулай ук такны «так». Һәр кеше күңелен генә күрмә, милләт авыруына бак!.. И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит.

5. Кеше ата берлек белән туган түгел, бәлки фикер һәм тоткан юлы белән кардәш була… Максуд җитәр: бара торгач — юл кыскарыр… Алгарыш һәм күтәрелеш юлларына атлап үтик… Алга адым сал, татар… Бари Тәгалә сезләрне… сәламәт кыйлсын… Тән урнашмагач, җан урнашмый. Җан урнашмагач, фикер урнашмый…

Фикерегезне язгыгыз да фикергә фикер ялгагыз… Тик якты булсын фикерегез; фикерегездер — фикеребез һәм фикеребездер — фикерегез… Олы фикерләр кузгалсын… Дөньяга фикеребез юл алсын. Чөнки фикерләр кайнаса, эшләр дә алга китәр, — бу мәгълүм булсын һәркемгә, — шушындый безнең фикер.

Борынгыдан бирле безнең фикеребез тоткын иде. Кем соң безне мескен итеп тоткында тоткан иде? Килде форсат кысан читлекләрне итәргә тар-мар, килде, иркен сулыш алып, вакытыбыз канат кагар.

Фикеребез торсын яңарып гел… Искермәсен, үзара җәнҗал-ызгыштан кыл кадәр ис кермәсен! Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен, истереп, милләтнең берләшү юлын кистермәсен!

6. Яшәсен әрбабе каләм [34]!.. Яшәсен туган тел!

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

X. ҮЗЕГЕЗ МИЛЛӘТКӘ НӘРСӘ ЭШЛӘДЕГЕЗ?

1. Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле, әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл вакытлы гына килгән бер авыру кеби…

Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик… Җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын.

2. Карендәшләр! Уйганаек, заман уйганмак заманыдыр… Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен… Як-ягымызны карап, дөньяның барышыннан хәбәрдар булалым. Башка милләт халкының барышыннан гыйбрәт алып, безләр дә алга таба аякларымызны атлап, һәр сәгать алга йөрмәгә иҗтиһат итик… Элек йоклап үткәргәнебезне уйлыйк та үкеник… Кыю һәм батыр рәвештә алга хәрәкәт итик…

Бушка узмасын һич безнең һәр ай, һәр ел, тәрәккый итеп тотыйк алга юл… Тырышыйк… Һәр көн үзгәрә заман… Тырышырга кирәк, карендәшләр! Уяныңыз да тартышыңыз. Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыңызны!.. Изге эштер тартышмаклык хокук өчен… Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!.. Теләсәк яшәргә, дәгъвабызны исбат итик, дәлилләр китереп… Киләчәктә бәхетләр көтә безне…

Элеккечә кайгы-хәсрәт, ачынуларга хәзер урын бармы?.. Җанлансын халык, бар моңын, барлык зарын өстән салып… Тор! Тартыш! Тиз бар, татар… Тор! Селкен! Кузгал, татар!..

Җитәр инде, җитәр инде, давайте, сызганыйк җиңне; … һич өмет юк җиңне сызганмай… Ачыйк иттифакъка [35] юл: ушбудыр иң тугъры юл; сыңар җиңнән ике кул чыгарыйк без…

Тотып милләт ливасын [36], юлга чыктык: «Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».

3. Бер теләктәге кешеләр, бер сүздә булып, мәйданга чыгып… Тырышып, күп акчалар тотып һәм төрле-төрле чаралар күреп, ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә!..

Татарда акча юк, байлык та юк, дип, юкны сөйлиләр… Татар акча тапмый түгел, таба… Тау кисәр эшлекле ул — тотынса, дөнья төзәтер… Алла мондыйларның санын арттырсын.

4. Тәрәккый дә итәмез, һәр нәрсәне көттерәмез дә…

Безнең татарларда, иң әүвәл мәртәбә әйткәндә, һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер. Алар, иң әүвәл чыкканда, ысулы җәдит берлә укуга да каршы тордылар. Кара тактаның эченнән «тавык аягы» да эзләп маташтылар. Бара торгач, белделәр ки, кара тактаның эчендә «тавык аягы» түгел, «чебеш аягы» да юк, имеш!..

Өч яшьлек балага да үзенең сәламәтләнүе өчен дару эчерсәң яки: тышка яланаяк, яланбаш чыкма, дисәң, билгеле, каршы торадыр. Шуның шикелле, татарларга да: болай итсәңез, сәламәт булырсыз, тегеләй итсәңез, үзеңез өчен яхшы булыр, дисәң: «Э… э… кирәкми, э… э…», — дип киреләнәләр…

Дөрест… «Яңа» дип һәр нәрсәгә мөкиббән кителмәскә… кирәк… Вәләкин… Нигә кирәк искелек, кирелек?.. Кирелек, наданлык гаскәрен җиңеп, сындырып ташлыйк… Якты көннәр алда… Хуҗа Насретдин шикелле, атның артына карап атланмыйк.

5. Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр… И кардәшләр, кул тотышып, алга барыйк, башка милләтләрнең хәлен карап карыйк; мәдәният мәйданында урын алыйк, егыла-тора, алга таба атлыйк!..

Кем җигә безгә тәдәнни [37] арбасы?.. Безгә аяк чалырга маташсалар, янә безне алар белән кычкырышу кебек түбәнлеккә сөйрәсәләр, без аларны бергәләшеп юлдан алып ташлап, яки «Безнең юл беләнме, әллә түгелме?» дигән сорау куеп, ничек тә аларны ераклаштырыйк…

Без мөһаҗим улмай, анчак мөдафигъ улдыкымыз җәһәттән хәкыйкан бәхтиярез.****

6. Рус җирендә без әсәрле, эзле без, тарихында бер дә тапсыз көзге без. Рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып. Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып, без шаярыштык, вакытлар алмашып. Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез. Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук!

7. Без — руслар белән татарлар — һәрвакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз… Бик яхшы бит!.. Дуслыкта берлек, тигезлек, тиңлек кирәклеген әйтмәсәм дә, беләсез инде.

8. Һәр милләтләр максудларын хасил итә… Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл; бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (Гыйззе вә Җәл). Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт, хөр Русия!

9. Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга [38] түзмәккә!..

Һәр заман хакны сөючеләр сездәй каһәрләнгән булыр… Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдан белик, мескин үлеп

**** Без һөҗүм итүче (сугышны башлаучы) булмыйча, тик каршы торып, аны кире кагучы булуыбыз белән чын бәхетлебез.

аңлатмагач?!. Мәмнүн булсын рухлары...

Күрсәтә һәрбер җаһил милләткә золым вә җәбрене, таптыйлар пычрак аяклар берлә милләт садрене [39]... Искеләр белми һәнүз милләт дигән сүз кадрене... Халык ... хөрриятнең җаннар корбан итәрлек дәрәҗәдә мөкатдәс нәрсә икәнен аңлап җитмәгән. Аңласа да, бик азы аңлаган... Милләтемез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, «улбу»лары гына өсткә калка шул... «Алла бирмәгәнне мулла бирмәс» мәкале бик тугъры сүздер...

Сезнең болай каршы торуыңызны бик зур гөнаһ дип беләмез. Бу эшләреңезне ташлап, тәүбә кыйлмак, кайтмак кирәк... Сезнең урыныңызга үзеңез бар заманда һичкем күз җибәрми. Без исәк, һәр каюмыз, Аллага шөкер, төрле-төрле кәсепләр илә шөгыльләнеп йөримез...

Кайчанга чаклы татар... бер-берсенә ук атар?

10. Бар мөселман булалса иде бер гәүдә...

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр... Бер-беребездән качмыйк... Барчабыз бер юлдан тырышып атлыйк... Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк, тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк... Килер бер көн: милләтең сиңа шәфкатен күрсәтер... Фәкать сабыр кирәк.

XI. АЕРЫЛЫШУ СОҢЫНДА

1. Берегез укыгыз да, берегез тыңлагыз... Кап-кара кол белми хөррият дигән сүз кадрене... Сөальләр җавапсыз калмасын... Сез үзегез милләткә нәрсә эшләдеңез?.. Әйдә, дустлар... Тәкрар әйтәмез... Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб, гүзәл эзне!

2. Эшем һәм ниятем изге иде, ләкин максудыма җиттеме — анысы минем эш түгел... Актык сүз буларак шуны әйтәм... Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен; мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен!.. Алла ни бирер... Мин догада...

Яшәсен милләт!

СҮЗЛЕКЧӘ

1. Җәсарәт — батырлык, кыюлык.
2. Парлак сурәттә муаффәкъ булу — якты зур уңышка ирешү.
3. Заһир — ачык.
4. Тәслим фитърәтендә — кемгә дә булса тапшырылырга тиешле хәлдә.
5. Нәсрани — христиан динендәге кеше.
6. Нәҗат — котылу.
7. Голүм — гыйлемнәр.
8. Гатәләт — ялкаулык.
9. Асла — һич тә.
10. Ләфзы — сүзе.
11. Мәнафигъ — мәнфәгать, интерес.
12. Мөрәбби, мөрәббия — тәрбияче ир-ат, тәрбияче хатын-кыз.
13. Сәляхият — сәләтлелек, талант, булдыклылык.
14. Җәһаләт — наданлык.
15. Анчак — бары тик.
16. Назик вә ләтыйф — нечкә һәм гүзәл.
17. Исхак әйләйә — төзәтсен дигән мәгънәдә.
18. Фәхерле — мактанычлы.
19. Зате гали — бөек зат.
20. Мәгъмур — төзек.
21. Мөрәүвәтле — үз-үзен кызганмаучы.
22. Фәркъ итмичә — аермыйча.
23. Кальбән — күңеленнән.
24. Мәлганәт — түбәнлек, явызлык.
25. Әүля — дөресрәк.
26. Фасикъ — бозык.
27. Һиммәт — юмартлык.
28. Гадил — турылыклы.
29. Борадәр — туган.
30. Икътидар — сәләт, көч-куәт.
31. Мәхбүбә — сөелгән хатын-кыз.
32. Тәхте пай — башкала.
33. Хиффәт — тиле, юләр.
34. Әрбабе каләм — каләм ияләре.
35. Иттифакъ — берләшү.
36. Лива — байрак.
37. Тәдәнни — артка өстерәү.
38. Зорлык — авырлык.
39. Садр (садыр) — күкрәк. ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара

THE ENCYCLOPEDIA OF TUKAY

The rubric is led by professor Zufar Ramiev

МАЙМЫЛ ХАФИЗ (Мөхәммәтҗан Хафиз, Мөхәммәтҗан Әхмәрев; шәхси язмышы мәгълүм түгел), Казанның иске фикерле сәүдәгәре, әчтәлеге белән урам әдәбиятына караган китапчыклар авторы. Печән базары чатындагы ларёгында (шкафында) вак-төяк товар белән сату иткән бу кешенең исеме Тукайның башлыча публицистик әсәрләрендә очрый. М.Әхмәрев беренче мәртәбә Тукайның «Гаҗәп талантлар» исемле парчасында («Ялт-йолт», 1910. — №1) шул чорның көлкегә лаек башка затлары арасында телгә алына, аның язганнары җәдидләргә каршы юнәлтелгәнен, «авыл никрутлары да ул кадәр начар чыгара алмаслык җырулар язарга фәүкыльгадә истигъдад»лы (гадәттән тыш сәләтле, булдыклы) булуы әйтелә. Ул бу елларда «Ук», «Инә», «Чукмар»ише урам әдәбияты — «җырулар» язып байлар акчасына бастырып бушлай тарата (Р.Гайнанов искәрмәсе). Журналның 1912 елгы 31 нче (1 гыйнвар) санындагы «Былтырның хисабы»нда Тукай Маймыл Хафизга былтыр (ягъни 1911 елда) «пәри-җен иялəште. Чөнки ул бер үк вакытны өендә «Сөбател-гаҗизин» дә укый, шунда ук театр сәхнәсендә дә күренә. Печән базары мәчетенең мөселман җеннәре күтәреп йөртәләр, күрәсең», — дип яза. Шагыйрь бу урында Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендә М.Әхмәревнең «ысул кадимчеләр башлыгы» Шкафчы (Әхмәтҗан) образында гәүдәләнешен истә тота. Комедия 1911 елның 11 ноябрендә Казанда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куелган, һәм Г.Кариев тудырган Шкафчының реаль тормышта кем булуын тамашачылар бик тиз «танып» алганнар. Спектакльнең зур уңыш казануына китергән сәбәпләрнең берсе шул. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасында сурәтләнгән, гайбәт оясы, иске фикерле сәүдәгәрләр җыела торган «Көфер почмагы»ның («Көфер чаты»ның) көндәлек тормышында зур роль уйнаган кеше дә Мөхәммәтҗан Әхмәрев була. Мәхмүт Галәүнең «Г.Тукай турындагы истәлекләрдән бер кисәк» исемле язмасында да Мөхәммәтҗан Хафиз искә алына. Тукай белән Балык базарындагы (хәзерге Тукай мәйданы) панорамада Неаполь һәм Венеция рәсемнәрен караганнан соң, М.Галәү әлеге сурәтләргә үз мөнәсәбәтен белдергәндә, Тукай: «...әллә шул рәсемне «Неаполь»гә китереп панорамада күрсәтсәң, синең төсле үк «Печән базары» мәчете тирәсендә нинди бәхетле кешеләр яши икән?» — дип сораучылар табылыр», — ди. М.Галәү, ризасызлыгын белдереп: «...Мөхәммәтҗан Хафизны анда илтсәң, читлеккә ябып «зверинец»та күрсәтерләр бит», — дигән җавабына, Тукай тапкырлык белән: «...һәр җирнең үз «Печән базары», һәр «Печән базары»ның үз Мөхәммәтҗаннары була», — ди. Тукайның киң карашы, тормышны, дөньяны тирән аңлавы, фикерләве, кешенең яшәү рәвеше, көнкүреше, аның кайда гына яшәвенә карамастан, һич үзгәрмәвен, кеше нинди генә җәмгыятьтә яшәсә дә, кеше кеше булып калачагын ассызыклый.

Зөфәр Мөхәммәтшин, *филология фәннәре кандидаты*

Zufar Muhamatshin, *Candidate of Philological Sciences* ■

Әдәбият

Тукай Г. Әсәрләр. 6 томда: Т.4. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1985. — Б.107, 230; Тукай турында истәлекләр. — Казан:Татар.кит. нәшр., 1986. — Б.116.

ТУКАЙ ДӘРЕСЛЕГЕ

Г.Тукай төзегән җыентыкларның милли әдәбият үсешендәге әһәмияте

THE TEXTBOOK OF TUKAY
(the importance of compilations that was created by Tukay in development of national literature)

Габдулла Тукайның үзе исән чакта китап булып басылып чыккан утыз өч җыентыгы билгеле. Шуларның утыз бере үз әсәрләрен туплаган, икесе Г.Тукай тарафыннан төзелгән җыентыклар. «Җырлар дәфтәре» җыентыгы исә кульязма хәлендә саклана.

Габдулла Тукай төзегән «Җырлар дәфтәре» белән «Халык моңнары» җыентыкларында халык җырлары, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»ндә төрле әдипләрнең әсәрләре җыйналган. Шагыйрь үзе язганча, җыентыкларга әсәрләр Тукайның үз зәвыгына туры китереп сайланган. Алардан Тукай рухы, Тукай стиле, Тукай кулы сизелеп тора. Шул яклары белән алар әһәмиятле дә.

Уральскида яшәгәндә, Тукай «Мотыйгия» мәдрәсәсенең рус классында укый. Анда ул рус әдәбияты белән якыннан таныша, А.Кольцов, А.Пушкин, М.Лермонтовларның шигырьләрен укый. Аларның халык иҗаты нигезендә язылган әкиятләрен тыңлау, Тукайның халык әдәбияты белән кызыксынуын тагын да арттырып җибәрә. Ул үзе дә зур кызыксыну белән халык җырларын җыя, халык көйләрен өйрәнә башлый.

«Җырлар дәфтәре» — шул мәдрәсәдә укыган елларда җыелган җырлар тупланмасы. Әлеге дәфтәр 1946 елда табыла һәм бүген Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Мирасханәсендә [9] саклана. Зәңгәр тышлы, кечкенә форматтагы мәктәп дәфтәренең тышына Тукайның үз кулы белән «Тетрадь для списывания ученика 1-го класса А.М.Тукаева» дип язылган. Эчке өлешенең беренче битендә җырларның эчтәлеге төзелгән. Барлыгы егерме



сигез җыр күрсәтелгән. Алга таба ят кул белән җырларның текстлары китерелә. Унҗиденче сан астында торган «Хан кызы» көе»нең тексты дәфтәрдә юк. Тышкы битендә «Контора 1-го товарищества Бр. Шараф и Ко, Казань» дигән язулы мөһер һәм мөһер уртасында «22 января 1911 г.» датасы да бар. Димәк, Тукай әлеге җырлар дәфтәрен бастырып чыгарырга уйлаган булса кирәк, әмма, ни сәбәпледер, җыентык кульязма хәлендә калган. Мөхәммәт Гайнуллин әлеге дәфтәрнең әһәмиятен искәртеп болай ди: «Бу материаллар Тукайның мәдрәсәдә вакытларындагы иҗади хезмәтләрен күрсәтүче документлар булу белән

бергә, аларда тупланган бай гына халык иҗаты үрнәкләре татар фольклорын һәм этнографиясен өйрәнү өчен гаять әһәмиятле яңа материаллар булып торалар» [1].

Г.Тукай — татар халык әдәбиятының поэтик иҗатын билгеле бер системага салучы, фәнни принципларга таянып өйрәнүче дә. 1910 елда шагыйрьнең «Халык моңнары» исемле китабы басылып чыга. Биредә җырлар берничә төркемгә аерып урнаштырылган: 1) халык моңнары; 2) озын көйләргә җырлана торган җырлар; 3) пешми калган җырлардан үрнәкләр; 4) ярты гыналар; 5) рестаннар җыры. Шунда ук «Сак-Сок» бәетенең бер вариантын да кертә. Әлеге җыентыкның төзүчесен ул «Шүрәле» дип күрсәтә. Тукай — Каюм Насыйриның халык авыз иҗатын җыю, өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеген дәвам иттерүче дисәк тә, ялгыш булмас. Аңлаешлы әдәби тел тудыруның чыганагы итеп, беренче чиратта, халык иҗатын, халык телен ала. «Чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җырларыннан гына табып була», — ди ул [7].

Тукайның иҗат мирасы фольклор белән тыгыз бәйләнгән: күп әсәрләренең нигезендә халык әдәбияты ята. Ул халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, туплау, аларны өйрәнү эшенең зарурияten аңлап, язма әдәбиятның башында халык иҗаты торганын искәртә: «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга бер дә шөбһәсез нигез булачактыр, — ди ул [8].

Тукай төзегән өченче җыентык — «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле дәреслек — хрестоматия.

XX йөз башы — татар халкының иҗтимагый-сәяси тормышында үзгәрешләр чоры. Бу чорда мәктәп-мәдрәсәләр алдына да ана телендә яңа уку әсбаплары булдыру мәсьәләсе килеп баса. Укучыны реаль дөнья белән таныштырырлык, актив фикер йөртүгә, тормышка хәзерләрлек дәреслекләр кирәк булуы үзен сиздерә. Әлеге юнәлештә бик көтелгән хезмәт 1910 елда Габдулла Тукай тарафыннан төзелгән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» басылып чыга.

Баланың яшь үзенчәлегенә туры килерлек әдәбият сайлау — педагогика фәненең иң авыр мәсьәләләреннән берсе. Түбән сыйныфларда алынган рухи азык баланың алга таба үсешендә һәм тормышта үз юлын сайлауда мөһим роль уйный. Әдәбиятның беренче максаты да — әдәби әсәрләр нигезендә укучыда кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү. Иң мөһиме — бу сыйфатлар көчләп түгел, ә табигый рәвештә үзләреннән-үзләре туарга тиеш. Шул максаттан Г.Тукай, балаларның яшь үзенчәлекләрен күздә тотып, төрле язучыларның әсәрләреннән сайлап алып төзелгән уку китабы тәкъдим итә.

Хрестоматияләр тарихына күз салсак, аның беренче үрнәкләре XIX йөзнең урталарына карый. Уку-укыту ихтыяҗларын күздә тотып, Г.Тукайга кадәр үк бу өлкәгә сукмак салучы галимнәребез була.

Татар телендә беренче хрестоматияне төзүче — М.Иванов. Аның «Татарская хрестоматия» хезмәте 1842 елда Казан университеты матбагасында басыла.

1859 елда Казан университеты матбагасында С.Кукляшев төзегән «Диване хикәяте татар» басылып чыга. Китапның 104 битле беренче бүлеге татарча-русча сүзлектән гыйбарәт, икенче бүлегендә халык телендә йөргән хикәяләр, мәкальләр, җырлар бирелгән.

XIX йөзнең II яртысында хрестоматияләр төзү активлаша. К.Насыйриның «Буш вакыт» (1868), В.В.Радловның «Белек» (1872), Г.Рахманколыйның «Тәнбиһес-сыйбиян» («Сабыйларның зиһененә салу», 1898), Х.Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» (1890) һәм К.Бикколовның 1904 елда басылган «Нәмүнәи тәрәккый» («Алга бару өчен юл күрсәткеч»)

хезмәтләре. Әлеге хрестоматияләр барысы да дидактик характерда. Әдәбиятны сайлаганда укучыларның яшь үзенчәлекләрен истә тоту мөһим нәрсә булса да, аларда әсәрләрне сайлаганда кайсы яшьтәге балалар өчен билгеләнгән булуы әйтелмәгән. Хрестоматиягә кертелгән әсәрләрнең авторлары да куелмаган.

Г.Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» — «Рөшди сыйныфларда укытыр өчен» язылган яңа тип хрестоматия үрнәге [3].

Әлеге дәреслек-хрестоматиянең кереш сүзендә Г.Тукай русларның «Живое слово» хезмәтенә таянуы турында яза. Ул А.Я.Острогорскийның 1907 елда Петербургта басылган «Живое слово» исемле рус әдәбиятыннан мәктәп хрестоматиясен үзенә үрнәк итеп алган. Г.Тукайның моңа кадәр 1909 елда басылган үз әсәрләреннән генә торган беренче җыентыгы — «Яңа кыйраәт» дәреслеге дә рус мәктәпләре тәҗрибәсеннән, К.Ушинский, Л.Толстой дәреслекләреннән файдаланып төзелгәнлеге билгеле. Г.Тукай XIX гасыр ахырында ук дөнья күргән, югарыда аталган хрестоматияләрнең берсен дә искә алмый. Әдип моңа кадәр милли әдәбият җитәрлек дәрәҗәдә юк дип санап, күбрәк халык әдәбиятына, тәрҗемәләргә таянган кешеләргә: «Әйе, бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият» [6], — дип ышанып җавап бирә. Үзенең дәреслеге белән моны раслый да. Алдагы хрестоматияләрдән аермалы буларак, әлеге дәреслектә укучы шул чорда иҗат иткән егерме алты татар язучысының исеме белән очраша, татар әдәбиятының төрле жанрларын иңләгән проза, поэзия, рус әдәбиятыннан тәрҗемә әсәрләре, тарихи язмалар белән якыннан таныша.

Ю.Туишев фикеренчә, Г.Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» «татар культурасы тарихында әдәбияттан беренче уку китабы иде... Тукай төзегән хрестоматия Бөек Октябрь революциясенә кадәр дә һәм революциядән соңгы беренче елларда да татар әдәбияты буенча бердәнбер дәреслек булып калды»[5]. Ф.Исламов та нәкъ шул ук фикердә [4]. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» мәктәпләр һәм мәдрәсәләрдә татар әдәбияты укытыла башлау, югары сыйныфлар өчен әдәбият теориясе буенча дәреслекләр төзелү, әдәбият укыту методикасын эшләү өчен этәргеч, нигез булды» [2], — дип бәяли Д.Заһидуллина, хезмәтнең кыйммәтен күрсәтеп.

Тукай төзегән «Җырлар дәфтәре» белән «Халык моңнары» җыентыгының әһәмияте халыкның тарихын, яшәешен, гореф-гадәтләрен чагылдырган һәм халык телендә иҗат иткән шагыйрьләр, язучылар үстерүдә булса, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең әһәмияте исә яңача укыту методикасын барлыкка китерүдә.

Әдәбият:

1. Гайнуллин М. Тукай һәм халык иҗаты // Г.Тукай. Халык әдәбияты. Казан: Татгосиздат, 1946. — Б.4.
2. Заһидуллина Д. Тукайның методик-педагогик карашлары // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте (Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары). Казан, 1997. — Б.288.
3. Ибраһимова Ф. Фәнни гомерем мизгелләре. Казан: Тат.кит.нәшр., 2012. — Б.61.
4. Исламов Ф. Тукайның педагогик эшчәнлеге һәм педагогик карашлары // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте (Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары). Казан, 1997. — Б.278.
5. Туишев Ю. Г.Тукайның кайбер педагогик карашлары // Совет мәктәбе. — 1961. — № 4. — Б.9.
6. Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. — Казан: Мәгариф, 1910.
7. Тукай Г. Халык әдәбияты. Казан: Татгосиздат, 1946. — Б.40.
8. Шунда ук, Б.33.
9. Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Музыкаль һәм язма мирас үзәге: 9 фонд, 1 тасв., 496 эш.

Эльмера Галимҗанова,
филология фәннәре кандидаты,
Фәния Фәйзуллина

Elmera Galimzyanova,
Candidate of Philological Sciences,
Faniya Fayzullina ■

«ӘЛИФБА» МУЗЕЕ... БЕРДӘНБЕР!

THE UNIC MUSEUM OF «ALPHABET»

Әлеге музей үзебезнең Татарстанда – Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә урнашкан. Биредә 56 телдә 357 данә «Әлифба» саклана.

Төрки халыкларның «Әлифба»лары

ӘДӘБИ МИРАС

ТУКАЙ ОБРАЗЫН ИҖАТ ИТКӘНДӘ

Габдулла Шамуков (1909-1981)

WHEN THE FIGURE OF TUKAY WAS BEING CREATED

Әхмәт Фәйзи әсәре буенча куелган «Тукай» спектаклендә Г.Шамуков Тукай ролен башкара. 1939 ел

1939 елның көзендә Башкорт дәүләт академия театрында Әхмәт Фәйзинең «Тукай» исемле трагедиясен куярга булдылар. Тукай ролен миңа тапшырдылар. Репетицияләр башланды.

Әсәр мавыктыргыч, җылы итеп язылган. Бөтен күңелемне биләп алды. Тукай — минем иң яраткан шагыйрем. Барлык шигырьләрен диярлек яттан беләм. Гомер юлы белән дә таныш. Шагыйрьнең трагедиядә сурәтләнгән эчке кичерешләрен дә тоям шикелле. Баштагы репетицияләрдә шактый кыю булдым. Дәртләнеп, илһамланып, сурәтләнгән вакыйгаларның сулышын тоеп хәрәкәт иттем. Ләкин бу хәл озакка бармады. Кыюлыгым каядыр югалды, хыялым богауланды, күңелемә шик микробы кереп урнашты, борчыла башладым.

Шагыйрьләрнең әсәрләрен укып, тамашачы каршында уңыш казану бер эш. Әмма сәхнәдә шагыйрьнең үзен җанландырып күрсәтү — бөтенләй башка нәрсә. Габдулла Тукай — халыкның иң сөекле шагыйре. Халкыбызның күңелендә аның мөкатдәс сурәте яши, гаҗәеп сөйкемле, бөек һәм изге ул сурәт. Сәхнәдә гәүдәләндереләчәк Тукай өчен материал — мин үзем ләбаса, гади бер актёр. Минем йөзем, күзләрем, тавышым, буем-сыным, килеш-килбәтем, кыяфәтем. Мин бит җирдә яшәүче гади кешеләрнең берсе. Габдулла Тукай исә гади кеше түгел — «көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез» ич ул. Мин, сәхнәгә Тукай булып чыгып, халык хыялындагы нурлы сурәтне бозармын, халкыбызның хисләрен рәнҗетермен, дигән уйлар белән борчыла башладым. Бу борчылу авыр бер чиргә әйләнеп китте. Мин хәтта актёрлык кабилиятемә дә шикләнеп карый башладым. Сәхнәгә килүем дә, бәлки, саташу гына булгандыр, тугыз ел эчендә ирешкән уңышларым да чын иҗади уңыш түгелдер? Шул гомер саташып йөрдем микәнни? Хәзер чигенеп тә булмый, ичмасам!

Башка сәнгатьтәге иҗатчыларның хәле әйбәтрәк — алар бәйсез. Рәссамнар, әдипләр эшләрен беркемгә күрсәтмичә эшли алалар. Ялыксалар яки эшләреннән канәгатьләнмәсәләр, ташлап тора алалар. Аларны вакыт белән дә чикләмиләр. Эшләре уңышлы чыкса — күрсәтәләр, уңышсыз булса, шул килеш кала бирә, аны беркем дә белми. Ә безнең хәл башка. Безнең иҗат календарь кысасына кертелә. Аны бар да белә. Театрның цехлары эшли — декорация ясыйлар, киемнәр тегәләр һ.б. Спектакльнең уңышын хәл итә торган төп образ барып чыкмаса, спектакль кабул ителми. Димәк, син барлык цехларның, бөтен коллективның хезмәтен җилгә очырган буласың.

Репетициядән репетициягә ышанычым җимерелә барды. Моны коллектив күреп тора. Баштагы репетицияләрдә рухланып эшләгән режиссёр Вәли Галимовның да сөмсере коелды — кашлары җимерелде. Кичерешләрен күрсәтмәскә тырышса да, миннән яшерә алмый.

Шундый авыр рухи кризис кичергән чагымда, миңа Тукайны күреп белгән «Сәйяр» труппасының күренекле артисткасы, соңгы елларда Башкорт театрында эшләгән Фәхерниса апа Сәмитова очрап, болай диде: «Тукайны мин беләм. «Тукай» куела дип

ишеткәч, шагыйрь ролен, мөгаен, сиңа бирерләр дип уйлаган идем, шулай булып чыккан да. Бик әйбәт. Ләкин син уйнарга тырышма. Сәхнәдә үзең булып, табигый килеш хәрәкәт итсәң, шул җитте. Гримны да җиңелчә генә салырсың, чөнки син болай да Тукайга охшыйсың», — диде.

Терелеп киттем мин, күңелем яктырып, балкып киткәндәй булды. Фәхерниса ападан аерыласым килми. Ул миңа Тукай турында кызыклы истәлекләр сөйләде. Аның кайбер гадәтләрен, шаянлыгын, тәэсирләнүчәнлеген сөйләде. Үзе күреп белгән сөекле шагыйрьне күз алдына китереп, дәртләнеп сурәтләде ул. Нинди бәхет бу минем өчен! Нинди мавыктыргыч җанлы күренешләр! Әдәбият мәйданына чыккан истәлекләрдә боларның берсе дә юк лабаса! Фәхерниса апаның сүзләре шагыйрь образын ачык итеп күрергә, тоярга ярдәм итте. Шул очрашудан соң репетицияләр күтәренкелек белән үтә башлады. Режиссёр да җанланды.

Берничә көннән Фәхерниса апа дөнья куйды. Аны җирләгән көнне репетиция булмады. Икенче көнне эшкә килдек. Мин тагын сүрелдем, тагын әлеге авыр газапны кичерә башладым. Әйтерсең лә Фәхерниса апа белән бергә минем ышанычым да җиргә күмелде. Кешеләрдән качам — начар дип әйтерләр дә, өметем бөтенләй өзелер дип куркам.

Һәм менә соңгы хәлиткеч репетиция. Шагыйрьләр, әдипләр, рәссамнар, укытучылар килгән. Мин киендем, грим салдым — анысын алдан өйрәнгән идем, әйбәт чыкты. Ләкин җаным буш. Үз-үземә болай дим: «Образ тудырып булмады инде, ичмасам, кулымнан килгән кадәресен намус белән үтим — автор язган сүзләрне-фикерләрне тамашачыга ачык итеп җиткерим», — дим.

Репетиция бетте — пәрдә төште. Мине театр мәктәбе укучылары, үземнең шәкертләрем сырып алды, күзләрендә яшь. Драматург Сәгыйть Мифтахов килеп кочаклады, аның да күзләре яшьле. Мин аптырыйм — нигә болай соң бу? Күңелем туңган, берни дә сизмим, хисләрем шулкадәр тупасланды микәнни?

Спектакль кабул ителеп, премьера афишалары ябыштырылгач, Әхмәт Фәйзидән телеграмма: «Спектакльне үзем карамыйча, халыкка чыгарырга рөхсәтем юк».

Мәскәүдән автор килеп төште. Кич белән театрга җыйналдык. Әхмәт Фәйзи, грим салмыйча, репетиция рәвешендә генә уйнап күрсәтүне сорады… Соңыннан: «Төп рольләрдәге актёрлар үз урыннарында — мин канәгать», — диде.

Шулай итеп, тамашачы каршына чыктык. Спектакль зур уңышлар белән барды. Бу уңыш бөтен шәһәр халкын аякка бастырды. Һәр спектакль көнне бәйрәмчә киенгән картлар, яшьләр театрга агыла. Тамаша залы шыгрым тулы. Республика газеталарында чыккан рецензияләрдә спектакльне театрның зур казанышы дип билгеләделәр. Якын дусларым, танышларым, хәтта бөтенләй таныш булмаган кешеләр, урамда туктатып, иҗади уңыш белән котлыйлар, рәхмәт әйтәләр, телефоннан шалтыраталар. Кыскасы, фактлар иҗади триумф турында сөйлиләр. Ләкин шунысы гаҗәп: үзем бер спектакльдә дә эчке канәгатьләнү сизмәдем. Бу парадоксаль хәлнең сәбәбен мин бик озак эзләдем. Соңга таба, үземчә, шундый бер нәтиҗә ясадым: бу эчке канәгатьләнмәүнең сәбәбе — бөек Тукай турындагы идеалым белән үзем иҗат иткән образ арасында нindидер аерма сизүем аркасында булса кирәк. ■

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / АПРЕЛЬ

THE CHRONICLE «OUR HERITAGE»/ APRIL

95 ел элек (1919)

● 4 апрельдә танылган трагик артист Мохтар Мутин бенефисына азәрбайҗан революционеры һәм язучысы Нариман Наримановның «Надыйршаһ» трагедиясе куелды. Режиссёры — Кәрим Тинчурин.

● 16 апрельдә Казандагы укучы яшьләрнең «Берек» оешмасы Габдулла Тукайны искә алу кичәсе оештырды.

90 ел элек (1924)

● «Эшче» газетасында Һади Такташның «Казан» дип аталган шигыре басылды.

85 ел элек (1929)

● 12 апрельдә Татар дәүләт академия театры Фатих Сәйфи-Казанлының «Зәкуан мулла шәҗәрәсе» исемле пьесасын сәхнәләштерде.

● 20 апрельдә Татар дәүләт академия театрында Галиәсгар Камалның 30 еллык әдәби хезмәт бәйрәменә багышланган кичә уздырылды. Юбилярның «Безнең шәһәрнең серләре» һәм «Беренче театр» пьесаларыннан аерым пәрдәләр уйналды.

75 ел элек (1939)

● «Совет әдәбияты» журналының 3-4 санында Муса Җәлилнең опера өчен «Алтынчәч» исемле либреттосы дөнья күрде.

● 16 апрельдә «Яшь сталинчы» газетасында бөек француз язучысы Ромен Ролланның танылган татар сынчысы Ахун Садрига язган хаты игълан ителде. Хаттан бер өзек: «Сез ясаган бюст искиткеч, аңарда энергия күренә. Бу энергияне миңа геройларым бирәләр».

● 24 апрельдә Габдулла Тукай исемендәге кабинетта Татарстан Совет язучылары Союзы идарәсенең отчёт-сайлау җыелышы булды. Яңа идарәнең җаваплы секретаре итеп Муса Җәлил сайланды.

70 ел элек (1944)

● 27 апрельдә Татар дәүләт академия театрында Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» пьесасы буенча куелган спектакль премьерасы булды. Режиссёры — Хөсәен Уразиков. Миңлекамал ролен Галия Булатова башкарды.

65 ел элек (1949)

● «Совет әдәбияты» журналында Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романы, Татарстан китап нәшриятында Нәкый Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» драмасы, Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы басылып чыкты.

60 ел элек (1954)

● «Совет әдәбияты» журналында азәрбайҗан шагыйре Самәд Вургунның «Муса Җәлилгә» дигән шигыре чыкты.

55 ел элек (1959)

● Әхмәт Ерикәйнең уйгыр телендә шигырьләр мәҗмугасы дөнья күрде. Ул «Дуслык вә мәхәббәт тугрысында» дип атала.

45 ел элек (1969)

● «Казан утлары» журналында Фатих Хөснинең «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повесте басылды.

● 26 апрельдә «Онытылмас еллар» трилогиясе өчен Ибраһим Гази Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. ■

ФӘННИ МИРАС

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

DICTIONARY OF THE NATION

Adler Timergalin

АГАЧ ЙОЛДЫЗ / ЙЫГАЧ ЙОЛДЫЗ бор.төр. — Юпитер (планетасы). Чыганакларда *Оңай / Оңгай, Каракош (*борынгы төркиләрдә), *Мөштәри (Әлмөштәри), Бирҗийс, Ормызт* атамалары очрый.

АДӘМ УЛЫ — Инҗилнең татарчага тәрҗемәсендә «Сын Человеческий» мәгънәсендә алынган. Семит телендә — *Бар-наша.* Борынгы төрки чыганакларда — *йалңук оглы (огланы)* дигән сүз бар (адәм баласы). Шәехзадә Бабич үзенең «Газазил» дигән поэмасында *«инсан углы»* сүзен куллана.

Христиан теологлары фикеренчә, «Адәм улы» дигән атамада Иисус Христос, ягъни бер үк вакытта Аллаһ Улы да булган шәхес күздә тотыла. // *Чынлап әйтәм сезгә: сез Израиль калаларын йөреп бетерә алмассыз, әмма Адәм Улы килер.* (Матфей, 10:23).

Чыганакларга карасак, күп кенә борынгы күрәзәчеләрнең һәм фикер ияләренең (Энох, Моисей, Барух, Ездра) җир йөзенә нindидер бер куәтле каһарман килеп, адәмнәрне коткарачагы турында әйткән сүзләренә тап булабыз. Ләкин аларның берсе дә бу адәм улының тәрегә кадакланачагы һәм күккә ашачагы, аннары Ахыргы Көндә кабат кайтачагы турында сөйләми. «Аллаһ улы»ның бер үк вакытта «адәм баласы» булуы да мөмкин хәл.

Дини текстларны борынгы телләр ярдәмендә җентекләп тикшергән профессор Габделәхәд Дауд (Давид Бенджамен Кельдани) әлеге атамада фәкать Мөхәммәд Пәйгамбәр турында гына сүз барырга мөмкин дип исәпли.

Иоанн Инҗилендәге (Иоанн, 16:7.): «Әмма Мин сезгә чынны әйтәмен, Минем баруым сезнең өчен яхшырак, Мин бармасам, сезгә Тынычландыручы килмәс шул; әгәр барсам, Аны сезгә җибәрермен» дигән сүзләр дә Гайсә Пәйгамбәрдән соң дөньяга киләчәк Мөхәммәд Пәйгамбәргә нисбәт ителергә тиеш, чөнки Иисустан соң килгән башка Бөек зат мәгълүм түгел.

АДӘМИ ШАЙТАН — «Йә, Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлам, Әбүҗәһил, Әбүләһәбләр сиңа дошман булсалар, әүвәлдә һәрбер пәйгамбәргә адәми шайтаннарны вә җени шайтаннарны дошман кылдык» («Әнгам»: 112). Моннан Әбүҗәһил белән Әбүләһәбләрнең адәми шайтан булулары аңлашыла. И.Ю.Крачковский бу төшенчәне рус теленә *«шайтан из людей»* дип тәрҗемә итә. Нурулла Мофлихун хәзрәт Арыслани «Ислам диненә каршы көрәшүче һәрбер патшаны һәм шәһәр, авыл хуҗалары»н «адәми шайтаннар» исәбенә кертеп, Иван Грозный, Ленин, Сталин кебек шәхесләрне атап әйтә. «Әнгам» сүрәсендә һәрбер пәйгамбәргә (һәрбер изге кешегә) шайтан белән көрәшергә туры киләчәге, бу шайтанның гадәти кеше кыяфәтендә булачагы кисәтеп куела.

Гомумән, гарәп телендә явызлыкка этәрә торган һәрбер затка карата шайтан, дип әйтергә мөмкин.

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынnan басылып килә.

АДЖИ — Тигез чатлы хачның (тәренең) аналогы. Аны тәңречеләр яңа эрага кадәр күп элек борынгы Тибет культурасыннан алганнар. «Аджи» сүзен үзенең фамилиясе иткән һәвәскәр тарихчы һәм журналист Мурад Аджи бу сүзнең буддилар динендәге дүрт чатлы яшен чаткысын белдергән *ваджра* сүзеннән алынган булуы мөмкин, дип фараз итә. Аның фикеренчә, «аджи-тәре» дигән табыну объектын һуннар Европага алып килгәннәр һәм христианнарның тәрегә табынулары шуннан башланып киткән. Тәңречеләр аджи тамгасын маңгайларына буяу белән яки инә белән кадап сурәтли торган булганнар. Н.М.Карамзин мондый гадәтнең кыпчакларда да булуын әйтеп китә. Тигез чатлы хачларның сурәте Байкалдан алып Дунайга кадәр далаларда кабер ташларында сакланып калган. Күрәбез ки, «аджи»дан «хач»ка һәм «хаҗи»га ул кадәр ерак ара түгел икән.

Тагын кара: ***Тәре һәм аңа табыну. Свастика.***

АДМИРАЛТИЯ БИСТӘСЕ, АДМИРАЛ БИСТӘСЕ тар. — Иске Казандагы бистә. Әдәбиятта, гадәттә, *Адмиралтейство бистәсе* рәвешендә очрый. Кайчагында *Диңгез (морская) бистәсе* дип тә аталган, чөнки анда елга кораблары төзелгән. Совет чорында бу бистә *Кызыл армия бистәсе* дип тә йөртелә. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә «Бишбалта» бистәсе атамасы кабул ителгән, ләкин ул тарихи чынбарлыкны чагылдырмый.

Тагын кара: ***Казан адмиралтействосы. Лашман хезмәте.***

АГА-БАЗАР — Идел буе Болгарстанында хәзерге Болгар шәһәре тирәсендә (Болгар шәһәрлегеннән 6 чакрым ераклыкта) Иделнең сул ярында хәзерге Меленка елгасы тамагында урнашкан сәүдә-һөнәрчелек үзәге, бакалтай. Ага-Базарда җәй көне *олы базар* җыела торган булган. Анда Рус кенәзлекләреннән, Бохарадан, Хәрәзем, Фирганә, Үргәнеч, Хаҗитархан, Сарай, Нугай якларыннан, Кытайдан, Кашгардан, Иран, Гарәп илләреннән, Юнаннан сәүдәгәрләр килә торган булган. Олы базар көннәрендә монда дәүләт күләмендә җыен да уздырганнар. 922 елда Болгарга килгән Ибне Фадлан сәяхәтнамәсендә шушы базар телгә алына дип уйлыйлар. Ага-базар 1431 елда кенәз Фёдор Пёстрый тарафыннан туздырылган.

Тагын кара: ***Тышкы Болгар.***

АГИДЕЛ, АГЫЙДЕЛ — *Кама* елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 1430 чакрым (Татарстандагы өлеше 76 чакрым). Уфа шәһәренә кадәр судно йөрешле. Башкортлар Каманы *Кара Идел* диләр (хәер, аларда Уфа суын да *Каридел* дип атау күзәтелә). Дим суының башка исеме *Күгидел* булуын әйтеп китик. Идел буе төрки халыклары гидронимиясендә *Ак Идел* таулардагы кар эрүдән туена торган елганы белдерә, ә *Кара Идел* җир асты суларыннан туена (*Кара елга*, гадәттә, урман һәм сазлык елгасы). Агидел елгасы исемен руслар башта, тәрҗемә итеп, «Белая Воложка» («Кечкенә Ак Волга») дип атаганнар, тора-бара аның *«Белая»*сы гына торып калган (Ф.Гарипова).

Тарихчы М.Глухов: «Керәшеннәрдә Агизел, башкортлардагы кебек үк — Кама елгасы», дип яза.

Татар язучысы Хәсән Сәрьян: «Безнең як халкы Агыйделне күп вакыт Идел дип кенә йөртә, шуңа күрә аның унар чакрымга җәелеп, язларын су астында кала торган әрәмәле, болынлы түбән ягын элек-электән *Идел Эче* дип әйткәннәр, ә таулы биек ягын *Кыр Ягы* диләр», — дип яза. Билгеле булганча, Казан якларында Иделнең *[Волга Иделенең]* бер ягын — *Болын Ягы* дип, икенче ягын *Тау Ягы* дип йөртәләр.

Тагын кара: ***Идел. Кама.***

АГУ КАЙТАРГЫЧ — Организмга эләккән aгуның (зәһәрнең, токсинның) тәэсирен бетерү, аны зарарсызландыру өчен кулланыла торган матдә, *антидот* (грек теленнән). Электә агу кайтаргыч сыйфатында еш кына терийак / тирйак (әфьюн) кулланганнар. Хәзерге вакытта синиль кислотасына каршы — *амилнитрит,* люизитка каршы — *тиоллы кушылмалар* (бал, унитол), агулы фосфороорганик кушылмаларга каршы *атропин*, мышьяк белән терекөмешкә каршы *димеркапрол* кулланыла. *Диңгез кәбестәсе* — бик көчле антидот һәм радиациягә каршы чара.

// *Зәһәр һәм пәнзәһәр* — агу һәм агу кайтаргыч.

АГЫЙЫК — Себер татарлары телендә арзанлы таштан ясалган муенса, беләзек, төймәләр һ.б. бизәнгечләр. Бу сүз Себер якларында халыкның ташларны яхшы тануы турында сөйли.

АДАШ СҮЗЛӘР — Аваздаш сүзләр, синонимнар. Гарәпчә — *морадиф сүзләр.* «Адаш сүз» терминын Н.Исәнбәт тәкъдим иткән. Гомумән, Н.Исәнбәт тел-әдәбият белемендә кулланылган гамәлдәге терминологияне бик үк «санга сукмый», төрки нигезле «үз» терминологиясен тәкъдим итәргә ярата иде. Мондый гадилеккә, халыкчанлыкка омтылыш аңар Владимир Дальнең сүзлегеннән «йоккан» шикелле тәэсир кала.

Гомумәдәби телдә синонимнарның муллыгы телнең байлыгы турында сөйли, ләкин фәнни, профессиональ телдәге синонимнар, киресенчә, терминологиянең эшләнеп җитмәгәнлеген, өлгермәгәнлеген күрсәтә. Моны онытмаска кирәк.

Адры бор.төр. — Борынгы төркиләрдә туп («шара») тәгәрәтеп уйнаганда тупка сугу өчен япьле кәшәкә, аеры. Бу термин Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә очрый.
// *Эр топыкны адры билә тулды* — ир тупка аеры кәшәкә белән орды. «Диване лөгатет-төрк».

АДЫМ — Халык метрологиясендә озынлык һәм мәйдан үлчәү берәмлеге. Башкача — *атлам.* Озынлык үлчәве буларак, 0,75 смга, мәйдан үлчәү берәмлеге буларак 5,5 кв.мга тигез (М.Глухов буенча). «Борынгы төрки ат-, алт- «атлау, йөрү» сүзеннән» (профессор Р.Әхмәтьянов). Охшаш сүз һәм берәмлек төрки телләргә хас. Калмык телендә *адм* — зур адым, үлчәү адымы. // *Адым-адым юл үтелер* — Дорогу осилит идущий (русча).

АЕПА (?-1117) — Кыпчак идарәчесе (ханы). Владимир Мономах белән сугышкан, аннары рус кенәзләре белән бергәләп Идел буе Болгарстанына яуда катнашкан һәм шунда үтерелгән. Русча чыганакларда *Айюп* язылышы да очрый. Татарча *Әйүб / Әйүп* дип булыр иде. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә *Әййүб* язылышы тәкъдим ителә, ул да кулай. Гомумән, бу исем мөселманлыкка ишарәли кебек, ләкин Аепаның Владимир-Суздаль кенәзе Юрий Долгорукийга кызын кияүгә биргәнлеге мәгълүм (ягъни ул рус кенәзе Андрей Боголюбскийның бабасы). Аепа үтерелгәннән соң, кенәз Долгорукий Болгарга яу чаба, болгар гаскәрен җиңеп, берничә каланы туздыра.

АЗА — Татар диалектында «демон», явыз көч. Көнчыгыш төрки телләрдә «җир рухы», «явыз рух». «Бәбиләр чире рухы» буларак, Умайанага каршы куела. Яңа туган бала өстендә Умай белән Аза көрәшә дип ышанганнар: Умай бәбине саклап калырга, ә Аза аны һәлак итәргә тырыша икән (Р.Әхмәтьянов буенча).

Аза кубу дигән фразеологизмның беренчел мәгънәсе — җир тетрәү (*«җир рухы Азаның калкуы»*). ■

Мирасворд





боронгы төрки халык

нота

мариларның элекке исеме

драматург Гамир …

… - том

сарык

ачык, билгеле, мәгълүм (иск.)

тарихта тирән … калдыру

… Насыйри

скиф кылычы

пар

рус композиторы

Украина, Молдавиядә яшәүче төрки халык

ботинка өстеннән киелә торган җылы куныч

рәссам Ван …

кыргый кош яки җәнлек

«…Самгинның тормышы» (М.Горький)

Себер шаманы

Коръәнне яттан укучы

будда динендә тынычлык халәте

сугышчы, гаскәри

XIII-XVIII йөзләрдә Россиядә почта станциясе

йомшак күн

матур, сөйкемле (иск.)

… Гыйләҗев

хөкүмәт карары

атны куалау

Кытай каласы

Урта Азиядәге елга

Кыргызстандагы шәһәр

Татарстандагы район

Африкадагы елга



гарәп артикле

борынгы сугыш киеме

кыргый үгез

… сабагын укыту

Ким Ир…

көйле тавыш, тон

Рәис Габдулла *төзеде.*

3 нче сандагы мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: мөнәҗәт, өяз, робагый, мут, Кашан, өммәт, Анак, Ык, Бакиров, наза, Ливан, Лорка, Риза, Бакый, гавам, ия, саванна, Упа, Мар, авар, бра, Дәрдмәнд, Рид, Ра.
Өстән аска: күбәләгем, Ади, Шакиров, дәва, Мәрҗани, алпар, нар, аем, Урда, Нәби, Кол, Вил, Гамбәр, җигем, Варна, манара, Арад, төймә, Аникин, Утыз, зыян, Азат, Камай.

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның апрель ае

APRIL OF 1914'S ISSUE OF «KAZAN HERALD» THE «KOYASH» («SUN») NEWSPAPER

Мәрҗани хәзрәтләренең мәдрәсәсе

Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең мәдрәсәсеннән, Мәрҗани исемен чыгарырга уйлап булырга кирәк, капкасы башына «Мәрҗания» дип яздырмыйча, «Мухаммеданский» дип язылган калай кадаклаттылар. Башкалар Мәрҗани хәзрәтләренең исеменә урам сорап та, шул урамны Мәрҗани исеме берлә атаганда, бу Мәрҗани мәдрәсәсен идарә итүчеләрнең исем алыштырудан максудлары ни икән? Мәрҗани хәзрәтләренең ничә еллар дәрес әйткән мәдрәсәсенә Мәрҗани исемен яздырып куйсалар ярамас идеме икән? М.Альметов.

1914. — №377. — 2 апрель.

Эш эшләнми

Тукайның елы булып үтте. Бу мөнәсәбәт белән аның тугрысында һичбер эш эшләнмәгән икәнен яңадан бер кат хәтергә алмый үтәргә мөмкин түгелдер: кабере һаман әле һичбер төрле тәгъмир ителмәгән [төзекләндерелмәгән], хәтта бер таш та куйдырылмаган. Тукайның мөфассал [җентекле] тәрҗемәи хәлен язып, нәшер итәргә төзелгән комиссия дә бу турыда бер юл булсын, бернәрсә язмаган вә һичбер тәшәббес ясамаган [эшкә керешмәгән]. Әгәр бу комиссия һаман шушы эшсезлегендә дәвам итәчәк булса, Тукай эшләрен фәкать хосусый инициативадан гына күтәргә каладыр.

Казанда Тукай көне

2 нче апрель* көнне Казан матбугаты һәм Казан яшьләре вә шәкертләре Тукай өчен зур матәм тоттылар. Газета вә журналлар һәммәсе Тукай хакында төрле мәкаләләр вә аның рәсемнәре илә тулы чыккан иде. Мәдрәсәләрнең бик күбесеннән шәкертләр Тукай рухына хәтем итеп дога әйткәннәр. Сәгать икеләрдә бөтен матбугат әһеле, укучы яшьләр вә җәмәгать хадимнәре хосусый бер ханәгә җыелып, башта сөекле карт имамнарыбыздан Зариф хәзрәт[1] вә яшьләр мелласы исемен алган зыялы муллаларыбыздан Касыйм хәзрәт булдыкы хәлдә, атларда зияратка киттеләр. Казанның бөтен зыялыларының үзләренең сөекле имамнары илә берлектә 10-15ләп атта зиратка китүләре, бу көннең кайгылылыгына аерым бер тәшшәкел [рәвеш] бирәдер иде.

Имамнар вә зыялылар зияратка барып җиткәндә инде сөекле шагыйрьнең кабере янында халык бик күп җыелган, һәм шушы халыкның күбрәге

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Зариф хәзрәт — Г.Тукайның дусты Ф.Әмирханның этисе — Мөхәммәдзариф Әмирхан. 1913 елда Г.Тукайның җеназасын укый.

шәкертләр булганлыгы аерым күзгә бәрелеп тора иде. Мөхтәрәм Касыйм хәзрәт тирән бер моңлылык илә «Тәбарәк» сүрәсен укып, озын дога әйтте. Җыелган халык Коръәнне бик ихлас берлә генә тыңлап дога әйткәннән соң, шул ук хошуг [түбәнчелек] илә тугры «Сабах» китапханәсе[2] мөдире Габделвәли Әхмәдуллин ханәсенә кайттылар. Чөнки бу көнне ул зыяфәт [сый-хөрмәт] ясап, мәзкүр имамнарны, зыялылар вә укучы яшьләрне үз ханәсенә дәгъвәт иткән иде. Әлегә кадәр бер-берсенә нәфрәт итешеп килгән чалмалылар илә зыялыларның бергә бер мәҗелестә, бер-берсенә чын мәхәббәт вә ихлас берлә туганнарча сөйләшеп утырышдыклары бу мәҗлесне соң дәрәҗәдә гүзәл итте.

Русларның бөек постлары һәфтәсе [атнасы] булу сәбәпле, бу көн клубларда Тукай шәрифенә кичәләр ясалмыйча, киләчәккә кичектерелгән иде. Шуңар күрә, яшьләр бу матәм көнен шушы дога берлә генә үткәреп торырга мәҗбүр булдылар.

Сүз ахырында, һәрбер форсаттан файдаланырга яратучы сәүдәгәрләрнең, бәгъзе форсаттан файдаланырга тырышуларының урынсыз булганын да әйтеп китим әле. Тукай зиярәты янында ниндидер бер малай Габдулла Килдишев нашире булган «Тукай хакындагы хатирәләрем» исемле бер әсәрне[3] сатып торадыр иде. Бу әсәр әлегә тәнкыйть аркылы кичмәгән бер әсәрдер. Халыкның Тукайга булган мәхәббәтеннән матди файда итү, аеруча мондый кайгылы көндә үзе бер тупас эш. Шул сәбәпле, моннан соң андый тупаслыклардан саклану тиештер.

1914. — № 380. — 6 апрель.

«Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дә губернатор

16 нчы апрельдә шәһәребезнең яңа губернаторы Боярский җәнаплары, М.Н.Пинегин һәм чиновник особых поручений при казанского губернатора, «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә кереп, карап йөрделәр. Һәммә сыйныфларга кереп, мәдрәсәнең бинасын күрделәр. Губернатор җәнапларын мәдрәсәдәге шәкертләр, мөдәррисләр үз сыйныфларында булганы хәлдә истикъбаль иттеләр [каршы алдылар]. Губернатор җәнаплары сыйныфларга кергәндә бәгъзе шәкертләрдән нинди дәрес укыганлыкларын истифсар кылды [сорап белде] вә кай җирлектән икәнлекләрен сорашты. Мәдрәсәнең нәзафәт [чисталык] җәһәтен яратканлыгын бәян итте. Миһманнар [кунаклар] мәдрәсәнең журналына имза кыйлып чыктылар.

Чиркәү бәйрәменә

Рус сәүдәгәрләреннән бер фирка губернаторга гариза биреп, мөселманнарны чиркәү бәйрәмнәрендә бәйрәм итәргә тәклиф итүен [боеруын] сораганнар. Алар, озын гаризаларында, чиркәү бәйрәме көннәрендә сәүдә иткән өчен протоколлар гына куеп йөрелмәсен, аларның кибетләре ябып кителсен, дип язганнар.

1914. — №390. — 17 апрель.

[2] «Сабах» китапханәсе — 1902 елда Казанда бертуган Әхмәдуллиннар ачкан китап кибете, 1911 елда аның каршында «Өмид» басмаханәсе ачыла.

[3] Сүз Камил Мотыгый тарафыннан язылып, Казанда 1914 елда Габдулла Килдишев наширлегендә дөнья күргән «Габдулла Тукаев хакында хатирәләрем» исемле китап турында бара.

«Мәрҗани» конфеты

Казанның могтәбәр фабрикантларыннан Вәлиулла Ибраһимов һәм борадәре фирмаларының «Аль-фа» исемле кондитер фабригы ачылганлыгын газетада язып узган идек.

Мәзкүр фабрика хәзер Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең юбилейсы мөнәсәбәте белән[4] «Мәрҗани» исемле конфет чыгарган. Шоколад катыштырылып ясалган бу яхшы конфетның кәгазенә Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең рәсеме төшерелгән. Бу конфет тиз көннән сатуга куелачактыр.

Бер мөселман фирмасының бер мөселман галиме юбилейсына хаслап яхшы товар дөньяга куюын, шөбһасез, тәбрик итеп кенә каршы алырга мөмкиндер.

Бу шулай, әмма менә безнең Казанның искечеләре, һәрвакыттагыча мантыйкка хилаф буларак, шушы конфет хакында ду килеп йөри башладылар. Мәзкүр фирманы Шиһаб хәзрәт сурәте белән конфет ясаган өчен сүгеп, Шиһаб хәзрәтләренең варисларына мөрәҗәгать итеп, ул конфетны саттырмауны таләп итәләр, хәтта кайсыбер кибәкбашлылары бу тугрыда чиновникларга мөрәҗәгать итеп, туктаттырырга йөриләр икән.

Без әлеге фирмага Печән базары искечеләренең бу шаулашуларына һич игътибар итмичә, юбилей конфетларын сатуга куярга киңәш итәбез. Мәрҗани рәсеме хәзер матбугатка чыккан рәсем, ул һичберәүнең милке түгел. Шунлыктан, Мәрҗанинең варислары бу эшкә һичбер төрле каршылык күрсәтә алмаячаклардыр.

Искечеләрнең түрәләр аркылы туктатырга йөрүләрендә дә һичбер төрле муаффәкыять [уңыш] казану ихтималы юктыр. Алар Мөхәммәд, Әхмәдҗан хафизларның сүзләре белән генә сәүдә эшләрен тыюдан югары торадыр.

1914. — № 387. — 14 апрель.

Кәҗә турында

Кәҗә асрау җәмгыяте шәһәр көтүләрендә кәҗә йөртү өчен ияләреннән түләү азайтылсын иде, диеп үтенгән. Бу үтенечне болыннар комиссиясе караган. Мәҗлестә булганнар, кәҗәнең күп зарарларын һәм начар сыйфатларын зикер итеп [искә алып], аларның һәммәсенә муенчаклар, намордниклар, җөгәннәр, тагын әллә ниләр, әллә ниләр киертеп, аларның зарарларыннан вә афәтләреннән сакланулар хакында, урамда йөргән кәҗәләрне тыю юлында мәҗбүри карар чыгару вә шулар хакында бик җитди мөзакәрәләр [фикер алышулар] кылганнан соң, җәмгыятьнең үтенечен кабул итеп, һәр кәҗәдән елына 1 сум алырга һәм дә урамда йөргән кәҗәләрне частька ябуны полициягә тапшырырга карар биргән.

1914. — №397. — 25 апрель.

Сөембикә манарасы

Губернское правлениенең техника вә тәгъмират [төзекләндерү] шөгъбәсе тарафыннан Сөембикә манарасы карап чыгылган. Манараның төзәтергә

---

[4] 1915 елның гыйнвар аенда Ш.Мәрҗанинең (1818/1233 h.-1889/1306 h.) тууына һиҗри ел исәбе белән (1333 елның рабигыль-әүвәл аенда) 100 ел тулган.

тиеш җирләре карап чыгылганнан соң, мондый хәлләр күрелгән: 1) Манара диварлары эчендәге бәйләвеч тимерләрдән түбән каттагылары сынып аерылганнар, алар урынына калын тимердән бәйләвечләр куярга ихтыяҗ күрелә; 2) нигез өсте катлавы бозылып беткән; 3) түбәнге диварның өске кирпечләре ышкылып ватылгалаган, кирпечләре төшкән урыннар күп; 4) гәрнизләре бозылып беткән; 5) иң югарыдагы тәрәзә аралары бозылып, кирпечләре коелып беткән ки, иң куркынычлы урыны да шулдыр; 6) манара диварының өске катлавы таушалып беткән; 7) һичбер урында рамнар, ишекләр, тәрәзә калмаган; 8) манараның эчке ягы, уртасы сәламәт хәлдә.

Якынча хисапка караганда, бу манараны төзәтеп чыгу өчен 10 мең сумнар кирәк булыр, диләр.

1914. — №400. — 29 апрель.

Мосафирлар

Төркиядә Вакыф нәзарәтенә табигъ мәктәп, мәдрәсә вә китапханәләр мөдире Наил Рәшид бәк илә аркадашы Гомәр әфәнде берничә көннән бирле шәһәребездә мосафирлар. Аларның шәһәребезгә тәшриф итүләре [килүләре] мөстәшәрык [шәрык белгече] Катановның китапханәсен сатып алмак максады иләдер. Килгән көннәреннән бирле мәзкүр китапханәдәге китапларны тәфтиш итмәк [тикшерү] илә шөгыльләнмәктәләрдер.

1914. — №394. — 22 апрель.

Катанов китапханәсе

Төркиядән Катанов китапханәсен алырга килгән Аукаф нәзарәтенә табигъ мәктәп, мәдрәсә вә китапханәләр мөдире Наил бәк аның иптәше Гомәр әфәнде китапханәне алты мең сумга килешеп алдылар. Бер-ике көннән китапларны, сандыкларга салып, Одессага озатачаклар[5].

1914. — № 398. — 27 апрель.

Мөселманча бугазлауга каршы

Шәһәрнең ветеринария комиссиясендә шәһәрнең хайван бугазлау ханәсендә мөселманча — хайваннарның аягын бәйләп бугазлау мәсьәләсе кузгалган. Комиссия бу эшне хайванны артык рәнҗетү дип аңлатканлыгыннан соң, бу эшне бетерү тиеш, дигән фикергә килгән. Ләкин, бу аяк бәйләп бугазлау мөселман шәригате буенча бугазлауга әсасме [нигезме], түгелме икәнлеге анык беленмәгәнлектән, бу мәсьәлә хакында мөселман руханиларына мөрәҗәгать итәргә, әгәр мөселман руханилары, мөселман шәригатендә аяк бәйләп бугазлау мәҗбүри дип тапмасалар, аяк бәйләүне бетерергә карар биргәннәр.

1914. — № 398. — 27 апрель.

Текстны һәм искәрмәләрне
***басмага Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

*The text was prepared by **Lenar Gubaydullin*** ■

---

[5] 1914 елда, матди хале авыр булу сәбәпле, галим, тюрколог Н.Ф.Катанов шәхси китапханәсен сата (барлыгы 3500 данә китап). 1922 елда, галимнең вафатынннан соң, хатыны да шул ук сандагы китапны Төркиягә сатып җибәрә. Хәзерге вакытта бу китаплар Истанбулның Тюркологик тикшеренүләр институтында саклана.

ЯҢА КИТАП

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ. Әсәрләр: Унбиш томда. — 10 том: Публицистика (1928-1933) (томны төзүче һәм текстларны әзерләүче Гөлназ Хөснетдинова; аңлатма һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр: Зөфәр Рәмиев, Гөлназ Хөснетдинова, Эльмера Галимҗанова; фәнни мөхәррире Зөфәр Рәмиев). — Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. — 479 б. Тиражы — 2000 данә.

Татар халкының бөек улы, әдип, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый мирасын халыкка кайтару эше дәвам итә. Бу өлкәдә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләре зур эш башкара. Күптән түгел Г.Исхакый «Әсәрләр»енең X томы дөнья күрде. Биредә Г.Исхакыйның 1928-1933 еллар аралыгында язылган мәкаләләре һәм «Идел-Урал» исемле хезмәте урын алган. Томда язмалар хронологик тәртиптә бирелгән, сүзлек, аңлатма һәм искәрмәләр белән баетылган.

Томга кергән мәкаләләрнең шактый өлеше Исхакый мөхәррирлегендә 1928-1939 елларда Берлинда гарәп язуында нәшер ителгән «Милли юл» («Яңа милли юл») журналыннан алынган.

Г.Исхакыйның 1929 елгы «Кызыл Татарстан»га җавап» мәкаләсе М.Сәгыйдуллинның «Милли байрак астында сәяси фәхеш», «Зәңгәр әләмгә мәхәббәт эзләгәндә», «Сатылган әләм астында» исемле Исхакыйга каршы басылган мәкаләләренә җавап рәвешендә язылган. Алар полемик пафос белән сугарылган.

Шулай ук Г.Исхакыйның «Толстойның татар әдәбиятына тәэсире» (1929) мәкаләсе дә Х.Вәлинең «Безнең юл» (1928) журналында урын алган, шул ук исем белән бирелгән мәкаләсе уңае белән язылган. Анда Исхакый, Х.Вәли фикерләренә каршы килеп, үз иҗатына Толстойның йогынты ясамавы һәм бөек язучының кайбер фикерләрен кабул итә алмавы, аларның аңа һәм, гомумән, татар зиһененә ят булуларын әйтә.

Белгәнебезчә, Г.Исхакый 1931 елның 6-17 декабрендә Коддеста уздырылган Бөтендөнья мөселманнары корылтаенда катнаша. Шул сәбәпле мөселман Көнчыгышына, Фәләстин, Мисыр, Сүрия, Иордания кебек илләргә сәфәре нәтиҗәсендә язылган «Ислам мәмләкәтләре» исемле очеркы аеруча игътибарга лаек. Автор үзе әлеге язмасын «Юл истәлекләре» дип атаган. Чынлыкта исә язма үзенең эчтәлеге белән сәяхәтнамә жанрына карый. Биредә авторның эшлекле сәфәр вакытында күргән-ишеткәннәре, уй-кичерешләре шактый җентекле сурәтләнгән. Аны укыганда, Г.Исхакыйның эрудициясенә, аның тарихтан һәм сәясәттән яхшы хәбәрдар булуына, фикерләвенең үткенлегенә, карашларының киңлегенә һәм тиешле дәрәҗәдә тәнкыйди булуына игътибар итәсең.

Томның искәрмәләр һәм аңлатмалар өлеше шактый бай. Биредә мәкаләләрдә очраган һәрбер атамага, шәхескә, вакыйгаларга бүгенге көн күзлегеннән карап, тулы аңлатма бирелгән.

Гомеренең шактый өлешен мөһаҗирлектә үткәргән Исхакыйның иҗатын барлау, таралып, сибелеп яткан язмаларын эзләп табу, текстология җәһәтеннән тикшереп, укучыга җиткерүгә томны әзерләүчеләрнең күп көч куюлары ачык күренеп тора. Китап татар әдәбияты тарихын, иҗтимагый-сәяси фикерен өйрәнүчеләр, тел тарихы белән шөгыльләнүчеләр һәм, гомумән, киң катлау укучылар өчен дә кызыклы һәм кыйммәтле мәгълүмати һәм фикри чыганак буларак бәяләнергә лаек.

Гөлчирә Ханнанова,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре

Gulchira Khannanova, *research associate of the Institute of Language, Literature and Art named after G.Ibragimov* ■

ХӘМИТ ЛАТЫЙФ

Hamit Latif, artist

«Су юлы». 2007 ел. Картон, пастель

Хәмит Нәҗип улы Латыйпов (Латыйф) 1949 елның 5 мартында Пермь өлкәсе Губака шәһәрендә туа. 1978 елда Уфа сәнгать училищесын тәмамлый.

Хәмит Латыйф — рәссам-шагыйрь, агачтан уеп эшләүче, график, сынчы. Иҗат кыйбласы — төрки дөнья образлары, риваятьләр, ырымнар, чәчәк вә гүзәл орнаментлар. Аның иҗатында, нигездә, фәлсәфи фикерләү, галәми-дөньяви гамь кебек олы төшенчәләр чагылыш таба.

Хәмит Нәҗип улы — Россиянең һәм Татарстанның Рәссамнар берлеге һәм Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы. Аның сәнгати әсәрләре Татарстанның һәм Башкортстанның үзәк музейларында, Россиянең төрле калаларындагы, Төркия, Америка, Германия, Израиль, Франциядәге шәхси тупланмаларда һәм галереяларда урын алган.

Редакциядән: журналыбызның бу санында тулаем Хәмит Латыйф рәсемнәре файдаланылды

«Җыр». 2007. Картон, пастель

«Риваять». 2007. Керамика

ИНДЕКС 54132
70275

МИРАС №4 / 2014



Төрки телләр шәҗәрәсе
Genealogy of Turkic languages